Мин Гакыйль абый Сәгыйров белән 1972 елда, ул үскән һәм озак еллар яшәгән Самар өлкәсенең Кошки районындагы Иске Фәйзулла авылының кияве булгач таныштым. Ул чакта мине бу авылдагы күп нәрсә хәйран калдырды: андагы табигатьнең гүзәллеге, киң урамнарында чылбырдай тезелгән күлләре һәм алар тирәсендә үскән биек таллар.

Әлбәттә, Гакыйль абый Сәгыйровка да менә шушы гүзәлләкләр илһам биргәндер. Аларны ул үзенең рәсемнәрендә дә чагылдырган.



Хәрәкәтләнү мөмкинлегеннән бөтенләй мәхрүм булган килеш тә, ул шушы авылда аның рухи үзәге булып яшәде. Аның янына халык нинди генә йомыш белән килмәде: фоторәсемгә төшәргә, дәрес әзерләргә булышырга, киңәш сорарга, серләрен, кайгысын һәм шатлыгын бүлешергә килүчеләр беркайчан да өзелмәде.

Урамда да, өендә дә аның янәшәсендә һәрвакыт төркем-төркем яшьләр, бала-чагалар, ыгы-зыгы килеп, кайнаша торган булды. Аның ау мылтыгы, фотоаппараты һәм ул чакта сирәк кешедә очрый торган, иганәче нефтьчеләр бүләк иткән башка мавыктыргыч нәрсәләр дә моңа сәбәпче булгандыр.

Гакыйль Сәгыйров, авылдагы һәрнәрсәдән хәбәрдар булып, кичләрен радиотапшырулар үткәрә иде. Аның өе каршындагы багана башына куелган радио ноктасыннан һәр кичтә төрле яңалыклар, татар көйләре яңгырап торды.

Гаҗәп, кайдан килде икән бу кешегә шулкадәр рухи ныклык, хисләр тирәнлеге һәм үзенә тарту көче?!

Аллаһы Тәгалә кешегә күп мөмкинлекләр, тормышны алып барырга сәламәтлек, көч-куәт бирә. Кызганыч, исән чакта без мондый байлыкның кадерен генә белмибез шул.

Гакыйль Сәгыйровның эчке дөньясы, күңел сафлыгы аның иҗатында да ачык күренә. Тыйнак-

лыгы, сабырлыгы, түземлеге һәм күнел нечкәлеге дә таң калдыра. Тормыштагы бар булган гаделсезлекне, затсызлыкны да ул үз йөрәге аша кичереп, аларны шигырь юлларына тезде. Бер шигырендә:

*Елар чагымда шаярдым, көлдем,*
*Йөрәк әрнүен мин шулай тыйдым,*
*Чыккан яшемне кеше күрмәде,*
*Тозларын сыгып, җаныма җыйдым, – дип яза ул.*

Җәмгыятебездә күзгә күренеп арткан әхлаксызлыкка җаны әрнеп:



*«Яшьләрдән яңа токым чыгардык,*
*Вәхшилегенә түгел чыдарлык», –* дип яза.

Коточкыч фаҗига эчендә, язмыш читлегендә яшәсә дә, ул милләтебез хәлен, телебезне кайгыртып гомер итте:

*«Мин – татар!» – дип,*
*«Без – татар!» – дип,*
*Күпләр йөри күкрәк бәреп,*
*«Татарлыкны югалтмадык,*
*Үттек юлның иң хәтәрен!»*
*Барып керсәң үз өенә,*
*Үсеп җиткән бәбкәләре,*
*Тәтелдиләр «кяфер» телдә,*
*Такмаганнар гына тәре...» –* дип ачынып яза ул.

Үзендәге каршылыклы хисләрен ничек җиңүе турында болай яза:

*“Көрәшергә җитми көчем,*
*Баш иясем килми дошманга,*
*Дошманнарым күп булмасын өчен,*
*Әйләндерәм барсын дусларга».*

Уйлап карасаң, моңа никадәр күңел киңлеге, бүтәннәрне санга санап, кичерә белү һәм башка матур кешелек сыйфатлары булу кирәк бит!

Тирән хисле, нечкә күңелле кеше буларак, ул үзенең фаҗигале язмышын да онытып, үз җәмгыятенең, уз милләтенең киләчәген кайгыртып яшәде.

Гакыйль Сәгыйров һәрвакытта мәгълүмат үзәге, сәясәтче, акыллы киңәшче, юатучы, төшенкелеккә бирелгәннәрне рухландыручы да булды. Бер генә адым да атларга, кул-аягын, гәүдәсен кыймылдатырга да мөмкинлеге булмаган кеше ничек боларны булдыра алды икән соң?!

Ул үз гомеренә кешене тыңлый, аңлый һәм аның шатлыгын-кайгысын да чын күңелдән уртаклаша белде. Нинди генә киңәшләр, сораулар белән килсәләр дә, ул беркемне дә игътибарсыз калдырмады. Кемдер армиягә яисә читкә китсә дә, кайтса да – аның белән исәнләшергә яисә, саубуллашып, сөйләшеп утырырга кермичә калмады. Бу хәл авыл халкында төпләнгән матур бер гадәткә әверелгән иде.

Аңарда ниндидер үзенә тарту көче, магнетизм бар иде кебек. Янында һәрвакытта төркем-төркем балалар булып, коляскасында үзен авыл урамындагы күлләр тирәсендә йөрттеләр. Ничә буын кешеләре аның сәкесендә дәрес әзерләп, акыллы киңәшләрен тыңлап үстеләр.

Авыл җәмгыятенең үзәге булып, халыкны берләштереп яшәү дәверендә ул бихисап матур истәлекләр һәм үзенә илаһи һәйкәл булырлык иҗади мирасын да калдырды.

Гакыйль Сәгыйровның шигырьләре һәм төрле әдәби әсәрләре басылган унлап китабы бар. Аларның исемнәрендә генә дә никадәр серлелек һәм тирән мәгънә салынган. Шуларның берсе «Кабатланмас моң» дип атала. «Йөрәк сере» исемле китабындагы шигырьләр аеруча дулкынландыра. Анда иҗатының иң уңышлы өлеше тупланган шул.

Ә аның Мәскәү сәнгать академиясенең ике курсын гәүдәсе хәрәкәтсез килеш «иң яхшы» билгеләргә тәмамлавын ничек аңларга?!

Ул әле ахыйрәттә дә милләтебез, телебез хәлен кайгыртып, безгә мөрәҗәгать итеп, кисәтеп тора сыман. Тик моңа бик күпләр битараф булып яшиләр шул әле.

Мәсәлән, ул авылдагы ике катлы мәктәпнең ишеге дә инде шактый еллар буена йозак элент хәлдә. Авыл балалары унбиш чакрымдагы мукшы авылына йөреп укыйлар.

Авыл торган саен картая. Биредә



буш йортлар арта бара. Ә нинди бөек шәхесне тәрбияләп үстергән авыл бит ул! Кемгә тиңләп була соң аның яшәү батырлыгын?! Дөньяда бармы икән тагын, аның кебек, авызына каләм кабып, тетрәндергеч шигырьләр язган һәм сокланырлык рәсемнәр ясаган башка кешеләр?!

Кызганыч ки, озак еллар аның йорты ташландык хәлдә булып, коймалары ауды, йортын өй биеклек тигәнәк, шайтан таягы басты. Өе дә череп таушалды. Озак еллар аның музеен булдыру турында сүзләр барса да, проблема урыныннан кузгала алмады.

Дөрес, бу көздә Гакыйль Сәгыйров яшәгән өйне сүтеп, анда булачак музейның нигезе салынды. Аны музей төзү исәбенә җыелган акчага җәмгыять эшлеклесе Гата улы Вазыйх Мөхәммәтшин эшләтте. Ләкин бередә шагыйрь истәлегенә тиң музей төзелер, дигән тулы ышаныч әлегә юк.

Хәзер Гакыйль Сәгыйров шигырьләрен урыс һәм инглиз телләренә тәрҗемә итү өчен актив хәрәкәт бара. Бу бит аның даны бөтен дөньяга таралачак, дигән сүз! Менә шул вакытта аның тормыш юлы белән якынрак танышырга теләүчеләр дә булыр. Шунда алар бөек якташыбыз яшәгән Иске Фәйзулла авылына килергә теләсәләр, ниләр күреп китәрләр икән?!

Бу авылның тарихы турындагы китап булдыру юлында хәзер актив эшчәнлек бара. Дөрес, башка авылларда узгандагы хәлләр турында төрле язмалар саклаган булса, мондагы 25-30 еллар элек булган хәлләр дә куе томан артындагы кебек хәлдә. Борынгылары турында инде сөйлисе дә юк.



Ә монда бит заманында танылган җәдитче, ахун Закир хәзрәт Шаммасов яшәгән һәм хезмәт иткән авыл турында сүз бара. Аның хәзерге хәле, рухы сүнеп, үлем көтеп яткан кешене хәтерләтә.

Арабызда бу хәлләргә колак салырлык, аларны үз йөрәге белән кабул итәрлек милләттәшләребез булса – уйлашырга, киңәшергә һәм ниндидер карарлар кабул итәргә кирәктер.

Кызганыч, тик: “Хәзер күп авылларның торышы шул хәлдә, моңа гаҗәпләнәсе юк!”, – диючеләр һәм битарафлар әлегә арабызда күпчелек санда. Боларны уйлаганда ирексездән Һади Такташның туган авылы таркалып, аның урынын чүп басу күренеше күз алдына килә.

Безгә, Татарстаннан читтә яшәгән татарларга, мондый мәсьәләләрне хәл итү авыррак шул. Тик шулай да, Гакыйль Сәгыйров – ул безнең уртак героебыз, халкыбыз горурлыгы. Аның музеен булдыру һәм ул яшәгән авылның тарихын бастыру юлында теләктәшлек күрсәтүчеләр табылса, бик шат булыр идек.



# МУЖ И ЖЕНА – ОДНА САТАНА?



## РЕШЕНИЕ СОВЕТА УЛЕМОВ ДУХОВНОГО УПРАВЛЕНИЯ МУСУЛЬМАН РФ НЕ ПОНИМАЮТ ДАЖЕ ИСПОВЕДУЮЩИЕ ИСЛАМ

***Времена, когда браки с представителем другой религии, расы, да просто национальности считались в обществе табу, хорошо помнили наши бабушки и дедушки. Потому что в их молодости это было так. Впрочем, даже они большую часть жизни прожили в стране, где межнациональные браки давно перестали считаться чем-то невероятным. А с вероисповеданием супругов всё было вообще просто – в СССР религия оказалась отделена от государства, да и многие серьезно думали, что Бога нет. Сейчас процент считающих себя верующими на порядок выше – вот и появились проблемы в головах у некоторых особо озабоченных деятелей. А уж предлагаемые ими решения этих проблем своим радикализмом иногда просто пугают…***

**Дмитрий ГРЕКОВ**

### СЛОВО – НЕ ВОРОБЕЙ

При Духовном управлении мусульман (ДУМ) РФ существует совет улемов – но до ноября нынешнего года подавляющее большинство россиян, особенно тех, кто не исповедует ислам, об этом даже не догадывались. Мгновенную известность это собрание 22 мудрых старцев получило, когда 10 ноября была опубликована его фетва (богословское решение по спорному вопросу), запрещающая мусульманам, проживающим в России, вступать в брак с женщинами других религий.

**Впрочем, некоторые из них еще не совсем «старцы», и даже не все мужчины. Их фотографии на сайте ДУМ показывают людей, мягко говоря, возраста «молодого и среднего», а Марьям Ковалева, единственный улем-женщина в этом совете, вообще совсем еще не похожа на человека, приближающегося к «возрасту мудрости».**

Сказать, что документ произвел впечатление разорвавшейся бомбы, – это будет даже преуменьшением. Православные и атеисты «в дружном порыве» связали злополучную фетву с кампанией, развернувшейся в последние недели из-за резонансного убийства школьного учителя во Франции, «карикатурного дела» и нагнетания околорелигиозной истерии разнообразными политиканами и экстремистами с обеих сторон под этим предлогом. Что, конечно, вряд ли – само заключение, оказывается, было дано еще год назад, в ноябре 2019 года, и только сейчас оказалось в публичном доступе на сайте ДУМ РФ. Впрочем, вопрос, а кто и почему решил его там выставить на всеобщее обозрение и под прицел неизбежной критики, именно сейчас – имеет смысл задать…

Неприятно удивлены оказались не только представители иных конфессий, но и многие добропорядочные мусульмане. Потому что слова «22 старцев и старицы» прямо противоречат тому, что они слышали от своих духовных наставников и читали в богословских трудах.

### А ЧТО ГОВОРИЛ ПРОРОК?

Улемы довольно иезуитски (да простится такое христианское сравнение – просьба воспринимать его просто как характеристику их изворотливости) воспользовались многочисленными и давними спорами о том, кого считать женщиной, на которой можно жениться мусульманину. Казалось бы, первоисточник, то бишь слова пророка Мухаммеда, переданные Кораном, довольно определенно говорит об этом – браки разрешены с женщинами, принадлежащими к «людям Писания», то есть иудейками и христианками. Таких примеров много не только в России и не только в «прогрессивном» XXI веке – истории знакомы случаи, когда даже православные принцессы выходили замуж за мусульман и оставались в лоне своей религии, как Феодора Кантакузина, дочь импера-

тора Византии Иоанна VI и супруга бея Орхана Гази, основателя династии, правившей Османской империей, или Ирина Палеологина, обрученная с Халилем, сыном Феодоры.

Единственным, но непременным условием таких браков всегда было обязательство воспитывать детей как мусульман. Но, как ни «подозрительно это звучит в XXI веке», такая каноническая позиция парадоксальным образом (для тех, кто не знаком с тонкостями ислама – тем паче) на сей день самая прогрессивная – ни католики, ни православные, ни иудеи, к примеру, вообще не разрешают церковный брак с представителями иной религии.

Просто что в Европе, что в СССР и в России, как его правопреемнице, гораздо большую роль играет в жизни общества брак гражданский. И потому, не вдаваясь особо в детали, фетву так негативно и встретили со всех сторон – экстраполировав ее на современную ситуацию в стране, где межконфессиональные гражданские браки весьма распространены. К примеру, в Татарстане, самом мусульманском регионе РФ (если не брать Северный Кавказ), их доля приближается к 30%.

Для чего же тогда вообще совет улемов ДУМ РФ «замутил воду» и подставился под резкую критику, опубликовав такое громкое, но, по сути, бесполезное заявление?

## ЗАЧЕМ И ПОЧЕМУ

Пытаясь как-то обосновать свою позицию, «старцы совета» поясняли, что они пытаются таким образом «защитить ислам именно в России, где он остается религией меньшинства населения, от вымирания», как раз из-за межконфессиональных гражданских браков. Такие союзы, мол, часто распадаются, а дети, как правило, остаются с матерями и потому не получают мусульманского воспитания. Да и вообще в семьях воспитанием детей чаще занимаются именно родительницы. Впрочем, они оговариваются, что к уже заключенным бракам «претензий не имеют», и просто хотели «предостеречь на будущее» своих единоверцев.

Однако эту позицию не разделяют даже представители других исламских религиозных организаций. ДУМ Татарстана заявило о несогласии с позицией улемов – не надо переписывать и домысливать Коран. А верховный муфтий РФ Талгат Таджуддин напомнил, что совет улемов – орган вообще совещательный, и по исламской традиции, не имеющей жесткой вертикальной религиозной иерархии, его решения отнюдь не обязательны к исполнению: «В России более 80 муфтиятов, каждый из которых может иметь свой совет улемов, где окажутся более толковые богословы, разбирающиеся в исламском семейном праве». Зато некоторые радикалы, как раз с Северного Кавказа, поспешили «официально поддержать» фетву, заявляя, что «такие браки никогда и не разрешались – чего их запрещать».

Другие же эксперты указывают на то, что фетва пестрит ссылками на «труды» богословов из таких организаций, которые в России вообще официально признаны экстремистскими и запрещены, как те же «Братья-мусульмане». Так что некоторая доля радикализма или даже экстремизма в таком явно вызывающем и эпатирующем заявлении все-таки «очень даже может быть». И это как раз в нынешнем мире, и без того переполненном конфликтами в том числе и на религиозной почве, совсем не способствует успокоению умов.

* * *

В общем, с какой стороны ни глянь – миссию «мудрых старцев», предохраняющих паству от разжигания злобы и ненависти и находящих мирные решения спорных вопросов, совет улемов ДУМ РФ провалил. Вместо умного разъяснения по на самом деле непростой проблеме получился очередной скандал, бросающий тень на мусульман и весь ислам. Разумно ли, официально признавая, что мусульмане в России – меньшинство, одновременно накалять ситуацию и подбрасывать дрова в огонь?





# ЖИЗНЬ КАК ПОДВИГ

***Вагиз Лотфуллович Яруллин – один из видных представителей мусульманского духовенства, оставивший заметный след в истории духовного возрождения мусульман Самарской области.***

**Идеал ГАЛЯУТДИНОВ**

С раннего детства впитавший в себя духовные ценности ислама, воспитанный на религиозной основе, несмотря на запреты, он сумел сохранить и передать эти традиции свои детям и внукам и до конца жизни оставался преданным своим принципам.

Его жизнь как подвиг. Так отзываются о Вагизе хазрате его современники. Он всегда подчеркивал высокое предназначение человека на земле, как творца добра, милосердия, ответственного за свои слова и поступки перед Всевышним и другими людьми.

В своих проповедях Вагиз Яруллин говорил: «Ин ахсантем, ахсантем ва анфесикем, ва ин эсъагетем фаляха», что в переводе с арабского означает «Творишь ли ты добро, или творишь ли ты зло – все возвратится к тебе сторицей».

С Вагизом хазратом Яруллиным я познакомился в 1984 году в Куйбышеве (ныне Самара), когда меня направили сюда для дальнейшего прохождения службы. Обосновавшись и осмотревшись вокруг, по моей просьбе мы с товарищем – подполковником Маратом Баишевым поехали в мечеть, расположенную на Малом тупике, чтобы навестить имама. Назвать тогда этот небольшой домик мечетью было сложно. Он был приобретен на средства местных мусульман, которые обивали пороги местных властей, чтобы использовать дом для совершения намазов. И вот в результате усилий инициативной группы в 1967 году он стал молельным домом.



Нас тогда встретил высокий мужчина со скромной бородкой и открытой улыбкой. Офисные кабинеты были оборудованы в полуподвальном помещении. Мы представились, коротко рассказали о себе. Кроме имам-хатыба Вагиза Яруллина, в офисе находились еще несколько человек: Галимзян Авзалов, Мунир Вальшин и Вагиз Кадыров. Последний оказался моим знакомым – я учился в одном классе в Нурлате с его братом Мавлюдом, а также в военном училище.

Вагиз Кадыров был правой рукой Вагиза Яруллина и приложил немало усилий, чтобы добиться разрешения на открытие молельного дома.

Мы прочитали короткую молитву «Фатиха», которую по традиции произносят каждый раз, когда входят в чей-то дом.

Вагизу хазрату и другим присутствующим импонировало то, что мы говорим на татарском языке, читаем дуа. До полуденной молитвы еще оставалось немного времени, и за чашечкой чая мы вели дружелюбную беседу.

Вагиз хазрат рассказал о себе. В 1983 году Указом Верховного муфтия он был назначен имам-хатыбом. Родом он был из соседнего нам Аксубаевского района, деревни Старое Ибрайкино. Старше меня на три года. Его отец тоже был имамом.

Послевоенный голод заставил 16-летнего Вагиза покинуть родную деревню, и он оказался в Куйбышеве, устроился станочником на завод имени Масленникова. Затем работал охранником на заводе КАТЭК. Служил в армии. Здесь ему удавалось изыскивать время для изучения исламской литературы, тайно совершать молитвы.

После службы в армии Вагиз уехал в Среднюю Азию. Там он женился на Асия абыстай, с которой прожил 62 года.

Яруллины воспитали замеча-

тельных детей: дочь Санию, сыновей Талипа и Мансура.

Затем Вагиз Яруллин возвращается в Куйбышев и в течение семи лет работает в металлопрокатном цехе КАТЭК, регулярно посещает мечеть, проявляет способности в чтении Корана. И вскоре его назначают имам-хатыбом махалля города Куйбышева.

Разговор, конечно же, коснулся и необходимости строительства Соборной мечети.

Так состоялась наша первая встреча с Вагизом хазратом, которая в дальнейшем перешла в добрые отношения.

Вскоре была построена и Собор-



ная мечеть, в области началось строительство новых мечетей, число которых за время его работы муфтием выросло с 17 до 100.

Большим достижением Вагиза Яруллина было возвращение Исторической мечети.

После увольнения из армии Вагиз хазрат пригласил меня на должность руководителя отдела по связям с общественностью регионального Духовного управления мусульман Самарской области. Работая рука об руку с Вагизом Лотфулловичем в течение пяти лет, я многое о нем узнал и многому у него научился.

Задумали мы написать книгу об истории мусульманских общин Самарской области и заодно посвятить ее 75-летию со дня рождения Вагиза хазрата. В президиуме регионального Духовного управления мусульман Самарской области эту идею одобрили.



Я решил поехать на малую родину Вагиза Яруллина, в деревню Старое Ибрайкино. Это было весной 2009 года. Машину оставили на окраине села и в резиновых сапогах, которые нам принесли из дома его родственники, добрались до его отчего дома.

Нас встретили, как дорогих гостей. На следующий день я встречался с односельчанами Вагиза хазрата, чтобы узнать о нем побольше.

Среди многих, с кем я встретился тогда, был и его одноклассник Асхат Исхакович Тагиров. И вот что он рассказал:

«Хорошо помню, как в 1949 году к нам в седьмой класс пришел учиться один юноша. Классный руководитель Мухтарама Аскарова представила среди других новичков и Вагиза Яруллина. Мы с ним сразу подружились. Вместе вынесли и холод, и голод. Вагиз учился очень старательно. Несмотря на запреты, он после занятий в школе садился за религиозные книги, учил молитвы. В этом ему помогал его отец Лотфулла ага, он был у нас имамом.

В нашем классе ибрайкинцев было семеро, а остальные дети были из разных деревень, поскольку наша татарская школа была единственной в районе.

Теперь мы уже сами стали отцами, дедами. Вырастили и воспитали детей, внуков. Мы гордимся нашим земляком, моим товарищем, сохранившим наши дружеские отношения и по сей день, его служением на пути Аллаха. Да поможет ему Всевышний».

Односельчанка Вагиза Яруллина – Мадина Минвалеевна Нафигуллина (лауреат премии Президента России «Лучший учитель России» с премией в сто тысяч рублей, мать двоих детей и бабушка трех внуков), выражая общее мнение земляков Вагиза хазрата, сказала следующее:

«У нас, татар, есть замечательный праздник Сабантуй. Мы тоже



в своей деревне его проводим. И я, как ведущая, ежегодно объявляю: «А сейчас хочу вам представить самого дорогого гостя, широко известного всем и в Республике Татарстан, и в Самарской области, кавалера ордена Дружбы за труд во благо земли Самарской – муфтия Вагиза хазрата Яруллина и его спутницу жизни, тоже нашу землячку, уважаемую Асия абыстай». Тысячи людей под бурные аплодисменты встречали этих уважаемых людей. Чем же они заслужили такую любовь и уважение своих односельчан и не только? Приведу лишь один пример.

1988 год, март месяц. Меня избрали председателем сельсовета. Проблем в селе хватает, но одна из них беспокоит меня больше всего. Это запущенное состояние наших кладбищ. Нужно было срочно изготовить ограду, а денег в сельсовете нет. Я собрала аксакалов на совет. Один из них – Мирсаит ага Нуруллин говорит: «Мы, доченька, вряд ли решим эту проблему своими силами. Обратись-ка ты к нашему земляку – имаму Вагизу Яруллину. Он – человек отзывчивый, его родители тоже покоятся на этом кладбище. Думаю, он поможет».

Тогда я написала письмо Вагизу Лотфулловичу. И он, действительно, помог. Тех денег, что он выделил, хватило на благоустройство двух кладбищ площадью в 13 гектаров.

От имени всего населения Старого Ибрайкино от всей души хочется выразить благодарность Вагизу хазрату, а также всем тем, кто протянул руку помощи в этом богоугодном деле».

Вагиз хазрат часто говорил, что человек не должен быть нищим, если рядом есть богатый. По законам шариата, богатые люди должны обязательно помогать тем, кто оказался в беде.

Вагиз Яруллин всегда брал меня с собой в дальние поездки на различные совещания, форумы. Помню, как однажды мы – я, председатель махалля Фарид Аюпов и Вагиз хазрат – поехали в Уфу в Центральное Духовное управление мусульман России. На всем протяжении пути – от Самары до Уфы – Вагиз Лотфуллович без перерыва (прервавшись только на чтение полуденного намаза в машине) читал наизусть Коран. Он не был Коран-хафизом, но знал Коран, и не только произношение, но и его толкование – тафсир. А макам его был мелодичным, грел душу.



Хочу сказать о мудрости Вагиза хазрата. Как известно, в 90–2000-е годы мусульманский мир подвергся тяжелым испытаниям – появились разного рода экстремисты – ваххабиты, игиловцы...

Прикрываясь исламистскими лозунгами, новоиспеченные «праведники» творили беззаконие, убивали людей, не разделяющих их точку зрения, повсюду распространяли экстремистскую литературу, вербовали молодежь в свои отряды.

Отголоски этого дошли и до Самарской области. Несколько человек – сторонников «Хизб ут-Тахрир», запрещенной в России экстремистской группировки, привлекли к ответственности, пресекалось распространение агитлистовок, брошюр, призывающих становиться в ряды экстремистов против традиционного ислама, против представителей власти и т. д.

Сложность ситуации заключалась в том, что среди прихожан Самарской Соборной мечети были разные категории представителей мусульман, отличающиеся между собой этнически и принадлежащие к различным мазхабам – религиозно-правовым школам.

Они, в отличие от традиционного ханафитского мазхаба, которому следуют мусульмане России, некоторые формы богослужения понимают по-своему, привычному своим мазхабам (шафигиты, ханбалиты, малакиты). И на этой почве иногда среди верующих возникали некоторые недоразумения. Вагиз хазрат внимательно ко всем прислушивался, анализировал, встречался с представителями разных мусульманских диаспор, разъяснял им необходимость соблюдения тех норм поведения, которые приняты в данной мусульманской умме. Он с осуждением высказывался о людях, чьи деяния наносили ущерб мирному исламу, единству мусльман.

На этой почве была попытка создать в Самаре паралелльный муфтият. Но, благодаря мудрости Вагиза хазрата Яруллина и его соратников, эта попытка была пресечена.

За годы руководства Вагиза хазрата Яруллина никогда не возникало конфликтов на межнациональной и межконфессиональной почве.

У него было много друзей. Он любил детей. При каждой встрече с мальчишками просил их прочитать аяты из Корана, не забывая их потом поблагодарить. Пользовался уважением и среди руководителей местной власти, и среди других авторитетных людей.

К нам приезжали Ахмат Кадыров, Рамазан Абдуллатипов, друг Габибуллы Хасаева, который руководил Попечительским советом при строительстве Соборной мечети и медресе, представитель Президента РФ А.А. Гришин, председатель Госсовета Республики Татарстан Ф.Х. Мухаметшин и другие.

Один из друзей Вагиза хазрата – Фатих Сибагатуллин, депутат Государственной Думы Законодательного Собрания Российской Федерации, доктор наук, сказал так:

«Вагиз Яруллин принадлежит к поколению людей, на чью долю выпала огромная тяжесть лишений в период Великой Отечественной войны, когда семьи, особенно многодетные, отправив на фронт своих кормильцев – взрослых мужчин, оставались наедине с безысходностью в ожидании похоронок.

Радость Победы была омрачена временем послевоенных голодных лет. Детство и юность Вагиза Яруллина и его сверстников – это годы, когда во имя хлеба насущного трудились наравне со взрослыми и на полях, и на фермах, и на заводах. Тем не менее эти люди выстояли, несмотря ни на что.



А Вагиз Яруллин – человек особенный. Он вобрал в себя любовь к труду и способность преодолевать трудности, прилежность в постижении духовных знаний, которые передали ему дед и отец, любовь и доброту, унаследованные от своей матери. Его отличает мудрость руководителя мусульманской общины, спокойствие и рассудительность, когда речь заходит о решении каких-либо конфликтных ситуаций.

Он своим примером духовного служения воспитывал поколения людей. Его сыновья и внуки также пошли по стопам своего отца и деда – стали имамами.

Авторитет Вагиза Лотфулловича заслуженный. Он прошел путь от имама-хатыба мусульманской уммы до муфтия, руководителя такого большого региона, как Самарская область, и до главного Казыя Центрального Духовного управления мусульман Российской Федерации.

Да упокоит душу Вагиза хазрата с миром и воздаст ему Всевышний за его благие деяния на пути Аллаха. Светлая память о Вагизе хазрате Яруллине будет вечно жить в наших сердцах.

## ИСКИТКЕЧ КЕШЕЛЕКЛЕ ШӘХЕС КИТТЕ



Арабыздан, яз кояшыдай, гел елмаеп торган, якты йөзле, киң күңелле, искиткеч кешелекле шәхес китте. Самар өлкәсе «Туган тел» татар җәмгыятенең актив әгъзасы, меценат, эшмәкәр, Яңа һәм Иске Ярмәк авылларын үстерү проектлары инвесторы, Самар дәүләт аграр университетының «Анатомия, акушерлык һәм хирургия» кафедрасы профессоры, биология фәннәре кандидаты. Әхмәтсабир улы Хәйдәр Сафиуллин кебек, тормыш сөючән, тере җанлы, яшәүнең тәмен тоеп, тормышның ямен күрә белеп һәм үзе дә тормышка туктаусыз бәрәкәт өстәп яшәгән кешенең үлеме– ул тетрәндергеч һәм моңа һич тә ышанып булмый.

Яшьтән тормыш буйлап бергә атлаган һәм бергә аралашып, хәлләрне белешеп яшәгән кешеләрне югалту – ул аеруча зур фаҗига. Үзе арабыздан китсә дә, аның мәңге онытылмаслык изгелекләре, якты истәлекләре калды.

Аның исемен телгә алуга, күз алдына шат күңелле, ярдәмчел, кешене тыңлый һәм аңлый белгән, бай табигатьле һәм эчкерсез Хәйдәр килеп баса. Аның белән аралашканда яшәү дәрте артып, тормышка ямь һәм бәрәкәт өстәлә кебек тоела иде.

Хәйдәр Сафиуллин турында никадәр сокланып сөйләсәң дә, аз булыр төсле. Ул хәзер, куе томан артындагы кебек, тоелган киләчәкне дә уңай рәвештә күрә белде. Башка авыллар картаеп, таркалу юлына баскан-да, ул һәрвакытта үзенең туган авылы Яңа Ярмәкне үсеш юлына бастырып, авыл халкында өмет уяту, аларда киләчәккә ышаныч тудыру исәбе белән яшәде. Моны тормышка ашыру, чынбарлыкка әйләндерү өчен ул бернәрсә дә җәлләмәде.

Һәркем үз-үзен генә кайгыртып яшәгән, буталчык заманда да, ул үз авылы, үз халкы өчен янып-көеп яшәде. Өлкәбездә генә түгел, башка төбәкләрдә дә киң танылган, ихтирам казанган галим булса да, ул гади һәм һәркемнең күңеленә якын һәм үз кеше булып яши белде.

Без барыбыз да аның кылган изгелекләре, күпләр тарафыннан аңа әйтелгән рәхмәтләре Аллаһы Тәгалә тарафына ирешеп, урыны оҗмах түрендә булуын телибез. Зур югалту кичергән туганнарының, якыннарының һәм бихисап дус-ишләренең кайгысын уртаклашабыз.

Аны якын күргән, хөрмәт иткән күп санлы замандашлары, дуслары, танышлары исеменнән Фәрид Шириязданов.



*Исмагиль Феткуллов, июль 1995 года*

# ГЛАВНОЕ ДЕЛО ЖИЗНИ

## В МИНУВШЕМ АВГУСТЕ ИСПОЛНИЛОСЬ 75 ЛЕТ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ ИСМАГИЛЯ ФЕТКУЛЛОВА

***Национально-духовное движение последних трех десятков лет вывело на общественную волну самых и деятельных представителей татарского народа. Одним из таких был Исмагиль Бадретдинович Феткуллов.***

**Шамиль ГАЛИМОВ**

В советские годы он проработал на многих ответственных должностях. Благо глубокие знания, полученные в энергетическом техникуме и плановом институте, и особый крепкий характер позволяли делать свою работу основательно. Мы его помним еще с 1970-х годов, с объединения «Горплодоовощторг», где он много лет трудился главным инженером, обеспечивая надежное функционирование большого и сложного хозяйства, который круглый год снабжал «зеленой» продукцией миллионный город Куйбышев.

...Наступила перестройка, и для дела татарского культурного и религиозного движения потребовались люди, воспитанные в соответствующих национальных традициях и готовые взять на себя ответственность за большое дело. Пожалуй, самым большим, даже грандиозным делом самарских татар (наряду с созданием школы «Яктылык») стало строительство Соборной мечети. После непростых событий вокруг будущей мечети (переноса места площадки с Партизанской на улицу Стара-Загора, митингов у кинотеатра «Шипка» против строительства и других) настало время начать работу.

Для этого нужен был человек, который обладает авторитетом, понимает в строительстве, экономике и финансах, и который может стать координатором работ по строительству новой мечети. Вот тогда-то выбор и пал на Исмагиля Феткуллова, который обладал всеми этими качествами. Весной 1992 года он был определен на должность председателя религиозного общества мусульман (тогда единственного в городе) с выполнением основной в тот момент обязанности –ответственного за новостройку. И сразу горячо взялся за работу...

Невозможно коротко рассказать об истории строительства Самарской Соборной мечети, надеемся, когда-нибудь кто-нибудь объективно и подробно напишет об этом. Об условиях, которые существовали тогда, в 90-е годы, и в которых оказалась возможной реализация такого масштабного проекта, о всенародной материальной помощи тысяч и тысяч татар, всех мусульман, представителей других национальностей, содействия администрации Самарской области во главе с Константином Титовым, едином порыве деловых людей, ожиданиях, прежде всего, татарской общественности на приобретение с новой мечетью центра духовной и культурной жизни, и в целом невероятном всеобщем подъеме, который сопровождал период строительства, и всем, что было связано, как мы тогда писали, с главной стройкой самарских татар.

На строительстве Самарской Соборной мечети был задействован большой коллектив во главе с попечительским советом: Габибулла Хасаев, Вазых Мухаметшин, Расим Вальшин, Ринат Садыков, Джамиль Валиуллин и многие другие. Мусульманская община во главе с Вагизом хазратом Яруллиным оказывала работам общественную и всякую другую поддержку.

Но, начиная с лета 1992 года, непосредственно на объекте «сидел» Исмагиль Феткуллов. Каждый день, в будние и выходные дни, и зимой, и летом... В сапогах и рабочей одежде он постоянно ходил по стройплощадке и этажам строяще-

гося здания, вникал в ход работ, следил за качеством, соблюдением технологических процессов, обеспечивал прием и распределение строительных материалов, техники и механизмов, координацию между различными строительно-монтажными организациями, выполнявшими работы на строительстве Соборной мечети… Приходилось также заниматься другими мелкими и крупными вопросами, которые обычно возникают на строительной площадке: по ходу работы менять проект, искать подрядчиков, находить решения из различных сложных ситуаций.



*В.Г. Мухаметшин, И.Б. Феткуллов, Д.А. Валиуллин, 1998 г.*

Двадцать один год назад, 28 ноября 1999 года, состоялось официальное открытие Самарской Соборной мечети. Но и после этого предстояло выполнить большой объем по отделке внутренних помещений и фасада здания, благоустройству территории, построить медресе и вообще наладить работу мечетного комплекса. Указанные работы были завершены к 2004 году.

И только после этого Исмагиль Феткуллов с чувством исполненного долга отправился на другой ответственный участок – восстановление Исторической мечети на улице Алексея Толстого. Его бесценный опыт мог быть применим на новом объекте. Но, к сожалению, болезнь не позволила Исмагилю Бадретдиновичу плодотворно поработать здесь – он был вынужден уйти на пенсию и 8 ноября 2011 года окончил свой земной путь.

Все, кто знал И.Б. Феткуллова, помнят его огромную работоспособность, компетентность, а когда нужно было – твердый характер, требовательность, упорство и настойчивость. И все это ради главного дела, которое он сделал в жизни для людей, своего народа, общества и страны. С чем человек и вошел в современную историю духовного возрождения.



*Слева направо – Равиль Ягудин и Исмагиль Феткуллов обсуждают дальнейший план работ. Июль 1997 г.*

# Әйләнә дә сәхнә, әйләнә...

## КАМЫШЛЫ АВЫЛЫ ТАТАР ХАЛЫК ТЕАТРЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНА

**Атлас ТӨХФӘТОВ**



Безнең илебездә театр сәнгате өчен уңай шартлар тудырылган, шуның өчен дә театр коллективлары һәм театр сөючеләрнең саны елдан-ел арта.

Бүгенге көндә  безнең илебездә 600дән артык профессиональ һәм 4000нән артык үзешчән театр коллективлары бар. Алар һәр көнне үзләренең мактаулы һәм авыр вазифаларын сәнгать сөючеләр алдында акларга тырышалар. Шушы коллективлар арасында безнең Камышлы районы Мәдәният йортының татар халык театры коллективы да аерым бер урын алып тора, якташлары алдында үзенең вазыйфасын үти, авыл эшчәннәрен театр сәнгатенә өнди. Быел инде театрыбыз оешуга 100 ел. Шушы уңайдан сезне, хөрмәтле укучылар, театр коллективының мактаулы тарихы белән таныштырырга булдым.

Камышлы авылы Мәдәният йорты каршындагы театр коллективы 1920 елда оеша. Аның беренче артистлары авылның актив яшьләре, беренче комсомоллары булды: **Миргасыйм Ханнанов, Бибинур Мифтахова, Хөмәйрә Вафина, Камал Зарипова, Хөршидә Минһаҗева, Зәкия Гарипова, Хуҗи Шәйхетдинов, Хәдичә Йосыпова.** Ул вакытта махсус клуб булмау сәбәпле, репетицияләрне укытучы Әгъләә Яруллин өендә үткәрәләр, коллективның беренче җитәкчесе дә ул була, ә тамаша мәктәптә куела.

Бу чорларда куелган спектакльләр агитацион характерда булалар. Сәхнәдә куелган пьесалар аркылы кулакларны, муллаларны, буржуаз сыйныф вәкилләре булараk, кешеләрне эксплуатацияләргә, җәберләргә, алдарга, шәхси материаль ихтыяҗлар белән генә яшәргә гадәтләнгән кешеләр икәнлеге фаш ителә. Коллектив үзенең чыгышы белән тирә-як авылларга да бара. Аларга декорация һәм реквизитларны үз җилкәләрендә күтәреп, җәяү барырга туры килә. Үзешчәннәрне барлык җирдә дә яхшы каршылыйлар, һәм алар үзләренең чыгышлары белән зур уңышларга ирешәләр.

1930 елда Камышлы авылында клуб бинасы салына һәм үзешчәннәр өчен уңайлы шартлар тудырыла, коллективның да мөмкинлекләре киңәя. 1930-34 елларда коллективның җитәкчесе булып Ленин орденына ия булган, КПСС әгъзасы, авыл укытучысы **Фатыйх** ага **Бикашев** эшли.

Һәвәскәр артистлар уңышлары белән рухланып, тагын да эчтәлеклерәк әсәрләр сәхнәләштерәләр. Ул елларда коллектив репертуарында Г. Камалның "Беренче театр", М. Фәйзинең "Галиябану", Ш. Камалның "Хаҗи әфәнде өйләнә" һәм башка татар классикларының, шулай ук туган-даш республика язучыларының әсәрләре керә. 1934-36 елларда коллективның җитәкчесе һәм төп рольләрне башкаручы, сугыш инвалиды **Кыям** ага **Хәсәнов** була.

Сугыш еллары алдыннан М. Фәйзинең "Галиябану" драмасы киң тарала. Галиябану ролен коллективның һәвәскәр артисты **Хәдичә Мифтахова** оста итеп башкара. Ә Кыям ага Хәсәнов армия сафларына алынгач, аның эшен **Зәки** ага **Бадыков**, **Шәрифә** ханым **Вәлитова** һәм башкалар дәвам итә.

Бөек Ватан сугышы елларында үзешчәннәр Р. Ишморатның "Кайту", Т. Гыйззәтнең "Бишбүләк", "Төнге сигнал", "Серле казна", "Чаткылар" кебек Ватанга чиксез мәхәббәт, совет халкының патриотизмы күрсәтелгән, дошманга каты нәфрәт белән сугарылган әсәрләрне сәхнәгә куя. Шул спектакльләр исәбенә коллектив 1942  елда оборона фондына 28 мең сум акча җибәрә.

Сугыштан соңгы елларда коллективка бик күп талантлы һәвәскәрләр өстәлде: **Газый Мостафин, Шәмсебәдәр Минһаҗева, Ганни Мостафин, Мөхтәбәр Төхбәтшин, Халит Минһаҗев, Гайфи Шәвәлиев, Мәрьям Якупова** һәм башкалар. Үзешчәннәр татар халкы тормышының төрле якларын күрсәткән күп пәрдәле, эчтәлеге бай булган, катлаулы яңа спектакльләр әзерлиләр. Т. Гыйззәт "Чаткылар", "Изге әманәт", "Төнге сигнал", "Чын мәхәббәт", "Бишбүләк", М.Фәйзинең "Асылъяр", "Галиябану", "Ак калфак" драмалары куела. Шулай ук еш кына К. Тинчуринның "Зәңгәр шәл" музыкаль әсәре сәхнәләштерелә.

1960-1970 елларда театр коллективы татар халкының яңа тормышын яктырткан, социалистик җәмгыять төзү, бөек коммунизм, патриотизм, кешелеклелек, гуманизм  идеаллары белән рухланган кешеләрне һәм, киресенчә, җәмгыятебезгә чит булган ялкауларны, әрәм тамакларны фаш итәрдәй әсәрләр белән чыкты. Х. Вахитның "Карлыгач канат кага", Ю.

Әминевнең “Гөлчәчәк”, “Язылмаган законнар”, “Өти балак”, Т.Закировның “Яучылар”, Г. Насыйриның “Яшел эшләпә” һәм башка спектакльләр сәхнәдә куела.

1970 елның язында, коллективка зур ышаныч белдерелеп, Башкортостан драматургы Ә. Атнабаевның “Ул кайтты” әсәре белән Куйбышев өлкәсенең 8 нче “Театраль яз”ында катнашу мөмкинлеге бирелде. Бу спектакль өчен безнең коллектив Диплом белән бүләкләнде.

Шул ук елның декабрь аенда коллектив үзенең СССРның 50 еллыгына багышланган иҗади отчеты белән Куйбышев шәһәренә чакырылган иде. Безнең спектаклебез Куйбышев шәһәренең опера һәм балет театрында куелды. Шундый зур залда (анда бер меңгә якын кеше сыя) спектаклебез куела, дигәч, бик шүрләгән идек. Шуңа бөтен коллектив бу очрашуга бик озак, бик җентекләп, зур җаваплылык тоеп әзерләнде.

Ул көнне барлык артистларыбыз да күтәренке күңел, илһамлы итеп уйнадылар. Мактап әйтәсем түгел, ул вакытта артистлар үзләренең рольләрен профессиональ итеп башкарулары белән барлык Куйбышев татарларын да, рус милләтендәгеләрне дә шаккатырдылар. Спектакль тәмамлангач, барысы да, аягүрә торып, озак кына кул чапты, сәхнәгә килеп, кулларыбызны кыстылар, кат-кат рәхмәтләр әйттеләр, бәйләм-бәйләм чәчәкләр бүләк иттеләр. Ул көнне зал шыгрым тулы иде, Куйбышев шәһәренең барлык татары җыелган диярсең. Ә менә халыкка безнең турында информация бирүдә үзебезнең авылдашыбыз, “Волжская коммуна” газетасының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире, журналист Лилия Шәфигуллина бик зур ярдәм итте. Безнең спектаклебез булыр алдыннан “Волжская коммуна” газетасы битләрендә аның “Театр из Камышлы” дигән мәкаләсе чыккан иде. Шуннан соң Камышлы авылы драмколлективының даны бик күп төбәкләргә таралды.





Коллективыбыз, үзенең көченә ышанып, тагын да ныграк эшли башлады, катлаулы әсәрләрне сәхнәләштерде. Ул елларда Әнгам Атнабаевның һәм Сәет Шәкүровның күп кенә әсәрләре сәхнәгә куелды. Менә шулай тырышып эшләгәнебез өчен 1972 елның июлендә, РСФСР культура министры приказы буенча, безгә татар халык театры дигән мактаулы исем бирелде. Бу вакыйга безнең авыл, район, өлкә өчен генә түгел, ә бөтен татар милләтенә дә бик зур шатлык булды.

Уйлап карасаң, халык арасында үскән авыл эшчәннәреннән торган драмколлективның халык театры дәрәҗәсенә кадәр үсүе барыбыз өчен дә зур шатлык һәм горурлык иде. Бу вакытта театрның эшендә актив катнашып, аның абруен күп төбәкләрдәге татарлар арасында тараткан артистларның да исемнәрен атыйсы килә. **Мөхтәбәр Төхбәтшин, Шәмсебәдәр Минһаҗева, Ганни Мостафин, Зөбәрҗәт Шәрипова, Зөләйха Шәкүрова, Җинан Вафина, Наил Гайнуллин, Әсхәт Сыйтдиков, Фәния Мусина, Фәнүзә Хәлиуллина, Нажия Шарапова, Флера Әхмәтвәлиева, Асия Төхфәтова, Мәймүнә Вәлитова,**

**Әсхәт Баһаветдинов, Фәүзия Хәлиуллина, Гадилә Гарифова, Роза Гафиатуллина, Тәскирә Гайфиева. Ә спектакльләрне гел Хәйдәр Галиуллин алып барды, ягъни суфлер эшен башкарды. Ганни Мостафин барлык декорацияләрне ясады.**



Бу вакыйга турында “Волжская коммуна”, “Сельская жизнь”, “Медицинская газета”, “Советская культура” газеталары яздылар, һәм без бик күп кешеләрдән тәбрикләү сүзләре ишеттек.

1973 елда бөтен ил буенча СССРның 50-еллыгына багышланган халык театрларының смотрлары үткәрелде. Бу тантанага без С.Шәкүровның “Тормыш бусагасында” дигән балалар тәрбияләү темасына багышланган пьесасы буенча спектакль әзерләдек. Өлкә смотрында лауреат исеменә лаек булып, май аенда Ульяновск шәһәрендә Бөтенроссия смотрында катнашып, дипломант исемен дә алып кайттык.

80нче елларда коллектив яңа әсәрләрне сәхнәләштерде. Алар арасында Әблиевның “Шәмсекамәр”, Ю.Әминовның “Минем җинаятем”, “Сатучылар”, “Язылмаган законнар” пьесалары бар иде.

Безнең һәвәскәр артистларыбыз сәхнә яратучы, чын күңелләре белән сәхнәгә бирелгән кешеләр иде. Алар һава шартлары нинди булуга карамастан, эштән арып-талып кайтканнан соң, репетицияләргә йөрделәр, төн йокыларын, исәнлекләрен жәлләмичә, ачык машиналарга,



тракторларга утырып, ерак авылларга барып, спектакльләр куйдылар. Ул вакытта Кләүле һәм Камышлы түрәләре безгә ярдәм кулы суздылар. Һәвәскәр артистлар түгел, хәтта режиссерлар да бер тиен акча да алмыйча эшләделәр.

Халкыбыз театрыбызның эшләрен бүгенге көнгә кадәр бик яратып карый. Нинди генә көнне аның спектакльләре куелса да, Мәдәният йорты шыгрым тулы була. Телевизордан нинди генә спектакльләр караса да, профессиональ артистларны яхшы каршы алса да, безнең Камышлы халкы үзенең халык театрын бик нык ихтирам итә. Нигә соң шулай? Чөнки аның спектакльләрендә халык белән эшләгән, үзенең хезмәтен үтәгән, халыкка якын булган авыл кешеләре, алдынгы эшчәннәр катнаша. Шундый берничә кеше турында язып үтәм. Мәсәлән, **Сәгыйть ага Галиуллин, Мөхтәбәр ага Төхбәтшин, Ганни абый Мостафин, Зөбәрҗәт апа Шарипова, Шәмсебәдәр апа Минһаҗева һәм башкалар.**

Мөхтәбәр ага һәм Бәдәр апа турында бигрәк тә күп мактау сүзләре әйтәсе килә. Алар безнең коллективта 50 елдан артык спектакльләрдә катнаштылар. Алар безнең сәхнә ветераннары иде. Үзләре олы яшьтә булуларына карамастан, йөрәкләре һәм күңелләре яшь иде. Икесе дә театр эшенә кагылганда, бигрәк тә башка авылларга чыгарга туры килгәндә, бу эшкә зур җаваплылык, әзерлек белән карадылар. Өендә эшләнмәгән эше каламы, мичендә пешкән, ләкин ашамаган бәлеше, өе тулы кунак буламы, бу кешеләр репетицияләргә, спектакльләр куелганда төгәл вакытына килеп җитәләр иде. Бу яктан алар яшьләр өчен үрнәк булып тордылар. Безнең коллективта күп хатын-кызлар уйнады, ә Шәмсебәдәр апа Минһаҗева кебек озак уйнаучы булмады. Монда аның театрга булган мәхәббәте белән бергә, яхшы, басынкы характеры да зур роль уйнады. Ул, кайсы хатын-кызлар кебек, юк-барга чәпчеми, берәр нинди конфликт килеп чыкса, аны уен-көлкегә борып, тиз генә барысын да җайлый.





Барлык артистлар да менә шулай эшләренә җаваплылык белән карарга өйрәнсеннәр иде. Бу инде коллективның җитәкчеләренә эшләргә җиңелрәк булачак, һәм коллективның уңышлары тагын да артачак, дигән сүз.

Аларның һәрбер чыгышы тамашачылар өчен һәм коллективның үзе өчен зур шатлык, бәйрәм кебек иде, чөнки авыл тамашачыларына профессиональ артистларны Камышлыда карау бәхете бик сирәк була иде бит.

Шуңа күрә дә безнең коллектив зур сәнгатьнең кечкенә генә бер өлешен үзебезнең авылдашларыбызга җиткерүләрен төп бурыч итеп санады.

Бу мәкаләмдә театрның соңгы еллардагы тарихы турында яза алмадым. Шулай да, безнең Камышлы авылы татар халык театрына мактаулы исем бирелде икән, бүгенге көндә дә театр коллективы бу исемгә лаек булырга тиеш. Камышлы татар халык театрының бүгенге режиссеры **Гүзәлия Шакировага** һәм барлык һәвәскәр артистларга исәнлек, шәхси тормышларында бәхет, иҗади уңышлар телим.



# 50 ЕЛ УЛ – ОЛЫ ЮЛ...

***Камышлы районы Иске Ярмәк авылының атаклы “Ак каен” халык фольклор ансамбле әле күптән түгел генә кырык биш еллык юбилеен уздырган иде кебек, инде 5 ел вакыт үтеп тә киткән. Быел ул үзенең 50 еллыгын билгеләп үтә. Бу истәлекле дата уңаеннан без ансамбльнең һәм аның балалар түгәрәге җитәкчеләре Наил Галимуллин һәм Айгөл Галиуллина белән әңгәмә корып алдык.***

**Алия АРСЛАНОВА**

**- Наил абый, “Ак каен” ансамбленә – 50 ел. Бу күпме әллә азмы?**

- Кеше гомере өчен бу бик аз, ә менә ансамбль өчен – тулы бер чор, олы юл. Шул дәвердә ул “халык” исеменә ия булды, өлкә, төбәкара һәм Бөтенроссия фестиваль-бәйгеләрендә дипломнар һәм бүләкләр яулады. 2012 елда “Ак каен” V Бөтенроссия “Түгәрәк уен” татар фольклоры фестиваленең Гран-при бүләгенә ия булды. Бу казанышлар – ансамбльнең һәр артистының тырышлыгы нәтиҗәсе.

**- Соңгы биш елда ансамбль яңа кешеләр белән дә тулыланган икән...**

- Әйе, төп составка (Наил һәм Оркыя Галимуллиннар, Ринат һәм Диния Сәгыйровлар, Әлфия Баһаутдинова, Әсгать Сәгыйров, Гөлчирә Вагыйзова, Айгөл Галиуллина, Динар Гарипов) Ришат һәм Гюлшан Ибраһимовлар, Илшат Галимов, Әюп Минһаҗевлар килеп кушылдылар. Берничә ел элек оештырылган “Яшь ак каен” төркеменә яшьләрнең бик теләп йөрүе киләчәгебезгә өмет тудыра.

**- Ансамбльнең туган көнен һәрвакыт бәйрәм концерты белән билгеләп үтәсез. Бу юлы да шулай булдымы?**

*- Аллага шөкер, бәйрәм программасы әзер инде. Тик пандемия вазгыяте быелгы юбилейны тамашачылар белән бергә билгеләп үткәрергә мөмкинлек бирерме–юкмы, белмим. Хәлләр яхшыргач, һишиксез, тамашачыларыбызны концертка чакырырбыз, дип өметләнәбез.*



***Камышлы районы башлыгы Рафаэль Баһаутдинов Наил Галимуллинны котлый. 2015 ел***

**- Пандемия дигәннән, ул мәдәни чараларны интернет челтәренә “куып кертте”. Сез онлайн-чаралар уздырасызмы?**

*- Чынлап та, соңгы тапкыр “реаль режим”да Казанда узган “Уйнагыз, гармуннар!” һәм “Түгәрәк уен” фестивальләренең гала-концертында катнашкан идек. Шуннан соң “дөньяга” чыкканыбыз юк әле.*

*Ә менә онлайн-чараларда катнашып торабыз. Мәсәлән, күптән түгел “Балан җыю” йоласын видеога төшереп, социаль челтәрләрдә урнаштырдык. Авылдашлар да , читтә яшәүче милләттәшләребез дә бик күп җылы сүзләр язды.*

*Шулай ук VII региональ “Россия йөрәгендә туганнар” һәм Халыкара “Мирас” татар мәдәнияте фестивальләрендә катнашу өчен “Кыенлыклар аша - Җиңүгә” дип аталган программабызны видеога төшереп, оештыручыларга җибәрдек. Анда ир-егетләрне сугышка озату, хатын-кызларның кул эшләре эшләүләре, сугыш бетү хәбәре килгәч, күңел ачу күренешләре чагылдырылды.*

**- “Балан җыю” йоласын**



***Казанда «Уйнагыз, гармуннар!» фестивалендә***



***«Каен сагызы кайнату» күренеше***

**күрсәттек, дисез. Гомумән, сез татар халкының бик күп йолаларын сәхнәгә чыгардыгыз.**

*- Әйе, ансамбльнең репертуарында “Печән өмәсе”, “Боз китү”, “Каз өмәсе”, “Солдатка озату” кебек җырлы-биюле күренешләр байтак.*

*Мәсәлән, 2014 елда Болгар тыюлыгында узган фестивальдә “Ярмәктә аулак өй” күренешен тәкъдим иттек. Яңа программада татар халкының онытылган “Бияләй ыргытыш”, “Талпан” уеннарын уйнап күрсәттек. Барысына да таныш булган “Йөзек салу” уенын үзебез уйлап чыгарган такмаклар белән башкарган “Канат җибәрү” уенын жюри әгъзалары югары бәяләде. “Ярмәкчә сербиянка” биюе дә, минемчә, берсен дә битараф калдырмады.*

**- 2018 елда Ульян өлкәсенең Иске Кулатка авылында үткән “Түгәрәк уен” фестивалендә “Ак каен” ансамбле махсус бүләккә ия булды, бугай?**

*- Әйе, ансамбльгә Россия гаскәрләренең Сириядәге хәрби операциясе вакытында һәлак булган Россия Герое Рәфәгать Хәбибуллин истәлегенә багышланган махсус бүләк тапшырылды.*

**- Анда нинди программа белән чыгыш ясаган идегез?**

*- Каен тузыннан сагыз кайнату йоласын күрсәттек. Моның серләре белән авылда калган бердәнбер сагыз кайнатучы Рамилә Вәлиева уртаклашты. Бу эш шактый катлаулы булып чыкты. Без, урманга чыгып, туз җыйдык, чистарттык-вакладык. Сагыз әзер булганчы, җырлап-биеп, такмаклар әйтеп, төрле халык уеннары уйнап, үзебез белән алып килгән самавырдан чәй эчеп тә өлгердек. Ахырда әзер сагыздан “бармак”лар ясап, матур итеп төрдек. Фестивальгә дә шул сагызны алып барып, жюри әгъзаларына, балаларга тараттык. Сәхнәдән сагыз кайнату йоласы тулысынча күрсәтелде һәм шулай ук җыр-биюләр белән үрелеп барды.*

**- Айгөл ханым, сез “Ак каен” ансамбленең яшьләр төркемен тәрбиялисез. Барлыгы ничә бала йөри?**

*- Бүгенгә 14 бала шөгыльләнә. Яшьләрнең милли гореф-гадәтләребез, татар халык җырлары белән кызыксынуы куандыра. Алар төп ансамбль белән бәрабәр, фестивальләрдә, бәйрәмнәрдә*



*Бахчысарайда «Түгәрәк уен» фестивалендә, 2016 ел*







*катнашалар. Авылда Сабан туе, “Сөлге җыю”, “Каз өмәсе” кебек йолалар, бәйрәм концертлары яшьләребез катнашыннан башка үтми.*

**- Димәк, өлкән буынга яхшы алмаш үсә?**

*- Кызганычка, балалар үсәләр, шәһәргә укырга китәләр дә шунда төпләнеп калалар. Бу безнең генә түгел, бөтен авылларның проблемасы инде.*

*Шулай да балаларның “Яшь ак каен” төркеменә йөрүләре эзсез калмас, күңелләрендә милли тәрбия орлыгы булып, шытып чыгар, дип өметләнәбез.*

*Бәлки, туган авылларына кире кайтучылар табылыр, киләчәктә шулар Мәдәният йортыбызны гөрләтер әле.*

**- Ә “Ярмәк вагы” бүген күбесенчә сәхнә биюеме?**

*- Юк, бездә бер туй, бер тантана да бу биюдән башка үтми. Хәтта авылыбыз яшьләре кичке дискотекага җыелганда да “вак”ка басмыйча таралышмыйлар.*

**- Айгөл ханым, Наил әфәнде, әңгәмәгез өчен рәхмәт. “Ак каен”ның алтын юбилее котлы булсын! Ансамбльгә киләчәктә дә иҗади уңышлар теләп калабыз.**








# “ТУГАН ЯК” – МИЛЛӘТЕБЕЗ САГЫНДА



*«Ак калфак» оешмасының Иске Усман авылы бүлекчәсендә токмач кисү буенча мастер-класс*

***Ике ел элек Камышлыда “Туган як” дип аталган иҗтимагый оешма барлыкка килгән иде. Аның президенты Раилә Сафина, директоры Рөстәм Хисмәтов һәм оешма активистлары туган якны өйрәнү, нәсел шәҗәрәләрен төзү һәм үстерү, гаиләдәге элемтәләрне һәм буыннар бәйләнешен ныгыту гамәлләрен оешманың төп бурычлары итеп алганнар. Ике ел эчендә бу юнәлештә байтак эшләр башкарылган да инде.***

**Алия АРСЛАНОВА**

Мәсәлән, Камышлы район үзәгендә “Ак калфак” хатын-кызлар җәмгыяте (җитәкчесе – Рушания Диндарова) булдырылган. Оешма активистлары милләтебезне саклап калу, үсеп килүче буында ана телен, татар халкының гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен өйрәнүгә кызыксыну уяту юнәлешендә зур эшчәнлек алып бара. Мәсәлән, мәктәптә “Татар ашлары-ризыклары көннәре” уздыралар, яшүсмер кызларны милли ризыклар пешерергә өйрәтәләр.

– *Балалар – милләтебезнең киләчәге. Шуңа да оешмабыз яшьләр белән эш алып баруга зур игътибар бирә. Күптән түгел шәҗәрә бәйгесе уздырдык. Мәктәп балалары үз гаиләләренең нәсел агачларын төзеделәр. Анда, әби-бабаларының исемнәреннән башка, нинди һөнәр ияләре булуы, кайда эшләүләре турында да язылган. Бөек Ватан сугышында катнашкан, тылда хезмәт иткән туганнары турында да мәгълүмат бар. Балалар, һичшиксез, бик зур эш башкарып чыктылар. Бу юнәлшетә эшебезне дәвам итәчәкбез, эпидемиологик вазгыять яхшыргач, нәсел бәйрәме дә оештырырбыз, дип өметләнәбез.*

*Киләчәктә балалар һәм яшүсмерләр, өчен башка төрле бәйгеләр, спорт чаралары, фестивальләр, дини конференцияләр һәм мастер-класслар уздырырга ниятлибез,* – дип сөйли Раилә ханым.

“Туган як” оешмасы районның топонимик (географик атамалар) электрон картасын булдыру өстендә дә эш алып бара. Шактый авылларда активистлар тырышлыгы белән чишмәләрнең, елгаларның, калкулыкларның, урамнарның һәм башка географик объектларның исемнәре, аларның ничек барлыкка килүе турында язып алынган.

– *Географик атамалар – шушы җирләрдә яшәүче халыкларның иң кыйммәтле һәйкәлләредер. Чөнки алар нинди телдә булуына карап, бу җирләргә кайсы милләт кешеләре беренче килеп утыруын күрергә була. Һәр авылның, һәр урамның да үз тарихы бар, һәм без аны белергә, балаларыбызга сөйләп, буыннан-буынга тапшырып килергә тиешбез,* – дип аңлата Раилә Нәгыйм кызы. Электрон карталар авыллар китапханәләрендә сакланачак, дип белдерә ул.




***Камышлы районы топонимикасы номинациясендә 1 урын яулаган Рәфис Гыйззәтов***



***Кыстыбый пешерү буенча мастер-класс***




***«Туган як» конкурсы призерлары***


Рөстәм Хисмәтов (сулда) «Туган як» бәйгесендә


Раилә Сафина Камышлы районының атказанган шәхесе Атлас Мөхтәбәр улы белән

Җитәкче сүзләренә караганда, авыл зиратларында элек җирләнгән кешеләрнең исемлеге дә булдырылачак һәм киләчәктә дә алып барылачак. Кызганычка, Камышлыда элек зират дәфтәре булмаган. Оешма активистлары җирләнгән кешеләрнең исем-фамилияләрен язып алып, электрон картотека төзегәннәр. Ә кайбер авылларда, зиратлар чистартылмау сәбәпле, бу эш кыенлаша.


Раилә Сафина мәктәп укучылары белән


Раилә Сафина (уңда) Нурания Абзалова белән

Быел оешма "Туган як" дип аталган зур бәйге уздырган. Төбәкне өйрәнүгә юнәлтелгән бу чарада яше дә, карты да катнашкан.

*– Бәйге "Тарихның борынгы чорлары" (1917 елга кадәр), "Хәзерге заман тарихы", "Нәсел шәҗәрәләре", "Якташлар", "Этнография", "Туган як табигатен өйрәнү", "Хәрби тарих" һәм "Камышлы районының топонимикасы" номинацияләрендә узды. Анда Камышлы авылының "Березка" һәм "Улыбка" балалар бакчалары сабыйлары һәм район авыллары мәктәпләрендә укучы балалар актив катнашты. Моның өчен тәрбиячеләргә, укытучыларга һәм ата-аналарга зур рәхмәт.*

*Жюри әгъзалары күмәк эшләрне аерым билгеләп үттеләр. Мәсәлән, Камышлы мәктәбе укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлары турында бай мәгълүмат туплап, китап бастырып чыгарганнар. Балыклы мәктәбе балалары «Хәрби һәм хезмәт даны» музее буенча проект әзерләгәннәр. Ә Камышлы коррекция мәктәбе укучыларының проекты уку йортының беренче директоры Абдулла Акчурин тормышына, аның хәрби һәм хезмәт елларына багышланган иде.*

*Өлкән төркем бәйгечеләренең эшләре дә мактауга лаек. "Якташлар" номинациясендә I урынны яулаган Нурания Абзалова Сәләй Вагызов музей-йорты буенча кызыклы материаллар, хатларын тәкъдим итте. Ә Рәфис Гыйззәтов Дәүләткол авылының 70тән артык топонимнарын язып алган. Зөлфия Хисаметдинова да Иске Усман авылы топонимнары исемлеген булдыру буенча зур эш башкарган. Алар "Камышлы районы топонимикасы" номинациясендә I һәм II урыннарга лаек булдылар.*

*Проектны тормышка ашыруда район администрациясе, Камышлы мәктәбе укытучылары һәм китапханә мөдирләре зур ярдәм күрсәттеләр. Аларның барысына да олы рәхмәтебезне җиткерәбез,* – дип сөйләде Раилә Сафина.


Раилә Сафина, Рөстәм Хисмәтов, Рушания Диндарова

"Туган як" оешмасы өлкәнең грант проектларында да катнаша. Киләсе елга да планнары зурдан – Сок елгасын чистартып, туристик маршрут ясарга, шулай ук Камышлы янындагы елга буен төзекләндерергә хыялланалар икән. Ике ел дәверендә шундый зур эшләр башкарган оешманың бу ниятләре дә тормышка ашыр, дип өметләнәбез һәм милләттәшләребезгә изге эшләрендә уңышлар теләп калабыз.





*Хасянзянов – справа*

# ВОЛШЕБНЫЙ СКАЛЬПЕЛЬ АБДУЛХАКА ХАСЯНЗЯНОВА

***Наверное, потребуется около страницы, чтобы перечислить все СМИ, порталы и сайты, которые в конце октября 2020 года опубликовали горестную весть о безвременной кончине заведующего хирургическим отделением Самарской областной детской клинической больницы им. Н.Н. Ивановой, ведущего детского хирурга Самарской области, отличника здравоохранения Российской Федерации Абдулхака Касымовича Хасянзянова. Откликнулся на это печальное событие даже Самарский рыболовный портал: «Парни, склоните головы. Умер ведущий детский хирург нашей области А. Хасянзянов». А на добрые слова о нем, которые обнародовала в своем инстаграм-профиле nadiakostmirova, пришло 474 положительных отзыва. Еще около 250 человек, прочитав сообщение о смерти хирурга, вывешенное на страничке сообщества ГБУЗ СОДКБ им. Н.Н. Ивановой в соцсети «ВКонтакте», выразили свои эмоции словами признательности ему и соболезнования – родным.***

**Рашид ШАКИРОВ**

Если высказывания этих людей, оглушенных новостью, соединить с присланными еще при жизни Абдулхака эфенди письмами и сообщениями родителей тех детей, которых Хасянзянов буквально «вырывал» из лап смерти, то получится повесть о настоящем хирурге малолетних (в том числе «маломесячных» и «малодневных») пациентов. Но повесть для журнала – «неформат», поэтому поступим по-другому. Сначала выделим группу эпитетов, которыми самарцы (и не только они) награждали нашего героя как профессионала.

Итак, вот эти определения: «хирург с золотыми руками», «хирург от Бога», «замечательный заведующий, хирург и человек», «самый лучший специалист в своем деле», «талантливый и самоотверженный врач», «легендарный детский хирург», «знаменитый хирург», «Хирург с большой буквы», «классный врач», «опытный и быстрый врач», «великий хирург», «дорогой наш волшебник» и др.

Многочисленные авторы этих эпитетов подтверждают точность и корректность своих слов описанием ситуаций, в которые попадали их дети и выбирались оттуда благодаря умениям, опыту и смелости Хасянзянова. Поэтому приведем некоторые выдержки из аргументации родителей детишек: «Три операции, первая – на вторые сутки с рождения. Полгода в реанимации самарской больницы. Только благодаря Вам наш внук жив и радует своими успехами».

Это были слова бабушки из Тольятти, а теперь слово дадим другой жительнице Автограда: «Вы сделали такую микроскопическую операцию на седьмом дне жизни нашему сыну, я благодарю Вас бесконечно. Ему поставили диагноз «непроходимость 12-перстной кишки» еще в утробе, на 33-й неделе – кесарево, и ребенок оказался в реанимации, потом обследование и операция, после

лежали еще два месяца. Сейчас нашему сыну семь месяцев, на УЗИ – все в порядке». Ей вторит еще одна мама-тольяттинка: «Александр Касымович (так к нему обращались официально. – Прим. Р.Ш.) спас нашего сына в июне 2019 г. В Тольятти не смогли поставить правильный диагноз, а в Самаре сразу определили доброкачественную опухоль в брюшной полости и сделали операцию».

В апреле 2019 года появился такой отзыв о действиях Абдулхака Касымовича за операционным столом: «Шестнадцать лет назад он прооперировал моего мальчика на следующий день после рождения. Ситуация была критической. Диагноз: ложная



*Родители А.К. Хасянзянова*

диафрагмальная грыжа. Ребенок не мог дышать самостоятельно».

А вот эти строчки написаны более пяти лет тому назад: «Моя дочка оказалась на операционном столе в Первой детской на вторые сутки после появления на свет. Она родилась недоношенной с диагнозом «атрезия (врожденное недоразвитие) пищевода». Ксюша весила всего два килограмма, когда ее оперировал Абдулхак Касымович. Ребенка увезли из роддома, где я осталась после кесарева сечения, и я понятия не имела, что происходит с моей дочерью. Но сегодня я точно знаю, что она была в надежных руках».

Родители трехлетнего сызранца Мирона в соболезновании по поводу кончины хирурга отмечают, что Хасянзянов помогал малышу поддерживать стабильное состояние до лечения в Германии, а во время операции вывел первые стомы (отверстия) и сохранил кишку такой, какая она есть, без лишних резекций.

Полон подробностей борьбы героя этой статьи за жизнь ребенка материал известного самарского блогера М. Комковой под названием «Весь кишечник прощупал пальцами». Блогер, она же мама, изложила, как хирург в 2007 году дважды вытащил ее ребенка с того света и как двухлетняя на тот момент дочка справилась с заболеванием (прободная язва кишечника), от которого умирает каждый второй мужчина, не выдерживая болевого шока. Причем перед первым хирургическим вмешательством Абдулхак эфенди предупредил родителей, что операция предстоит очень тяжелая, и в Самаре ее еще не делали. После трех недель реанимации девочку перевели в хирургическое отделение, но через пару дней ситуация осложнилась. Решение о срочной второй операции Хасянзянов принял после 22.00, вернувшись почему-то на работу и взглянув на свежий рентгеновский снимок, который не обеспокоил дежурного врача. Эту публикацию надо читать в Интернете самостоятельно и порадоваться тому, что ныне девятиклассница Настя проблем со здоровьем не имеет.



*В школьные годы*

Теперь констатации без подробностей: «Нашего сына не было бы сегодня с нами, если бы не Александр Касымович», «Он спас обеих моих дочек», «Спас сына без операции», «Спасибо за дважды спасенную жизнь нашего ребенка», «Спасибо за спасение брата», «Подарил моей дочке вторую жизнь».

Слали сообщения этому детскому хирургу и его бывшие пациенты. «Мне ваша помощь потребовалась сразу же после рождения, в 1992 году, – написала 26-летняя Ю. Семкина. – Потом родители привозили меня к Вам каждый год на бужирование (введение инструментов – бужей – в некоторые органы трубчатой формы). Спасибо Вам большое, мы очень Вам благодарны за Вашу трудную и ответственную работу с маленькими детьми!»

А как относились к герою статьи его коллеги? Ведь не секрет, что талантливых, успешных и востребованных суперспециалистов в трудовых коллективах подчас не любят, и это неприятие может доходить до



*В период обучения в КГМИ. Хасянзянов – крайний слева в нижнем ряду*



*С сестрой, Куйбышев, 1967 год*

крайних проявлений. К счастью, в нашем случае такой напряженности не было. Наоборот, отмечается, что заведующий отделением сумел создать в нем очень теплую и дружескую атмосферу. Несмотря на то, что он вырастил не одно поколение детских хирургов и обладал непререкаемым авторитетом среди соратников, Абдулхак Касымович всегда охотно делился с ними своими знаниями и опытом.

К тому же он был невероятно чутким и доброжелательным человеком, всегда отзывчивым на чужую беду независимо от того, касалась она детей или взрослых, сотрудников больницы или их родственников. Поэтому в нем постоянно нуждались. И Хасянзянов звонил, договаривался, просил, убеждал. Причем свою персону не навязывал и взамен для себя ничего не испрашивал. Своего спокойно-деликатного шефа, умеющего пошутить и быть в нужный момент опорой, бесконечно преданного педиатрической службе и служению маленьким пациентам, коллеги ласково называли так – «Касымыч». Это же обращение использовали и ребятишки.

Кстати, имя Касым в переводе с арабского означает «распределяющий», а Абдулхак – «Слуга Доброго» (хотя есть и другие оттенки). Получается, что в качестве слуги доброго дела (истолкуем так) Хасянзянов распределял доброту, под которой можно понять и выздоровление. Попадание в свое имя не дает преференций в автоматическом режиме, но благоприятствует его носителю в движении к цели.

Окончив в 1978 году Куйбышевский государственный медицинский институт, он за 40 с лишним лет безупречной работы детским хирургом в больнице им. Н.Н. Ивановой помог тысячам ребятишек. По сути дела, наш герой стоял у истоков формирования и развития детской хирургической службы региона, был первопроходцем во внедрении в Самарской области многих современных хирургических методик и технологий. Он одним из первых начал проводить операции новорожденным детишкам первых часов жизни. Успешно опери-



*В день свадьбы, 1979 год*

ровал пациентов с онкологическими заболеваниями. Он брался за те случаи, от которых отказывались в других городах России. Он зачастую выходил из операционной после длительных хирургических манипуляций в 4 часа утра, а в 8.00 вновь был на работе.

Иного графика Хасянзянов, видимо, не представлял. Как же иначе, если его отделение принимало в круглосуточном режиме экстренных больных в возрасте до трех месяцев – ежедневно, а до 15 лет – три дня в неделю. По данным пятилетней давности, каждый год через хирургическое отделение проходило около 1500 детей, притом 40% из них попадали сюда по экстренным показаниям. Вряд ли эти числа за прошедшее с тех пор время стали меньше. Поэтому Абдулхак эфенди, живший работой и в значительной степени на работе, понимал, что каждая минута на счету.

Застать его свободным было практически нереально, так как он постоянно действовал: на операциях и обходах, консилиумах и приемах. Дух больницы, заложенный ее пионерами – «Ребенок на первом месте» – вошел в плоть и кровь нашего героя, как и его коллег. И это не просто красивая фраза. Подростки, которые соприкасались с ним не в операционном боксе и больничной палате, а лишь на разовом приеме, оставляли такие записи: «Доктор даже очень понравился, безгранично добродушный, хороший специалист, озвучил очень много подобранных под меня советов», «Давно не встречала таких грамотных врачей, которые с таким уважением относятся к пациентам. Выслушал мои жалобы, внимательно провел осмотр, выписал лекарства и совершенно спокойно ответил на мои вопросы», «Он здравомыслящий, располагает к себе», «Вел себя уважительно, даже улыбался, тщательно осмотрел, объяснил все нюансы лечения». Показательны даже эти слова тинейджера: «Ничего отвратительного заявить о докторе не могу». Вот так – без сантиментов, но в плюсе!

При всей своей занятости Абдулхак эфенди никому не отказывал: ни в консультации, ни в помощи, ни в личном курировании, ни в проведении хирургических вмешательств. Он брал инструмент и спасал детей, наполняя их добром выздоровления и распределяя роли среди коллег на такие же действа.

Судя по отзывам, наш хирург делал виртуознейшие операции, принимая нестандартные решения. Так, в 90-х годах он оперировал ребенка с диафрагмальной грыжей, из-за которой у малыша практически не было одного легкого, сдавленного кишечником. При удалении грыжи собственного материала диафрагмы не хватило, и в ней осталась большая дыра. Чтобы спасти пациента, нужно было чем-то ее закрыть. Но чем? На Западе уже использовали для этого искусственные материалы, которых в



Во время обхода. Хасянзянов – второй слева



В хирургическом отделении больницы, 2017 год

России еще не имелось. И врачи пошли на риск – взяв кусок обычной капроновой ткани, простерилизовали его и использовали как заплатку. Результат оказался удивительным – малыш выжил, а инородный материал, отрезанный от тюля (!), со временем оброс собственными тканями организма. Доводилось нашему герою исправлять и ошибки матушки-природы, делая пластику 500-граммовым младенцам, у которых не было прямой кишки или пищевода.

Доктор Хасянзянов имел 30 научных публикаций, в том числе в центральных медицинских журналах, и опыт выступлений на городских, всероссийских и международных конференциях, что и неудивительно при такой уникально-интенсивной многолетней практике. Удивляло окружающих и старших товарищей другое – почему не делается следующий шаг, предполагающий написание и защиту диссертации. На это у Абдулхака Касымовича был железный ответ: «Я хирург и работаю руками, а не ручкой и мышкой».



С мамой и сестрой, Ертуганово, 1993 год

В статье «Жизнь благодаря. 45 лет СГДКБ № 1 им. Н.Н. Ивановой», которая увидела свет пять лет назад, ее автор Ю. Русяева сформулировала определение детского хирурга. По ее мнению, «это особенный специалист. Высокий уровень знаний, солидная практика, психологический подход к родителям и детям, уверенность в своих решениях и необыкновенная мягкость по отношению к пациентам. Эти люди должны быть жесткими, как военные генералы, и мягкими, как любящие матери».

Согласимся с этой фразой, оговорив лишь то, что генеральство проявляется не в пациентско-родительской среде, а в некоторых служебных кабинетах и при принятии ответственного решения в операционной. Хотя при разговоре об Абдулхаке эфенди образ генерала не возникает: ни командного голоса, ни желания «выпятиться» и быть в центре внимания, ни тяги к презентационным мероприятиям и прочему официозу.

А еще важно, чтобы у детского хирурга был надежный тыл в виде семьи, члены которой понимают и принимают специфику его работы, не выражая недовольства по поводу ночных операций и вызовов в больницу в любое время. У Хасянзянова в этом плане был полный порядок. С женой Натальей Геннадьевной он некоторое время учился в одной институтской группе, и ныне она является заведующей детским поликлиническим отделением № 2 Самарской городской поликлиники № 13. Педиатром стала и единственная дочь Юлия, которая замужем за врачом Самарской областной клинической больницы имени В.Д. Середавина.

Можно говорить даже о медицинской династии детских врачей, если учесть, что сестра нашего героя Руфия Касымовна трудилась с ним в одной больнице и заведовала отделением «Малыш», а их прабабушка (по линии отца) была повитухой в селе Ертуганово Ульяновской области (до января 1943 года – Куйбышевской области). Там жили и родители нашего героя, добрые, трудолюбивые и отзывчивые люди.

В 1951 году они с трехлетней дочкой Руфией и годовалым сыном Амирзяном переехали в Куйбышев. Отец Касым Шакирович, участник Великой Отечественной войны, начал работать мотористом на моторостроительном заводе им. Фрунзе и по праву считался мастером на все руки. Во всяком деле он стремился достичь высокого качества исполнения (таких ныне называют перфекционистами). Вскоре его как честного, старательного и обязательного члена трудового коллектива избрали депутатом районного Совета депутатов трудящихся. А мама Шамшизамал Абдулловна, имевшая медаль как тру-



*Выступает на заседании Самарского областного научно-практического общества хирургов, 2004 год*

женица тыла (учетчица в тракторной бригаде и депутат сельсовета), была некоторое время в областном центре сотрудницей фабрики-кухни завода «Металлург» и буфета спецкомендатуры. 6 июля 1954 года у них родился последний ребенок – Абдулхак. Правда, в родительской семье его называли Габдельхаком, но это имя «не пропустили» при регистрации в органах ЗАГС ввиду его отсутствия в перечне имен того периода.

Абдулхак рос серьезным и смышленым ребенком, который очень любил читать сказки. Кстати, во взрослее годы он снова открывал эти книги, находя в народном творчестве и мудрости предшествующих поколений новые смыслы и подтексты. Подросток был и неплохим спортсменом на любительском уровне, выступал в различных соревнованиях, в том числе и по хоккею с шайбой в роли вратаря. Но не растущая слава молодого Третьяка определила выбор жизненного пути. С детства нашему герою нравились две профессии – летчика и хирурга. Для покорителя небес он вскоре стал излишне высоким. Поэтому, окончив среднюю школу № 5, юноша отправился поступать, как было отмечено выше, в медицинский институт.

Однако с первой попытки сделать это не удалось, и он устроился санитаром в клинику факультетской хирургии. На следующий год парень стал студентом, но работу в клинике не прервал, стремясь с самых низов начать путь к избранной профессии. Будучи студентом-старшекурсником, он набирался опыта в качестве медбрата в реанимации Первой городской детской больницы, которая со временем будет называться ГБУЗ СОДКБ им. Н.Н. Ивановой.

По окончании вуза молодого специалиста ждала интернатура в Чебоксарах, где он в течение года трудился в местной больнице. Чувашский период многое дал Хасянзянову: здесь он часто оперировал, набирался практических знаний. Жить пришлось в общежитии при больнице, так что интерна при необходимости моментально находили и вызывали на помощь в любое время. А в 1979 году начался период его работы в упомянутой куйбышевской детской больнице. Здесь Абдулхак эфенди прошел все ступеньки своей карьеры: был врачом-хирургом, а в 1991-м стал заведующим хирургическим отделением. Отсюда его посылали на повышение квалификации в СамГМУ и в Москву, а также на обмен опытом в госпиталь «Ольга» немецкого города Штутгарта – побратима Самары.

На базе возглавляемого им отделения в 1999 году был организован «Центр хирургической коррекции врожденных пороков развития у детей» для ребятишек Самарской области. Кроме того, с 1999 по 2012 год наш заведующий являлся главным внештатным сотрудником (главным детским хирургом) Департамента здравоохранения Администрации городского округа Самара.

Когда по жизни выпадали часы досуга, Хасянзянов стремился проводить их на даче, организуя какие-нибудь усовершенствования: строительство беседки, рытье колодца и пр. В отпуске предпочитал путешествовать с женой и дочерью по заграницам (Италия, Арабские Эмираты), совершать теплоходные круизы по Волге либо отдыхать с супругой в санаториях.

По словам очевидцев, всех своих «летних» женщин (супругу, дочь и двух внучек) наш герой просто обожал. Чтобы привлечь к себе внимание одногруппницы Наташи, выросшей в офицерской семье на территории ГДР, он даже решил стать военным и подал заявление на военфак. Потом разум возобладал над чувствами – ведь в армии детские хирурги не нужны (да и девушка стала выделять его из среды поклонников), и процесс превращения в офицера с трудом удалось остановить на уровне военкомата. Так Вооруженные силы не получили хорошего военврача, но зато за волшебство хирургических рук его начали вскоре вспоминать добрым словом родители заболевших деток, которые живут не только в нашей области, но и в других регионах страны, а также в некоторых бывших республиках Советского Союза.

Есть в этом какой-то особый знак



*С Н.Н. Ивановой – главным врачом детской больницы и коллегами, 2005 год*



*С женой и дочерью, 2015 год*



*На общегородском субботнике, 2015 год. Хасянзянов – крайний справа*

или нет, но июль в семье известного хирурга – месяц особый, потому что он вобрал в себя дни рождения и главы татаро-русской ячейки общества, и его законной половины, и внучек. Да и дочь лишь на один день припозднилась с появлением на свет, а то и ей быть бы июльской. Но зато она – Юлия, хотя считает, что это не дань семейному месяцу, а компромиссный вариант выбора имени интернационального звучания. Следует добавить еще сюда и июльский день свадьбы Абдулхака и Наташи в 1979 году.

Близкие люди полагают, что Наталья Геннадьевна была не просто замужем, а за Мужем, правильно понимавшим свою роль в семье, многое умевшим качественно делать по домашнему хозяйству благодаря «урокам» отца, прекрасно готовившим мясные блюда и с удовольствием занимавшимся с дочкой. Он заплетал ей косички и играл с ней в куклы, водил в музыкальную школу и на Волгу, помогал делать задания по сольфеджио, научил играть в шахматы, кататься на коньках и вязать хирургические узлы, покупал игрушки и пластинки с произведениями Чайковского, Шопена и Шуберта, сшил шубку из старой маминой шубы.

По словам Юлии Абдулхаковны, все подружки ей с детства завидовали – какой у тебя папа! – и с удовольствием приходили в гости. А папа очаровывал и школьных друзей дочки, и вузовских, совершенно не имея такой цели. Просто срабатывало природное обаяние и интеллигентность. В дачный период семья Хасянзяновых снимала каждое лето домик на турбазе «Волжские зори», и там наш герой быстро становился кумиром всех ребятишек.

Его искреннюю расположенность и любовь к детям успела оценить и первая внучка, достигшая пятилетнего возраста. Она играла с бабаем в машинки и прочие шумные игры, чувствуя, видимо, неподдельный интерес к себе. Вторая внучка всего этого оценить не успела – ей идет второй год. Со временем она, наверное, узнает, что через час после ее появления на свет Абдулхак Касымович возник с букетом цветов в послеродовой палате, в которую посторонних категорически не пускают, и произнес: «Все нормально, Юля. Поздравляю со второй дочкой. Я очень рад!»

Вместе с тем у нашего хирурга была тесная компания давних друзей, которых судьба развела по разным специальностям, но не ослабила их неформальные связи. Каждый Новый год они вместе встречали за городом. При всем при этом Габдельхак всегда испытывал нужду в общении и с сестрой, поскольку ощущал не только родство крови, но и близость душ. «Наши отделения в больнице были рядышком, – говорит Руфия ханум, – и мы каждый день улучали мгновения, чтобы встретиться в коридоре и обменяться информацией, заботами, поговорить на родном языке».

Помимо добрых слов от родителей пациентов герой сей статьи получал и официальные благодарности и награды. Так, в портфолио обладателя высшей квалификационной категории по специальности «детская хирургия» есть почетные грамоты Министерства здравоохранения и социального развития Российской Федерации, СамГМУ, благодарственные письма депутата Думы городского округа Самара и регионального благотворительного фонда «Самарская губерния», а также медаль «За медицинские заслуги» фонда «Региональный наградной фонд Самарской области». Добавим сюда отзывы студентов, с которыми Хасянзянов встречался в альма-матер в качестве преподавателя-почасовика. Назовем и главные награды доктора – многочисленные рисунки и поделки детей, лечившихся в его отделении.

Но первым подарок детишкам делал Хасянзянов, и для этого у него в кабинете стояла ваза с купленными им самим конфетами. Чтобы как-то скрасить неприятность и болезненность некоторых процедур, он не только находил успокаивающе-отвлекающие слова для ребенка, но и дарил ему конфетку. Бывало и так: идет заведующий отделением по коридору, а к нему подходит несмышленыш, берет за руку и ведет в кабинет – к упомянутой вазе. А встреченным в коридоре подросткам мужского пола доставалось рукопожатие Касымыча.

Вице-президент Самарской областной ассоциации врачей, доцент



*В День Победы с женой, дочкой и зятем, 2019 год*

СамГМУ Л.А. Бальзамова подчеркивает, что за несколько десятилетий работы в этой ассоциации она встретила такое всепоглощающее упоение своей профессией только у двух врачей губернии, и один из них – А.К. Хасянзянов. Она называет его примером настоящего, идеального врача, потому что он, во-первых, мог делать чудеса руками во время операций, а, во-вторых, выхаживать пациентов, проявляя заботливость и осмотрительность. Ведь между врачом и пациентом должно возникать поле доверия и внимания, позволяющее первому эффективно провести лечение, а второму понять, что ему не просто оказывают медицинскую услугу, а помогают справиться с болезнью.

Лидия Алексеевна уверена в том, что если бы Александр Касымович пошел в науку, в Самаре появилась бы еще одна школа великого врача – школа Хасянзянова.

Но, увы – не пошел. Зато срывался в отделение с любых семейных и дружеских мероприятий или опаздывал на них, ибо рукодействовал над ребенком, лежавшим на операционном столе. Однажды он отдыхал вместе с женой в санатории им. В.И. Ленина в Ундорах. Раздался звонок из Самары, и наш хирург срочно выехал в ставшую родной больницу. Супруга решила его сопровождать. После успешно проведенной им операции Хасянзяновы вернулись долечиваться в Ульяновскую область. А вот в башкирском санатории «Янган-Тау» им удалось провести весь срок без экстренного вызова.

Последний раз на работе Абдулхак эфенди был в субботу, 3 октября 2020 года. Успешно завершив во втором часу ночи следующего дня операцию по изъятию из пищевода ребенка проглоченного игрушечного жука, он отправился домой. А утром подскочила температура. «Зацепивший» врача ковид так и не позволил ему перейти в группу выздоравливающих от «болезни года» несмотря на все усилия медиков.

То ли сказалась хроническая усталость Хасянзянова, накопившаяся с годами и ослабившая иммунные силы его организма, то ли имела место недооценка им опасности нового вируса, присущая многим до тех пор, пока беда не войдет в твой или знакомый дом. Наш хирург издавна привык не болеть и быть всегда в мобильном состоянии. Отработавшая с ним более 30 лет старшая медсестра смогла вспомнить лишь один случай, когда он оформил больничный лист. В остальных случаях решение бывало таким – немножко посижу, приму таблеточку, и все пройдет. Антракт отсутствовал даже после перелома Абдулхаком эфенди одного ребра при катании с 33-летней дочкой на катке.

26 октября исцелитель детей, который возвращал им здоровье и подчас дарил вторую жизнь, покинул сей мир. Его внезапная кончина стала шоком для коллег Хасянзянова, родных и близких, а также родителей маленьких и уже подросших пациентов. Горечь от такой утраты пройдет нескоро, но ее надо перетерпеть. Сил родным и близким, некоторым из которых тоже выпала участь борьбы с заболеванием от коронавируса. Стойкости и неразбалансированности коллективу хирургического отделения, лишившемуся своего капитана, наставника и сохранения комнатных цветов в его кабинете, которым он всегда уделял много внимания. И, конечно, продолжения курса заведующего на самоотверженную борьбу за здоровье главных цветов нашей жизни – детей.

А Абдулхаку Касымовичу – вечная светлая память и искренний низкий поклон от всех бабушек-дедушек, матерей, отцов и детей, которых ему удалось вернуть к нормальному существованию. Как написала в Интернете Наталья из Иркутской области, мама спасенного им ребенка, «Царство Небесное Великому Хирургу!».



*Извещение о кончине А.К. Хасянзянова, 26 октября 2020 года*



# ТАБИБ БУЛЫП ТУГАН УЛ

***Ак халатлы табиблар, шәфкать туташлары, медицина өлкәсендә эшләүчеләр турында бик еш кына “Ак фәрештәләр”, диләр. “Фәрештәләр” диюгә, күз алдына әкиятләрдән генә укып белгән, тылсым көченә ия, иңнәрендә канатлары булган кешеләр килеп баса. Минемчә, әлеге чагыштыру бик урынлы. Чөнки мең төрле авыруларга дәва тапкан, үлем белән көрәшеп ятучыда да өмет уята алган, күпме кеше гомерләрен саклап калган шәфкать ияләрен башкача атап булмас иде!***

**Эльмира СӘЙФУЛЛИНА**

Тик бу аклык артында күпме тынгысызлык, эзләнүләр, йокысыз төннәр, борчылулар булганын барыбыз да аңлап бетермибез, кайвакытта рәхмәт әйтергә дә онытабыз. Нинди авыр, җаваплы эш бит табиб һөнәре, алар кулында – кеше гомерләре!

Балачакта күбебез: “Мин табиб булыр идем”, дип хыяллана. Әмма, үсә төшкәч, бу һөнәрнең ни дәрәҗәдә җаваплы булганын аңлый башлагач, күбебез бу хыялдан баш тартырга мәҗбүр була.

Ә минем әңгәмәдәшем, бернинди авырлыклардан да курыкмыйча, балачак хыялын чынга ашыру өчен бөтен көчен куйган кеше. Үзенең максатчанлыгы, тырышлыгы һәм хезмәт сөючәнлеге аркасында ул 33 яшендә Исаклы үзәк район хастаханәсенең баш табибы вазыйфасын үти.

Равил Хаметов Пенза өлкәсенең Неверкино авылында 1986 елның 6 ноябрендә Зиннюр һәм Адилә Хаметовлар гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. 7-8 сыйныфта укыганда ук ул алдагы тормышын медицина белән бәйләргә карар кыла. Ата-анасы каршы килүенә карамастан, кешеләргә ярдәм итү, җәмгыятькә файдалы булу теләге сүрелми – егет үз фикерен үзгәртми, киресенчә, югары уку йортына керү өчен ныклап әзерләнә башлый.

Урта мәктәпне уңышлы гына тәмамлаганнан соң, 2003 елда Равил Самар дәүләт медицина университетына укырга керә. Максатчан юнәлеш (целевое направление) буенча ул бюджет бүлегенә эләгә. Югары уку йортында Равил беренче курстан башлап, соңгы уку елына кадәр староста, профком оешмасы вәкиле була. Шулай ук хәрби кафедраны тәмамлый. Бүгенге көндә ул – медицина хезмәтенең өлкән лейтенанты.

Икенче курста укыганда ук, ул үз теләге белән Самарның төрле хастаханәләрендә төнге дежурлык үтүче табиблар янында эшли башлый.

– Табиблар дөньясына тизрәк кереп, дөрес диагноз кую, пациентлар белән аралашу үзенчәлекләрен беләсем, үз күзләрем белән күрәсем килде. Аеруча хирургия юнәлеше кызыклы иде. Бераздан миңа операция барышын күзәтергә, соңрак ассистент буларак катнашырга рөхсәт итә башладылар. Кайвакыт операция өстәле артында төн буе басып торырга да туры килгәләде, – дип искә ала Равил.

Медицина университетының өченче курсын тәмамлагач, егет юридик белем алырга карар кыла һәм Мәскәү югары уку йортының көндезге һәм читтән (очно-заочно) торып уку бүлегенә керә. Ике уку йортын да берьюлы алып бара ул. Медицина буенча төрле олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар яулый. Бишенче курста Равил урология юнәлешен тирәнтен өйрәнә. Аннары акушерлык һәм гинеколо-








гия хирургиясе буенча интернатура үтә. 2009 елда ул, ике югары уку йортын да бик уңышлы тәмамлап, ике диплом ала.

– Интернатура узган вакытта гинекология буенча яман шешләрне өйрәнү циклы булды. Ул дәресләр Самарның онкология үзәгендә үтте. Шулай итеп, мин яман шешләрне өйрәнүгә чумдым. Әлеге юнәлешкә кагылышлы һәрнәрсә дә мине чиксез кызыксындырды. Мин, онкодиспансерның барлык бүлекләренең эшчәнлеге белән танышып, төрле дәвалау ысулларын өйрәнү бәхетенә ирештем. Самар өлкәсенең иң яхшы белгечләрендә уку минем өчен икеләтә уңыш булды. Шуларның берсе медицина фәннәре докторы, профессор Михаил Олегович Воздвиженский. 2012 елның март аенда миңа онкодиспансерда онкоуролог табибы урынын тәкъдим иттеләр. Җитәкчебез Леонид Васильевич Шаплыгин яшь табибларны фәнни эзләнешләр белән шөгыльләнергә өндәде, безнең омтылышларыбызны хуплап, һәрьяклап ярдәм итеп торды. Шул рәвешле мин 2013 елда Саратов шәһәрендә мәни бизенең яман шеше (рак предстательной железы) темасына диссертация яклдым һәм фәннәр кандидаты булдым.

Шуннан соң Михаил Олегович Воздвиженский мине үзе эшләгән абдоминаль хирургия бүлегенә онколог булып эшләргә чакырды. Бераздан онкоүзәкнең паллиатив ярдәм күрсәтү бүлегендә эшләү бәхетенә ирештем. Әлеге бүлек табиблары аеруча авыр хәлдә булган, яман шешнең соңгы стадияләре белән көрәшүче авыруларга ярдәм итү белән шөгыльләнәләр. Дөресен әйткәндә, мондый авырулар белән эшләү искиткеч кыен, – дип авырсулап куйды егет. – Бу




чор минем өчен аеруча әһәмияткә ия, чөнки миңа бик зур тәҗрибә, белем һәм үз-үземә ышаныч бирде. Шулай ук паллиатив ярдәм бүлегендә хезмәт иткәндә мин Мәскәүнең Александр Иванович Евдокимов исемендәге медицина университетында әлеге юнәлеш буенча өстәмә белем алдым. Бүлек җитәкчесе Сергей Николаевич Ищеряковка чиксез рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Аның кебек остаз белән бергә эшләү – минем өчен зур бәхет.

– **Равил, миңа калса, бүгенге көн яшьләре арасында, сезнең кебек, үз эшенә бирелгән, бөтен буш вакытын укуга, белем алуга багышлаган кешеләр сирәк күренеш булып тора. Туплаган белемнәрегез җитәрлектер инде, дип уйламыйсызмы?**

– Юк. Яраткан һөнәремнең барлык нечкәлекләренә төшенәсем килә. Үсмер вакытымда ук алдыма кешеләргә файдалы булып, ярдәм итеп яшәргә, дигән максатлар куйган идем. Табиб булырга хыялландым һәм бу хыялыма ирештем. Авыру кешеләрнең хәлләрен җиңеләйтү, аларны дәвалау, сәламәтләндереп, шатландырасым килә минем. Шуңа күрә дә минем ярдәм югары дәрәҗәдә булырга тиеш, дип уйлыйм.

Бүгенге көндә мин медицинаның төрле юнәлешләре буенча 6 сертификатка ия. 2019 елда алган сертификатым медицина өлкәсендә җитәкче вазифаларын биләү мөмкинлеге бирә. Хәзерге вакытта шулай ук Самар дәүләт икътисад университетында “Стратегик менеджмент” белгечлеге буенча белем алам. Тормыш барышында барысы да кирәгәчәк.

Минемчә, канәгать пациентларның Равилнең җитәкчеләренә, хәтта сәламәтлек саклау министрына юлланган күпсанлы уңай бәяләмәләре онколог Хаметовның белем дәрәҗәсен һәм эшенең сыйфатын иң югары билге белән бәяләү ул. Яшь, талантлы, тырыш, үз эшен



яратып, югары дәрәҗәдә башкаручы табибны авырулар гына түгел, сәламәтлек саклау министры Михаил Ратманов та күреп ала һәм 2020 елның февралендә Равилне Исаклы районы үзәк хастәханәсенең баш табибы итеп билгелиләр.

Ул яңа урында бер дә аптырап калмый, булган проблемаларны барлап, аларны чишү юлларын таба, халыкка медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын яхшырту өстендә эшли башлый. Районда онколог булмаган икән. Иң элек Равил әлеге юнәлеш эшен җайлап җибәрә. Тулы булмаган бер ел эчендә район буенча яман шешләр буенча күрсәткечләр берничә тапкыр уңай якка үзгәргән. Һәр атна саен ул, районның зур авылларында урнашкан үзәк хастаханә офисына барып, халыкны шәхсән үзе кабул итә. Шул рәвешле бик күп авыруларны башлангыч стадиясендә үк белеп алып, тиешле дәвалау үз вакытында билгеләнә. Шулай ук ашыгыч ярдәм эше җайлана. Районның иң ерак урнашкан авылларына да тар белгечләрдән торган бригадалар барып, урын өстендә ятучы, мөмкинлекләре чикләнгән һәм халыкка тиешле башка ярдәм итүләр оештырыла. Шулай ук район хастаханәсе хезмәткәрләрен паллиатив ярдәм күрсәтү белән таныштырып, әлеге юнәлештә актив эш башлана. Һәрбер авыр хәлдәге авыру буенча комиссия төзеп, алга таба дәвалау турында карар кабул ителә. Бүгенге көнгә 200гә якын комиссия утырышы узган инде.

**– Равил Зиннюрович, халык**



**сезне ничек каршы алды?**

– Беренче вакытта авыл халкы ничектер куркып кына, кыюсыз гына мөрәҗәгать итә иде. Мин алар белән төрле темаларга әңгәмәләр корып, хәлләрен сорашып, зарларын игътибар белән тыңлап, һәрберсенә ярдәм итәргә тырышуымны күргәч, үзләре дә бераз сораулар бирә, киңәшләр сорый башладылар. Миңа карата ниндидер ышанычлы мөнәсәбәт барлыкка килде кебек. Алар минем икенче килүемне түземсезлек белән көтеп тора башладылар. Кайвакыт тиз генә әйләнеп кайтам, дип килгән авылда иртәдән кичкә кадәр эшләргә туры килә. Җыелган халыкны ничек кире борасың инде?

Белгәнегезчә, нәкъ менә Равил яңа вазыйфалар башкаруга алынганда, яңа коронавирус котырынган чак иде. Шунлыктан яшь җитәкчегә, көнне төнгә ялгап, җиң сызганып, күп проблемалар өерен чишәргә туры килә. Исаклы районы өлкә башкаласыннан бик ерак урнашканлыктан, яңа вирус йоктырган авыр хәлдәге авыруларны тиз арада Самарның махсус хастаханәләренә озату мәсьәләсе туа. Әмма Равил Зиннюрович монда да аптырап калмый, ул җитәкләгән хастаханә, беренчеләрдән булып, авыруларны өлкә башкаласына Санавиация вертолетлары белән озатуны оештыра.

Аның тәвәккәллеге никадәр кешенең гомерен саклап калды! Гомумән, коронавирус зәхмәте белән көрәш стратегиясен дөрес оештыру район буенча авырулар санының үсешен туктатуга китерде. Равил, баш табиб буларак, хезмәткәрләренә дә бик игътибарлы.

– Пандемия чорында барыбызга да бик кыен, барыбыз да талчыктык. Шунлыктан мин хезмәткәрләрем белән бертигез эшлим. Әлеге авыр вакытта без бергә, иңгә-иң куешып, коронавирус зәхмәтен җиңәргә тырышабыз. Нинди генә проблемалар, арыганлык булса да, коллективта без бер-



беребезгә җылылык һәм хөрмәт белән карарга тиеш. Ул чакта безнең эштән файда күбрәк булачак. Бер-беребезгә алмашка килеп, кыска гына булса да ял сәгатьләре дә оештырабыз. Терелеп, аякка баскан авыруларның елмаюын күреп, бергә шатланабыз. Һәрбер авыруның терелүе – безнең эшебезгә иң зур бәя. Аларның рәхмәт сүзләре тагын да дәртләнебрәк эшләргә этәргеч бирә, – ди ул.

Равилнең табиб булуга омтылышы, үз-үзен аямыйча, куйган максатына ирешүе туганнарына да үрнәк булып тора. Аның кече энесе Рөстәм хәзерге вакытта Самар дәүләт медицина университетының стоматология бүлегендә укый. Шулай ук туганнан туган абый-энеләре дә, медицина өлкәсендә белем алып, төрле шәһәрләрдә эшлиләр. Бик яшь булуына карамастан, эшен җиренә җиткереп башкаруы, җаваплы булуы белән кыска гына вакыт эчендә хезмәттәшләренең дә, район халкының да хөрмәтен яулый алган Равил Зиннюр улы.

Гомумән, һәрьяклап хөрмәтле, үрнәкле, халык арасында абруйлы булып, тормыштан ямь табып яши ул. Төп эше күп көч һәм вакыт биләвенә карамастан, Равил җәмәгать тормышында да бик актив катнаша. Самар өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр советы әгъзасы, актив хәйрияче Равил Хаметовны татар җәмәгатьчелеге арасында белмәгән кеше юктыр, мөгаен. 2016 елда төзелгән хәйрия фондының инициаторы да ул була.

– Мөфтиебез Талип хәзрәт Яруллин яшь активистлар керткән тәкъдимнәргә бик теләп колак сала. Төрле киңәшләр бирә, безнең башлангычларга һәрьяклап ярдәм итәргә тырыша. Гомумән, ул киләчәк яшьләр кулында булганны ачык аңлый һәм шуңа күрә дә лаеклы алмаш һәм ышанычлы киләчәк тәрбияләргә тели. Форсаттан файдаланып, Талип хәзрәткә олы рәхмәтләремне җиткерәсем килә.

Хәйриячелек темасына килгәндә, мин күптән инде ятимнәргә, мохтаҗларга ярдәм итәргә тырыша идем. Әмма бу эшләр ничектер читтән торып кына башкарылу миңа тынгы бирмәде. 2016 елдан башлап, мин үзем яки волонтерлар белән ятимнәр йортларына барып, җитәкчеләре белән сөйләшеп, нинди проблемалар, нәрсәләр кирәклеген барлап, әлеге юнәлештә зур эш башладык. Хәйриячелек эшчәнлегебез Мехзавод бистәсендә урнашкан “Малютка” ятимнәр йортыннан башланды. Алдан әзерләнгән исемлек буенча бөтен кирәк-яракларны җыйгач, Талип хәзрәт, мин һәм башка берничә активист нәниләргә кунакка бардык, алар белән таныштык, бүләкләрне тапшырдык. Мин ул чакта кичергән хис-тойгыларны сүз белән әйтеп аңлатып булмый... Ятим сабыйларның рәхмәт тулы күз карашлары аннан соң да бик озак күз алдымда торды әле, – дип авырсулап куйды Равил. – Шулай итеп, без акрынлап шәһәребезнең һәм өлкәбезнең төрле ятимнәр йортларына 2-3 ай саен булыша башладык. Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең (ГУФСИН) 15нче колониясенә дә ярдәм кирәклеген белеп алгач, анда тоткынлыктагы хатын-кызларның бәләкәй сабыйларына кирәкле барлык кирәк-яракларны туплап, делегация белән бардык. Безнең килүне сабыйлар







махсус концерт әзерләп көтеп торганнар. Җитмәсә, Яңа ел якынлашып килә иде. Шунлыктан безнең белән очрашу бәләкәчләр өчен икеләтә бәйрәм булды кебек. Сабыйлар белән аралашу безнең күңелләрне дә аеруча җылы хисләр белән тулыландыра, уңай эмоцияләр бирә.

Быел, Аллаһы теләсә, ятимнәр йортларына Яңа ел бүләге итеп чыршылар, уенчыклар өләшергә, дип уйлыйбыз. Урманчылык җитәкчелеге белән әлеге сорау хәл ителде инде.

– **Хәйриячелек өчен акча бик күп кирәк бит.**

– Әйе. Бәхеткә, кеше кайгысына, ятим сабыйлар язмышына битараф булмаган кешеләр дә җитәрлек. Мин дусларым, туганнарым, хезмәттәшләрем, пациентлар, татар җәмәгатьчелеге арасында хәйрия эшчәнлеге турында мәгълүмат тараттым. Шулай итеп, кем ничек ярдәм итә ала, акрынлап җыела башлады. Кемдер акчалата, кемдер башкача булыша. Талип хәзрәт бу эштә дә бик зур ярдәм күрсәтә.

Шунысын да әйтеп үтәсем килә: ятим балалар белән очрашуларга барганда, без дә аеруча әзерләнәбез. Сабыйларга төрле спортчылар һәм башка танылган кешеләр белән









әңгәмәләр оештырабыз. Үзебез турында сөйлибез, төрле уеннар оештырабыз. Аларга сатып алынган бүләкләр генә түгел, күңел җылысын да бүләк итәргә тырышабыз.

Самарда хайваннар өчен приютлар да бар. Аларга да булышырга тырышабыз. Алар өчен азык, медикаментлар сатып алабыз, читлектә утырган зур токымлы этләрне йөртергә чыгарабыз. Табигатьне саклауга да өлеш кертү өчен вакыт табабыз, – дип сөйли табиб. – Менә инде 3 ел дәвамында өлкәбез урманнарында агачлар утырту акциясендә актив катнашабыз. Ел саен язын, 200ләп кеше җыелып, урманга барабыз. Эшне һәрвакыт дога белән, Талип хәзрәт укыган Коръән сүрәләрен тыңлаганнан соң башлыйбыз. Шуңадырмы, урман хуҗалыгы җитәкчесе әйтүенчә, без утырткан агачлар да башкалардан тизрәк, ныграк булып үсәләр икән.

– **Сез кайчан булса да ял итәсезме соң?**

– Төнлә бераз йоклап алырга тырышам, – дип елмаеп куйды Равил. – Ял итәргә өлгерербез әле. Көч-куәт, мөмкинлекләр булганда кешеләргә ярдәм итеп, файдалы булып яшәргә кирәк.

Менә бит, безнең арабызда нинди асыл, киң күңелле, ярдәмчел, ихлас милләттәшебез бар икән! Журналыбызны укучы асыл затлар колагына сер итеп кенә әйтәм: “Равил әлегә өйләнмәгән”...



# АВЫР ДА, ҖАВАПЛЫ ДА, КЫЗЫКЛЫ ДА ХЕЗМӘТ

***Бүген тел һәм милләт сагындагы төп көчләрнең берсе булып татар теле укытучылары тора. Камышлы мәктәбенең татар теле укытучысы Тамара Хисмәтова да татар халкының аваз иҗаты, бай тарихы, әдәбияты аша укучыларында ана теленә, гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт хисе тәрбияли.***

**Әңгәмәдәш – Алия АРСЛАНОВА**

Тумышы белән Тамара Фанзеловна Башкортостанның Иске Күчәрбай авылыннан. 1984 елда Эстәрлетамак педагогия институтын тәмамлаганнан соң, ул Самар өлкәсенең Камышлы авылы мәктәбенә эшкә килеп урнаша һәм менә 36 ел шунда балаларга белем бирә.

Укытучы дәресләрен зур әзерлек белән, укучылар материалны җиңел аңлый алырлык итеп үткәрә, балаларны мөстәкыйль фикер йөртергә, иҗади эшләргә өйрәтергә омтыла. Моның өчен Тамара Фанзеловна дәресләрне заманча укыту технологияләрен кулланып оештырырга, балаларны кызыксындыру өчен зур тырышлык куя. Укытучы һәр көн балаларга яңалык алып килергә, аларның иҗатын, сәләтен үстерергә, белемен арттырырга тырыша, аларга рухи-әхлаки тәрбия бирүгә дә зур игътибар юнәлтә. Хезмәттәшләре дә, ата-аналар да Тамара Фанзеловна турында үз һөнәрен бөтен күңеле белән яратучы, тынгысыз, эзләнүчән җан, дип сөйлиләр.

Без Тамара Хисмәтова белән Камышлы мәктәбендә татар теле дәресләре ничек укытылуы, бүгенге шартларда татар теле укытуның үзенчәлекләре, балаларда ана теленә карата кызыксыну уяту хакында сөйләштек.

**– Тамара Фанзеловна, Камышлы мәктәбендә ана теле дәресләренә ничә сәгать бирелә?**

– Камышлы урта гомуми мәктәбендә татар теле һәм татар әдәбияты дәресләре 2нче сыйныфтан башлап 11нче сыйныфка кадәр атнасына бер сәгать өйрәнелә. 8нче сыйныфта өстәмә рәвештә дәрес сыйныфтан тыш чаралар өчен бирелә.

**– Туган тел дәресләрендә заманча технологияләр һәм алымнар кулланыламы?**

– Бүген укытучыга замана белән бергә атларга, яңалыкларны үзләштереп барырга кирәк. Әлбәттә, технологияләрне дә нәтиҗәле файдаланабыз. Инновацион алымнар укучыларыбызны татар теленә өйрәтүдә уңай йогынты ясый, дәресне үзләштерүне югары дәрәҗәгә күтәрергә ярдәм итә.

Впервые в татарских селах нашей области я побывал уже после окончания вуза, когда начал проводить полевые этнографические исследования народов Самарского края. Самым первым районом был Красноярский – туда я приехал по рекомендации первого редактора газеты «Бердемлек» Рафгата Набиулловича Аглиуллина. Там, недалеко от райцентра, расположено поселение под названием Угловое – мое первое татарское село в Самарской области. Было дело летом, погода стояла прекрасная. Итак, поездка в автобусе до Красного Яра, а оттуда – пешком через поля, вдыхая аромат цветов, наблюдая за полетом бабочек и слушая стрекот кузнечиков. Вот и село. В нем запомнились встречи с людьми разного возраста: с мужчинами и женщинами, с молодой мамой, с бабушкой, перешагнувшей столетний юбилей. Местные легенды, особенности традиционной одежды, старинные обряды – обо всем этом рассказывали люди разных возрастов, жители этого места.





В настоящее время полевые этнографические исследования обычно проводятся у нас в летнее время, свободное от основной, преподавательской, работы. Ушли в далекое прошлое те времена, когда этнографы работали в одном и том же месте годами и без перерыва, – например, наш знаменитый соотечественник Н.Н. Миклухо-Маклай, живший долгое время у папуасов Новой Гвинеи. Сейчас все иначе: летом – в поле, а начиная с сентября – в аудиторию, чтобы передать студентам знания, в том числе полученные во время собственных исследований. Исключением являются разовые поездки. Все же могу здесь отметить, что не только в башкирских, но и в некоторых татарских селах я был и зимой – например, в селе Денискино Шенталинского района. Это старинное село известно, в частности, своим народным фольклорным коллективом «Чулпан», получившим известность далеко за пределами села, выступления которого мне доводилось слышать и в последствии. Посетил я и местную мечеть, беседовал с людьми разных возрастов – хранителями родной культуры. А традиции здесь помнят и сохраняют.

В заключение хочется отметить, что в наше время, несмотря на активное развитие городской этнологии, не следует забывать и про села – там есть что изучать, знакомиться с тем, как местные жители сумели и в наше время сохранить этнокультурные особенности.

# ЧТОБЫ ЗАСЛУЖИТЬ УВАЖЕНИЕ, НАДО УМЕТЬ ЗАБОТИТЬСЯ О БЛАГЕ НАРОДА

***Мнение о человеке и о его семье складывается из многих факторов. Но определяющим является то, к какому роду он принадлежит и насколько крепки корни его происхождения.***

**Фарид ШИРИЯЗДАНОВ**

Село Балыкла по праву может гордиться людьми, которые из поколения в поколение прославляют свою малую родину. Например, там всегда с уважением относились к представителям династий Вахитовых, Ахметшиных, Нигматуллиных, Абсаттаровых, Билаловых и других.

Родословная Нигматуллиных берет свое начало от их далекого предка Султаная, и они с чувством гордости рассказывают о том, что являются его потомками.



Хабибулла Гайзуллович Нигматуллин – наиболее яркий представитель своего рода. Будучи кровно привязанным к земле, он много сделал для развития родного села Балыклы. Чувство такой привязанности он воспитал и в своих детях.

О таких, как Хабибулла Гайзуллович, говорят: «Человек сделал себя сам!» Родился он перед Великой Отечественной войной – в 1934 году. Детство его и юношество прошли в тяжелые военные и послевоенные годы. Поколение людей, которых называют «детьми войны», наравне со взрослыми перенесли на своих плечах все тяготы тех лет. Суровые испытания сделали людей их поколения особенно крепкими и жизнеспособными.

Несмотря на разруху и тяжесть послевоенных лет, стремление к знаниям у Хабибуллы Гайзулловича, присущее представителям их рода, не угасло. Хотя в селе Балыкла дети могли обучаться только до 7-го класса, он пошел учиться в школу села Старое Ермаково и там получил среднее образование.

В своих воспоминаниях он часто говорит о том, как каждую неделю, будь то слякоть, трескучие морозы либо в пурга, им пешком проходилось пройти расстояние в 18 километров.

Хотя людей, получивших тогда среднее образование, считали самыми грамотными в селе, стремление к знаниям в нем не угасало и далее. Со временем он поступил учиться на агрономическое отделение Куйбышевского сельскохозяйственного института заочно и успешно окончил его.



Хабибулла Гайзуллович по натуре человек общительный, находчивый, обладает сильным чувством юмора. Но при этом он требователен, настойчив. Умеет строить серьезные планы, смело и упорно действовать при их реализации. Словом, он обладает серьезными качествами лидера. Конечно, без этого нельзя представить достойного руководителя сельского хозяйства.



После того как он проработал в системе советско-партийных органов Камышлинского района, его, как способного организатора, направили в один из отстающих колхозов – в родное село.

Всю тяжесть груза ответственности руководителя сельского хозяйства в полной мере может познать и прочувствовать только тот, кто испытал это на своей шкуре.

Человек в жизни может проявлять себя во многих сферах деятельности. Но есть такие профессии, осваивать которые нельзя только обучением. Тут необходимо, чтобы человек с рождения был «привязанным» к этой профессии или ремеслу. Взять, например, врачей и учителей, которые работают с «человеческим материалом» и ошибки которых чреваты серьезными последствиями, порой даже для всего общества.

Истинным хлеборобом также может стать только тот, кто «рожден в борозде», кто умеет чувство-

вать дыхание земли, чью душу волнует запах вспаханного поля и шелест спелых колосьев. Только тех, кто умеет чувствовать пульс земли, умеет ухаживать за ней и быть благодарным ей, земля может осчастливить своими дарами.

Хабибулла Гайзуллович – один из тех людей, которых смело можно называть хлеборобами. В основе этого слова заложен глубокий смысл – поборник, то есть борец за урожай хлеба, который является основным продуктом для нашего жизнеобеспечения.

Став председателем колхоза, Хабибулла Гайзуллович изучил особенности почвы, выработал свою тактику обработки полей колхоза, которым руководил.

За полученные результаты он был удостоен ордена Трудового Красного Знамени. Результаты его деятельности изучали другие и приезжали перенимать его опыт.



Под его руководством колхоз стал одним из прибыльных и передовых хозяйств в районе, когда большинство хозяйств работали себе в убыток.

Имея свободные деньги, в колхозе, которым он руководил, начали строить не только производственные помещения, но и объекты социального и культурного назначения. Возросла энергоемкость производства. Начали применять научно обоснованные методы и приемы работы и трудоемкие процессы стали выполнять машины и механизмы. Возрос машинно-тракторный парк. Хозяйственным способом, то есть силами колхоза




были построены:
- впервые в районе вальцовая мельница;
- типовые коровники по современным стандартам;
- двухэтажная школа;
- проведена телефонизация села;
- новые склады для хранения зерна;
- весовое хозяйство и три ЗАВ;
- две мастерских;
- картофелехранилище;
- пилорама;
- мосты;
- телятники;
- был достроен СДК и многие другие жизненно важные объекты сельхозпроизводства и соцкультбыта.

В этот период регулярно и своевременно выдавалась зарплата. Труд людей достойно оплачивался и применялась система стимулирования и премирования. Трудиться на земле тогда стало делом благородным и почетным.

Вот что пишет о нем Рашит Закирович Билалов, работавший тогда главным агрономом колхоза, в своей книге об истории села:

«Хабибулла Гайзуллович Нигматуллин много сделал для улучшения условий жизни на селе. При его руководстве повысилась урожайность полей, продуктивность животноводства. Преобразилась жизнь на селе. Все село было электрифицировано. Люди начали строить новые, добротные дома. При этом колхоз оказывал им всемерную помощь.

Главное достоинство Хабиба Гайзулловича заключается в том, что он четко видел перспективу, строил серьезные планы и мог до конца реализовать свои смелые замыслы, никогда не останавливаясь на полпути.

С ним всегда можно открыто поговорить и решать любые проблемы. Жители села и все те, кто его знают, относятся к нему с уважением. К его словам везде, на любом уровне внимательно прислушиваются. Любой человек, кто бы к нему ни обратился, не оставался без внимания и его помощи. Как мог он помогал каждому – добрым советом или делом.

Одним словом, я считаю его опытным и умелым руководителем, способным не только организовать серьезные дела и достойно завершать их, но и заботиться о благе народа, оправдывая его доверие».

Известно, что сущность человека (его эго) формируется вокруг его имени. А имя Хабибулла в переводе с арабского означает «любимец Аллаха». Наверно, поэтому Всевышний одарил его многими способностями. Например, Хабиб Гайзуллович, как и многие в его роду, обладает музыкальным даром – играет на гармони, имеет золотые руки, умеющие изготавливать столярные изделия.

Он всегда был в гуще всех событий и являлся душой общества –

будь то при осуществлении серьезных проектов или же на отдыхе.

Будучи уже в преклонном возрасте, он и сейчас пользуется заслуженным авторитетом как у односельчан, так и в районе. В качестве почетного гостя его приглашают на все торжества и традиционные мероприятия.

Как было сказано, его заслуга еще и в том, что он сумел передать своим детям любовь к своей малой родине, уважительное отношение к земле.

Его старшая дочь Раифя Абсаттарова, живя в селе, проработала в администрации Камышлинского района, где заведовала районным финансовым отделом.

Сын Рафаиль окончил Куйбышевский сельскохозяйственный институт и, получив специальность инженера-механика, вернулся в родное село. Работал в системе районного агропрома на руководящих должностях, затем был избран председателем колхоза «Правда» в родном селе.

Младшая дочь Резеда в своем селе работает в системе социального обслуживания и реабилитации сельского населения.

К сожалению, в настоящее время круто поменялось отношение людей к труду земледельца. Пропала преемственность, когда сыновья от отцов и дедов перенимали умение трудиться на земле и уважать труд хлебороба. Возиться с землей для многих стало считаться делом неблагородным. При этом сейчас многим в тягость засевать свои придворные участки, даже сажать овощи и картофель.

Наши далекие предки, несмотря на то, что владели бескрайними землями, они бережно использовали и ценили каждый ее клочок. Они обожествляли землю и работали на ней беззаветно, относясь к ней как живой субстанции. Ведь земля – это бесценное богатство. Не зря ее называют матушкой и кормилицей. Не считаться с этими понятиями – безнравственно.



К счастью, всегда были и есть люди, которые, показывая образцы трудолюбия и уважения к земле, стараются сделать жизнь на ней счастливей, краше и добротной.

Династию Нигматуллиных смело можно назвать истинными хозяевами на земле и достойными всякого уважения. Например, дед Хабиба Гайзулловича, Нигматулла Хисматов – ремесленник, кузнец по холодной обработке металла, отцу Гайзулле Хисматову присвоено звание «Заслуженный колхозник», сын Рафаэль – последний председатель колхоза, внук Альмир – руководитель крестьянского хозяйства в родном селе.

Сейчас, когда неуважительное отношение к земле, презрение к сельскому труду стало привычным явлением, восхищает появление людей, которые способны поднять престиж сельского хозяйства, проявляя образцы трудолюбия и целеустремленности. Один из таких – Альмир Нигматуллин, внук Хабибуллы Гайзулловича.

Занятие сельским хозяйством требует максимальной отдачи. Оно не терпит полумер и попустительства. Только тогда земля может одаривать того, кто достойно трудится и уважительно относится к ней.

Но уважение к труду земледельца в людях надо воспитывать сегодня, сейчас. Ведь сельское хозяйство – это основа экономической безопасности страны. Потеря уважения к нему чревата серьезными последствиями.



# “НАМАЗ КЕШЕНЕҢ ТОРМЫШЫН ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРТӘ”

***Татар яшьләре арасында тәрбияле, тыйнак, акыллы, максатлы, ачык йөзле, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы, олылар белән ипле итеп сөйләшүче егетләребез, кызларыбызның күп булуы шатландыра.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**



*Ләйсән Мансурова*

“Мин татар кызы булуым белән горурланам! Безнең шундый бай тарихыбыз, матур гореф-гадәтләребез бар бит!” – дип сокланып сөйли үз милләте турында Разил кызы Ләйсән Мансурова.

25 яшьлек Ләйсән – инглиз теле укытучысы. Үзенең ана телен дә бик яхшы белә ул, аңарда матур итеп, яратып сөйләшә.

“Кечкенәдән әбием, әти-әнием татар телен өйрәтеп үстерделәр. Аннары “Яктылык” мәктәбендә укыганда аны тагын да камилләштердем. Гомумән, мине нәкъ шушы мәктәпкә укырга китергәннәре өчен мин гаиләмә бик тә рәхмәтле”, – дип сөйли башлады Ләйсән сүз милли темага кагылгач. – Миндә әлегә кадәр “Яктылык”ка карата җылы хисләр саклана. Анда безгә төпле бирем бирделәр. Тәрбия турында сөйләргә дә юк, бигрәк тә милли яктан. Татар теле, әдәбияты, моңлы җырларыбыз, тирән мәгънәле шигырьләребез, күркәм гореф-гадәтләребез – боларны тагын кайда өйрәнер идем әле?!

Ә укытучыларыбыз нинди яхшы иде. Мин ел саен аларның һөнәри бәйрәмнәрендә дә, чыгарылыш сыйныф кичәсенә дә мәктәпкә барырга тырышам. Мөгаллимнәремне, сыйныфташларымны озак күрми торсам, күңелемнең бер чите китек”.

Ләйсән мәктәп чараларында да актив катнаша. Укытучысы Фәния Гыйлаҗева җитәкчелегендә татар язмасы графикасының тарихы буенча Казанда конференциядә катнашканы турында әле дә зур кызыксыну белән сөйли ул. Ә университетта укыганда Ләйсән Самар өлкәсенең “Туган тел” исемле татар җәмгыятенә йөри. Казанда узган Татар яшьләре көннәренә, Бөтендөнья татар яшьләре форумына да бара.

Рухи мәркәзебезне аеруча ярата Ләйсән. Мәктәптән соң Казан федераль университетының инглиз теле һәм әдәбияты филологиясе факультетына укырга керә ул. Ике ел анда белем алгач, аерым сәбәпләр аркасында, Самар дәүләт университетына шул ук факультетка күчәргә мәҗбүр була.

“Яктылык”та инглиз теле укытучысы Зилә апа Шәрәфетдинова үз фәненә карата шундый кызыксыну уятты ки, мин инде ул чакта ук киләчәктә нинди һөнәр сайлап алуымны билгеләп куйдым”, – ди Ләйсән.

Университетны тәмамлагач, кыз Самарның “Диалог” дип аталган белем бирү үзәгендә инглиз телен укыта. Ә биредәге бик тыгыз эш графигы канәгатьләндерми башлагач, репетиторлык белән шөгыльләнергә карар кыла. Аның укучылары арасында олылар да, балалар да бар.

“Күп нарасыйлар инглиз теленнән мәктәп программасын үзләштереп бетермиләр, артта калалар. Шуңа күрә, өстәмә дәресләр алыр өчен, аларның әти-әниләре репетитор ялларга мәҗбүр булалар.

Ә инде олыларга килсәк, күбесе чит илләргә ял итәргә барганда инглиз теле кирәк, дип өйрәнә. Хәзер күп зур оешмаларда бу телне белү таләп ителә. Шуңа күрә кешеләр яхшы эшкә урнашу теләгеннән дә инглиз телен өйрәнүне максат итеп куялар. Кайберәүләр хезмәт урыннарында инде аны кулланып, белемнәрен камилләштерергә, дип, репетиторга мөрәҗәгать итәләр”, – дип сөйли Ләйсән Мансурова.

**– Инлгиз телен укыту авырмы соң? – дип сорадым аңардан.**

– Кечкенә балалар белән авыррак, әлбәттә. Алар бит озак вакыт бертөрле эш белән шөгыльләнә алмыйлар. Дәресләрне уен формасында, кызыклы итеп, күрсәтмә әсбаплар кулланып, актив рәвештә алып барырга кирәк.

Ә инде урта яшьтәге нарасыйлар үз проблемаларын аңлыйлар, аларны хәл итәр өчен бөтен тырышлыкларын куялар.

**– Кешегә инглиз телен өйрәнер өчен күпме вакыт кирәк?**

– Һәрберсенең төрлечә. Кемдер бик тиз үзләштерә. Ә кайберәүләргә бер теманы берничә тапкыр аңлату таләп ителә. Гомумән алсак, инглиз телен белер өчен аны ике ел интенсив рәвештә өйрәнү кирәк. Әлбәттә, даими үзлегеңнән белем алу да мөһим.

**– Телне өйрәнү – бер хәл. Аны практикада кулланмасаң, ул онытыла бит. Укучыларыңа бу турыда берәр нинди киңәшләр бирәсеңме?**

– Әлбәттә, практика, аралашу, белемне үстереп тору кирәк. Укучыларыма инглиз телендә китаплар укырга, видеороликлар, фильмнар карарга киңәш итәм.

**– Хезмәтең нәрсәсе белән ошый?**

– Кешеләргә гыйлем бирүем шатландыра. Мәктәп балалары инглиз телен өйрәнүе авыр, дип беләләр. Мин аларга бу фәнне башка яктан күрсәтәм. Аннан алар фикерләрен үзгәртәләр, үзләрендә инлгиз теленә кызыксыну уяна, аны яратып үзләштерәләр.

Аралашканда кешенең мавыгулары белән кызыксынам. Аннары инглиз теле дәресен шул темага бәйләп үткәрәм.

**– Укучылар белән уртак тел табуы авырмы?**

– Аллаһыга шөкер, һәрберсе белән уртак тел табам, һәркайсының күңелен күрә беләм. Мин – ачык, намуслы, гадел кеше. Кешеләр моны сизәләр, күрәләр бит.

**– Тормышта уңышларга ирешер өчен кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш, дип саныйсың?**

– Максатка омтылышлы, тырыш, үз дигәнен булдыручан. Белем алу, үсү теләге кирәк.

**– Әти-әниең сине ничек тәрбияләделәр?**

– Әтием Разилгә, әнием Галиягә мине, апам Алсуны, энем Ильясны яхшы, мәрхәмәтле кешеләр итеп үстергәннәре өчен бик рәхмәтлемен. Милли һәм дини тәрбия дә бирделәр. Гаиләбездә гореф-гадәтләребезне үтәп яшибез. Аллаһыга шөкер, 18 яшемнән намазга да бастым.



*Ләйсән Мансурова әбисе Рәисә белән*

**– Намаз укый башларга нәрсә яисә кем этәргеч булды?**

– Кечкенәдән әбием Рәисәнең догалар укыганын ишетеп, гыйбадәт кылганын күреп үстем. Нәкъ ул миндә динебез Исламга мәхәббәт тәрбияләде, барысына да өйрәтте. Аннары Казан университетына укырга кергәч, Камышлыдан килгән бер яхшы кыз белән дуслашып киттек. Аның белән бергә намазга бастык.

**– Гыйбадәт кыла башлагач, үзеңдә үзгәрешләр сиздеңме?**

– Күңелемә тынычлык иңде. Атлаган саен Раббымның ярдәмен тоямын. Имтиханнар алдыннан да, намаз укып, уңышлы билге алуымны сорый идем. Аллаһы Тәгалә һәрвакыт булыша.

Мин кечкенәдән тыйнак идем. Начар гадәтләрем беркайчан да булмады. Гыйбадәт кыла башлагач, тормыштагы күп принципларым тагын да ныгый төште. Раббыбызга шөкерана кылам. Иман байлыгы, исәнлек, дөрес юллардан гына йөрт, дип сорыйм.

**– Ләйсән җәен никахың да булган икән. Иреңнең нинди сыйфатларына кызыгып кияүгә чыктың?**

– Ирем Рамил минем мәрхүм әтиемә охшаган. Ул – йомшак, киң күңелле кеше. Һәрвакыт ярдәмгә килә, хуплап тора. Әдәпле рәвештә дөресен күзгә бәреп әйтә. Мин аның шушы сыйфатларын ошаттым. Ул – минем терәгем, таянычым.

**– Буш вакытларыңда нәрсә белән шөгыльләнәсең?**

– Әнием, әбием янына барам, иптәшләрем белән очрашам. Татар чараларына, концертларга йөрим. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры шәһәребезгә гастрольләр белән килгәч, бер спектакльләрен дә калдырмыйм. Фильмнар карарга яратам. Хәзер пандемия вакытында күбрәк өйдә утырырга туры килә, әлбәттә. Шулай булса да, тик тормыйм, һәрвакыт эш белән мәшгуль.

**– Берәр нәрсә белән мавыгасыңмы?**

– Эрләгән җептән (пряжа) кәрзиннәр бәйлим. Интернетта күргәч, бу кул эше белән ныклап кызыксынып киттем. Хәзер беренче заказлар да ала башладым. Киләчәктә сумкалар бәйләргә дә ниятлим, Аллаһы бирсә.

**– Интернеттан үзең өчен тагын нинди мәгълүматлар аласың?**

– Ашамлык рецептлары белән кызыксынам. Кәрзин бәйләү буенча осталыгымны камилләштерергә ярдәм итүче язмаларны үзләштерәм. Гомумән, үсешем өчен файдалы булган мәгълүматларны укыйм. Тарихи, иҗади темаларны яратам.

**– Кемнәрдән үрнәк алып яшисең?**

– Күп кызлар өчен тормышта әниләре үрнәк булып тора. Минем дә шулай. Әбиемнең акыллы киңәшләреннән башка бик авыр булыр иде. Апамның күп сыйфатларын үземдә тәрбияләргә тырышам.

**– Үзеңә карата дөрес тәнкыйтьләү сүзләрен ничек кабул итәсең?**

– Аңлап кабул итәм. Тәнкыйтьлиләр икән, димәк, кимчелекләрем бар. Алар өстендә эшләп, яхшы якка үзгәрер өчен яхшы сәбәп ул.

**– Ә үзең башкаларга кимчелекләре турында турыдан-туры әйтә аласыңмы?**

– Мин йомшак холыклы. Кешеләрнең кимчелекләрен күрсәм дә, битләренә бәреп әйтә алмыйм. Һәрхәлдә әдәпле, тыйнак сөйләшергә тырышам.

**– Тормышта җитди карар кабул итәргә кирәккәндә кемнәр белән киңәшәсең?**

– Әнием, әбием, ирем белән. Якын дустым Җәмилә дә гел ярдәмгә килә.

**– Иптәшләр дигәннән, синеңчә, чын дус нинди булырга тиеш?**

– Чын дус кеше хәленә керүчән, ярдәмчел, миһербанлы, гадел, дөресен әйтә торган булырга тиеш. Дуслар күп булмый ул. Минем берничә бик якын, ышанычлы иптәшем бар. Без күңелсезлек килсә дә, шатлык булса да, гел бергә, серләребез белән уртаклашабыз, бер-беребезгә булышабыз, проблемаларны бергә хәл итәбез. Мин аларны бик яратам һәм үзләренә рәхмәтлемен.

**– Синең өчен бәхет нәрсәдә?**

– Якыннарымның исән-сау, янымда булуы.

**– Киләчәккә нинди планнар белән яшисең?**

– Репетиторлык эшен ошатсам да, киләчәктә, Аллаһы теләсә, я инглиз теле укытучысы, я тәрҗемәче булып урнашырга телим. Гаилә учагымны саклап, балалар табып, матур гына гомер кичерергә насыйп булсын.

**– Амин, Ләйсән. Ниятләрең гамәлгә ашып, динебез кушканча, шундый ук күркәм холыклы шәхес, милләтебезнең лаеклы вәкиле булып яшәвеңне телим.**



*Ләйсән ясаган кәрзиннәр*


*Кәүсәрия Шәйхетдинова (уңнан өченче)*

# “БАЛАЛАРГА ДИНЕБЕЗ ИСЛАМГА, МИЛЛИ ЙОЛАЛАРГА НИГЕЗЛӘНГӘН ТӘРБИЯ БИРЕРГӘ КИРӘК”

***Мөхәммәтнур кызы Кәүсәрия апа Шәйхетдинованы озак еллар беләм инде. Мин аның белән Гали авылына репортаж ясарга баргач таныштым. Ул вакытта Кәүсәрия ханым һәм авылның актив, күренекле хатын-кызлары Фәһимә Зарипова, Саимә Морзаханова, мәрхүм Сания Әмирова, безне бик яхшы каршы алып, кызыксындырган сорауларыбызга җентекләп, барысын да аңлатып сөйләгәннәр иде.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Зыялы, акыллы, төпле, тыныч, ипле, йомшак кына аралашучы, ачык йөзле, татар телен камил белеп, аһәңле әдәби сөйләмгә ия булган Кәүсәрия Шәйхетдинова мине бер күрүдән үзенә җәлеп итте, һәм шуннан бирле аңа карата күңелемдә җылы хисләр сакланып яши.

Кәүсәрия ханым – 35 ел буена мактаулы һәм авыр саналган укытучы хезмәтен башкарган кеше, Гали авылы мәктәбендә математика фәнен укыткан, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булган. Унбиш ел район депутаты булып сайланган.

Моңардан тыш, милләттәшебез Похвистнево районының “Туган тел” татар җәмгыяте эшендә актив катнашучы да, Гали авылының “Ак калфак” татар хатын-кызлары оешмасы житәкчесе дә. Гомумән, тормышының бер генә мизгелен дә эшсез үткәрә алмый ул. Пенсиягә чыгып, мәктәптән китсә дә, әле бүген дә иҗтимагый оешмалардагы хезмәтен актив рәвештә дәвам итә, авыл музее эшендә дә зур булышлык күрсәтә.

Кәүсәрия Шәйхетдинова “Россия Федерациясе гомуми мәгарифенең мактаулы хезмәткәре” күкрәк билгесе, Россиянең фән һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан хөрмәт грамотасы белән бүләкләнгән. Гомумән алганда, укытучы хезмәтендә дә, иҗтимагый эшләрендә дә аның мактаунамәләре санап бетергесез.

Гали авылында туып-үскән Кәүсәрия апа Подбельский педагогия училищесын тәмамлый. Мәктәптә






эшли башлагач, читтән торып, Куйбышевның педагогия институтында физика-математика факультетында югары белем ала.

Кәүсәрия апа белән, чын туганнардай, рәхәтләнеп сөйләштек. Әңгәмә алган вакытта үзе минем хәлләремне дә сорашып өлгерә. Менә шундый киң күңелле, олы йөрәкле шәхес ул!

**– Бигрәк тә кешеләргә игътибарлы, йомшак ханым сез, Кәүсәрия апа! – дип, аңа рәхмәтемне белдердем.**

– Әткәйнең әнисе – Минафа әбием шундый йомшак, сабыр, тыныч иде, Миләүшә, аңа охшаганмындыр инде. Әтиебез дә шушындый ук холыкка ия, бик дини кеше булган. Күршеләр аның җәйге эсселәрдә дә рәттән өчәр ай ураза тотканын исенә төшерәләр. Кызганычка, 40 яшендә үлеп китте. Мин ул вакытта бишенче сыйныфта укый идем. Әниемә биш баланы берүзенә үстерергә туры килде.

Әнкәйнең әбисе – Гыйльмениса әбием безнең белән бергә яшәде. Әткәйнең ата-анасы да бездән ерак түгел торалар иде. Әтием үлгәч, Минафа әбием безне бик җәлли иде, гел ярдәм итәргә тырышты.

Әби-бабай тәрбиясендә үстек инде. Кечкенәдән догалар, юмарт, ярдәмчел булырга өйрәттеләр. Гыйльмениса әби бөтенесенә булышып яшәде, әнкәйгә безне күтәрергә дә нык ярдәм итте ул, – дип балачак елларына кайтып килде әңгәмәдәшем.

– Укып бетергәч, читкә эшкә җибәрергә теләделәр. Әмма мин авылга кайтырга тырыштым, әниемә булышырга кирәк иде. Ул, минем белән район мәгариф бүлегенә барып, елый-елый үземне Галидә калдыруларын үтенде. Шулай пионервожатый булып эшли башладым.

Парторг Рәфгать абый Муратов бар иде. Мин ул кешене бик хөрмәт иттем. Авыл советына сәркатиб кирәк булгач, ул мине бу эшкә килергә үгетләде. Сүзен тыңладым һәм җиде ел анда сәркатиб булып эшләдем. Беренча баламны тапкач, китәрмен дигән идем, ләкин калырга бик сорадылар. Икенче улым тугач, яңадан мәктәпкә урнаштым. Кулымда югары белем алу турында диплом да бар иде инде. Авыл советы башлыгы, рәис булырга да тәкъдим иттеләр, әмма күңелем укытучылыкка тартты.

Элек мәктәп хезмәте рәхәтрәк, күңеллерәк иде шул. Кәгазь эше алай күп булмады. Балаларга игътибар бирергә вакыт күбрәк кала иде. Мин укучыларымны төрле экскурсияләргә йөртергә яраттым. Атна саен кайда булса да юл тоттык – цирк, театр, шәһәрне карап йөрү.

“Туган як укулары” дип аталган бәйгедә җиңгән балаларны да Кырлайга, Мостафа авылына, Болгарга, Буага алып барган идек. Ул конкурсны Расих Латыйпов җитәкчелегендә “Туган тел” оешмасы үткәреп килде. Укучылар үз гаиләләре, әби-бабалары, авылның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, мәчетләр, авыл урамнары, сугыш ветераннары турында иншалар яздылар, шәҗәрәләрен төзеделәр. Бу эшне татар теле укытучысы Зөлфия Асылгәрәева белән башкара идек, – дип дәвам итте сүзен мөгаллимә.

**– Кәүсәрия апа, укытучы хезмәте күңелегезгә нәрсәсе белән якын булды?**

– Укучыларымны үз балаларымдай яратып эшләдем мин. Укытучы хезмәтендә бу – иң мөһиме.

**– Сезнеңчә, укытучы, белемнән тыш, тәрбия дә**


*Кәүсәрия Шәйхетдинова уңнан беренче*










**бирүчеме? Яисә тәрбияне ата-ана бирергә тиеш, дип саныйсызмы?**

– Тәрбия белән белем бирү бер юлдан барырга тиеш. Тәртип булмаса, уку да аксаячак. Әлбәттә, тәрбияне күбесенчә ата-ана бирә. Әмма без, укытучылар да, зур роль уйныйбыз. Мин һәр дәрестә әз генә булса да тәрбия турында сөйләп китә идем. Сыйныф җитәкчесе буларак та моңа зур игътибар бирдем. Укучыларым арасында намаз укучылар, ураза тотучылар да булды. Алар, гаилә корып, тәртипле тормышта яшиләр хәзер. Әти-әниләр һәм мәктәп тәрбияне бергә алып барырга тиешләр.

**– Кәүсәрия апа, математика – төгәл фән. Балалар иҗади дәресләрне күбрәк ярата бит. Ничек**




**итеп укучыларыгызда үз фәнегезгә мәхәббәт уята идегез?**

– Дәрестән тыш чаралар уздырырга, төрле кызыклы мәгълүматлар эзләп табарга, күрсәтмә әсбаплар кулланырга тырыштым. Авылда балалар күбрәк татар телендә сөйләшә. Мин эшләгән чакларда бигрәк тә шулай булды. Шуңа күрә математиканы татар телендә дә аңлата идем. Кеше үзенең ана телендә фикер йөртә бит ул. Шуңа күрә теманы яхшырак үзләштерәләр иде. Медалистларым да булды.

**– Укучыларыгызның уңышларына куана идегезме?**

– Әле дә ничек! Аларның уңышлары – минем эшемнең нәтиҗәләре бит. Дөрес юлдан барам, дигән сүз. Бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулаганнарына да алардан да күбрәк мин сөенә идем.

**– Тормышта шундый хәл күзәтелә – укытучылар тәртип бозучы укучыларын күбрәк яраталар кебек. Сездә ничегрәк булды?**

– Тәртиплеләрен дә, тәртипсезләрен дә яраттым. Бала бит юкка гына тәртип бозмый ул. Димәк, аңа игътибар, наз җитеп бетми. Нинди генә азгын булса да, аның бит барыбер яхшы яклары да бар. Андыйларны күбрәк җәллисең, күбрәк игътибар бирәсең.

**– Укытучы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

– Әйткәнемчә, безнең эштә иң мөһиме – балаларны ярату. Тирән белемле, гадел, йомшаклыгы да, таләпчәнлеге дә чамалы булырга, укучы укытучыдан курыкмаска, аңа ышанырга һәм шул ук вакытта үзен ихтирам итәргә, тыңларга тиеш.

**– Ата-аналар белән мөнәсәбәтләрегез ничек иде? Аларның ярдәмен тоеп эшләдегезме?**

– Укучыларымның ата-аналарына һәрвакыт рәхмәтле булдым. Аллаһыга шөкер, һәрвакыт ярдәм иттеләр, активлык күрсәттеләр. Алардан беркайчан да гаепләү сүзләре ишетмәдем. Бары тик рәхмәт әйттеләр. Нарасыйларына карата ясаган кисәтүләрне дә аңлап кабул итәләр иде. Бердәм булып, бергәләп эшләдек.

**– Сез тәрбия эше буенча директор урынбасары вазифаларын да башкаргансыз. Бу өлкәдәге хезмәтегез турында да әйтеп үтсәгез иде.**

– Бу – бик тә күләмле эш. Мин мәктәпкә урнашканда ул вакытта пионер оешмалары булды бит. Анда максатларыбыз төгәл билгеләнгән иде. Аннан соң комсомол оешмалары. Һәрберсенең холкын күздә тотып, сыйныф җитәкчеләре белән аерым эш алып бардык.

Бу оешмалар таркалгач, "Милли мәдәниятне торгызу" программасы буенча эшләргә тотындым. Җыр-бию түгәрәкләре, төрле чаралар. Безнең



мәктәптә ел саен Сабан туе узып килә. Бу бик тә матур, зур чарага бөтен авыл халкы диярлек җыела. Элгәреге замандагыча, укучыларыбыз бәйрәм алдыннан, һәр йортка кереп, Сабан туе бүләкләре җыеп йөриләр. Шулай аларга милли гореф-гадәтләребезне өйрәтәбез.

Тәрбия эше, гомумән, һәр адымыбызда булды. Ата-аналар җыелышларында төрле темаларны кузгата идек. Клуб хезмәткәрләре белән, мәдрәсәбез әһелләре белән бергәләп эш иттек. Укытучылар белән аерым сөйләшүләр алып барасың.

Тәрбияне дин белән бәйләп алып барырга тырыштым мин. Дини кеше тәртипсез була алмый. Мәдрәсәдән имамнар чакырып, алар вәгазьләр сөйлиләр иде. Бу эшләр мәктәбебездә хәзер дә дәвам итә.

**– «Авыл мәктәбендә, шәһәрнекенә караганда, тиешле дәрәҗәдә белем бирелми. Шуңа күрә балаларга, калага барып, югары уку йортларына керүе авыр», дигән фикер гамәлдә йөри. Бу турыда нәрсә әйтә аласыз?**

– Бу фикер белән һич тә килешә алмыйм. Аллаһыга шөкер, укытучыларыбыз бик көчле безнең, төплеләр, тирән белем бирәләр, үз эшләрен чын күңелдән, тырышып башкаралар. Имтиханнар буенча укучыларыбыз югары баллар җыя, һәм барысы да диярлек югары уку йортларына керә.

**– Укытып чыгарган балаларыгызны сагынасызмы?**

– Әйе, сагынам. Аларның һәрберсе күз алдымда тора. Кайда белем алалар, кайда эшлиләр – барысы белән дә кызыксынам, сорашып торам. Үзләре дә гел шалтыратып, хәлләремне беләләр, бәйрәмнәр белән тәбриклиләр, күрешергә киләләр. Никахларына да чакыралар. Бу – минем өчен зур бәхет.

**– Сездә татар балалары гына укыдымы, әллә башка милләтләр дә бар идеме?**

– Авылыбызга читтән кешеләр килеп урнаша башлагач, урыслар да, үзбәкләр дә, азәрбайҗаннар да булды. Барысы да үзара нык дуслашып китәләр иде. Милли нигездә низаглар чыкканы булмады, шөкер.

**– Сезнеңчә, элгәреге укучылар бүгенгеләрдән аерылалармы?**

– Мин эшләгән вакытта балалар уйнарга, котырырга яраталар, гел хәрәкәттә, активлар иде. Хәзер күбесенчә телефонда утыралар бит. Элеккегеләрен дә, бүгенгеләрен дә тәртипсез, дип әйтеп булмый. Күп нәрсә эти-әни, сыйныф җитәкчесе тәрбиясеннән килә.

Хәзер пандемия аркасында читтән торып укыту ысулы зур авырлыклар тудыра, әлбәттә. Укытучыларга да, укучыларга да, ата-аналарга да кыен.

Балалар белән кара-каршы аралаша алмыйлар. Мәктәптә һәрберсенең эшен, тәртибен күзәтәсең бит ул, балалар күз алдында. Аларның тәртибен контрольдә тотасың. Кирәк чакта кисәтү ясыйсың, кирәк вакытта мактап куясың. Үзем эшләмәсәм дә, укытучыларны да, укучыларны да бик җәллим. Вакытлы гамәл булып, тизрәк элеккеге укыту процессына кайтырга насыйп булсын үзләренә. Укучылар, хезмәттәшләрең белән күрешү, аралашу кирәк ул.

**– Кәүсәрия апа, мөгаллим – тынгысыз җан бит инде ул. Менә сез дә, төп хезмәтегездән тыш, “Туган тел” татар җәмгыяте эшләрендә дә актив катнашкансыз. Моңа милли җанлы булуыгыз этәрдеме?**

– Шулай. Тик утыра алмыйм шул мин. Татар халкының язмышы өчен дә борчылам. 2008 елда район “Туган тел” оешмасының җитәкчесе итеп Расих Мөҗәһит улы Латыйпов сайланды, һәм ул мине үзенең ярдәмчесе итеп куйды. Без аның белән бөтен эшне бергә башкардык. Ул һәрвакыт безнең белән киңәшләште. Планнарны, отчетларны төзи идем. Барлык язу эшләрен башкардым.

Расих әфәнде бик оста, уңган җитәкче булды. Авылыбызда зур күләмдәге күп матур чаралар уздырылды: беренче Бөтенроссия авыл Сабантуе, регионара ат чабышы, “Авыл кызы” конкурсы, дини форумнар, “Халкым минем” фестивале, “Туган як” укулары, дини бәйрәмнәр, спорт ярышлары.

“Шатлык” балалар һәм “Мирас” фольклор төркемнәре барлыкка килде. Костюмнар тегелде. Бабайлардан гармунчылар төркеме җыйдык.

Каз өмәсе дә бик күңелле бәйрәм булды. Ул елны Ра-












сих турбазада бик күп казлар асраган иде. Өмәгә Мәчәләй, Яңа Мансур авылларыннан, Самардан, Камышлыдан килделәр.

“Җырлыйк әле!”, “Җырлы-моңлы балачак”, “Урмай моңы”, “Манзара” телевизион тапшыруларында да катнаштык.

Казаннан күренекле татар шагыйре Роберт Миңнуллин, “Ак калфак” бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасының җитәкчесе Кадрия Идрисова, мәртәбәле мөгаллимә Саидә абыстай Аппакова бездә кунакта булдылар.

Нинди генә чыгым булса да, Гали авылында үткәрәбез, дип, Расих бөтен күләмле чараларны бездә оештырырга тырышты. Шөкер, бик актив эшләдек. Расих үзе бик тә уңган кеше иде, ялкауларны яратмады ул.

“Туган тел”дәге хезмәтем мәктәптә тәрбия эшендә дә бик ярдәм итте. Укучыларны да, укытучыларны да җәмәгатьчелек эшенә җәлеп иттек.

**– Сез Гали авылының “Ак калфак” татар хатын-кызлары оешмасын да җитәклисез бит әле. Шушы хезмәтегез турында да сөйләп үтегез әле.**

– Иң элек хатын-кызлар оешмасын барлыкка китерү хакында сүзне Расих Латыйпов башлады. Чөнки барлык чараларда да хатын-кызлар катнаша, оештырыша иде. 2004 елда “Ак калфак” оешмасы барлыкка килде, җитәкчесе мин булдым. Мәрхүм Расихның хатыны Кәүсәр белән икенче форумда катнаштык. 2016 – 2019 елларда оешма җитәкчесе булып Илһамия Кәримова торды. 2019 елдан җәмгыятьне яңадан мин җитәкләдем.

“Ак калфак” хатын-кызлар оешмасы алда әйтеп үтелгән һәр чарада актив катнаша, оештыруда ярдәм итә.

Гөлшат Хәйруллина интернетта “Одноклассники”да махсус битебезне алып бара. Чараларда фотоларга төшерә, яза.

Флюра Низамова бик күп итеп калфаклар, күлмәкләр текте, музейга зур ярдәм күрсәтте. Һәрбер чарада күргәзмә ясый. Ул – безнең оешманың йөзек кашы.

Саимә Морзаханова – шагыйрә. Чигә, аш-суга бик оста, уңган ханым. Кияүгә чыгучы кызларга сөлге чигә, күчтәнәчкә кулъяулыклар чигеп өләшә, бәйрәмнәргә, килгән кунакларга бавырсак пешерә. Өч шигырь җыентыгын бастырды, һәрбер чарада күргәзмә ясый.

Фәһимә Зарипова – авыл китапханәчесе. Минем уң кулым, киңәшче, ярдәмче, оештыручы, кирәкле материални табып бирүче.

Рузия Моратова – чигүче. Камыр ашларын оста пешерә. Аның бавырсагы үзенчәлекле, тәмле. Күргәзмәләрдә рәхәтләнеп катнаша. Турбазада кунакларны мичтә пешкән коймаклары белән сыйлый.

Барлык хатын-кызларыбызны санап бетереп булмый шул. Бөтенесе дә актив катнаша, рәхмәт яусын.

Корбан, Мәүлид бәйрәмнәре, Ифтар мәҗлесләре үткәрәбез. Кул эшләре, милли ризыкларны пешерү буенча төрледән-төрле мастер-класслар оештырабыз.

Читтә яшәүче авылдашларыбыз җибәргән, мәдрәсәбездән арткан корбан итләрен, садакаларны картларга, фәкыйрьләргә таратабыз.

Ел буена музей өчен кирәкле мәгълүматлар җыйдык, стендлар ясадык, шәҗәрә төзү буенча конкурсны дәвам итәбез. Ак калфаклылар экспонатлар, фотоматериаллар җыюга зур өлеш керттеләр.

Оешмаларыбызга матди ярдәмне үзебезнең эшкуарлар күрсәтә. Казанда яшәүче авылдашыбыз Дания Тулова да булышып тора. Ул авыл өчен күү эшләр башкарды: мәктәпне, өченче мәчетне төзекләндерде, музейның барлык эше аның матди ярдәме белән башкарылды, бихисап авылдашларына ярдәм кулы сузды. Барысына да Аллаһының рәхмәте яусын.

**– Сез – дини авылда туып-үскән кеше, гомерегез буе шушында яшисез. Намаз укыйсызмы?**

– Раббыма шөкер, 40 яшемдә намазга бастым. Уразаны кечкенәдән тота идем. Исең китәр, Аллаһы Тәгалә намазу укыган кешегә сораганын бирә. Атлаган саен Раббымның ярдәмен тоямын.

**– Кәүсәрия апа, сез – ике ул анасы, җиде онык әбисе. Балаларыгызны тәрбияләү серләре нинди булды?**

– Эш белән тәрбияләнеп үстеләр алар. Хезмәт сөючән, уңган, акыллы булып үстеләр, шөкер.

Олы улым Солтан хәләл колбаса ясау цехында эшли. Оста, кулыннан барысы да килә. Икенче улым Рөстәм юридик белем алды. ГИБДД инспекторы булып эшли. Киленнәрем Зөлфирә, Камиләдән дә уңдым. Оныкларым Илһам, Илназ, Илсаф, Илзирә, Самир, Ясмина, Ислам – минем бәгырь җимешләрем, шатлыгым.

**– Бала татарча сөйләшсен өчен нинди чаралар күрергә кирәк?**

– Кечкенәдән гаиләдә, балалар бакчасында ана теленә өйрәтергә кирәк. Шул чакта гына ул татарча сөйләшәчәк. Татар китапларын, гәҗитә-журналлар укырга.

Бездә колхоз таркалган еллардан алып, бүгенге көнгә кадәр балалар бакчасы булмады. Күрше чуваш авылына йөргән нарасыйларның телләре урысча ачылды. Ә бит элек укучылар мәктәптә һәрвакыт татарча гына аралашалар иде.

Әлхәмдүллилләһи шөкер! Яңа ел алдыннан авылыбызда балалар бакчасы ачылды. Биредә татар теле алып барыла. Авыл җирлеге башлыгы Идрис Муллабаев белән Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыевка һәм Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Закировка хат язып, татарча китаплар сорадык. Аллаһының рәхмәте яусын Гөлназ Шәйхигә. Аның һәм Дания Тулова ярдәмендә ул китаплар кайтарылды. Без аларны бик шатланып бакчага тапшырдык.

**– Буш вакытларыгызда нәрсә белән шөгыльләнәсез? Берәр нинди мавыгуыгыз бармы?**

– Коръән, дини китаплар укыйм. Төрле басмаларга мәкаләләр дә язгалыйм. Оныкларым белән мәш киләм.

**– Кәүсәрия ханым, Гали – данлыклы авыл. Аны Самар өлкәсендә генә түгел, башка җирләрдә дә яхшы беләләр. Авылыгызның шундый күренекле булуы нидән килә икән?**

– Безнең авыл дини яктан бик көчле. Гомер-гомергә шулай. Элек бер мәчеттә икешәр мөәзин, икешәр мулла булган. Хәзер дә, шөкер, дүрт гыйбадәтханәбездән азан яңгырый. Мәдрәсәбез эшләп килә.

Халкыбыз уңган, чиста, аш-суга оста. Бер дә тик тормыйлар бездә. Бер җирдән акча керми башласа, шунда ук икенче эш табалар. Күпләп теплицада яшелчә үстерәләр, мал асрыйлар, кибетләр тоталар. Эшкуарларыбыз, фермерларыбыз бар. Аллаһыга шөкер, авылым белән горурланып яшим.

**– Үз гомерегездә үкенгән чаклапрыгыз булдымы?**

– Ни язган шул булган инде. Барысына да риза мин, шөкер. Яшьлек сизелмичә уза ул, шатлыклы картлыкта яшәргә язсын. Аллаһы бала хәсрәте күрсәтмәсен.

**– Димәк, тормышта үз урынымны табып, бәхетле яшәдем, дип әйтә аласыз?**

– Әйе, Раббыма шөкер. Улларым, киленнәрем, оныкларым тәүфыйклы булдылар. Дусларым, күршеләрем, авылдашларым яхшы, тату яшибез. Туганлык җепләрен өзәргә ярамый. Бәхеткә, без туганнарыбыз белән бик тату, аралашып, күрешеп яшибез. Гомерем буе яраткан эшемне башкардым. Мин барысына да канәгать, Аллаһыга шөкерана кылам.

**– Яшьләргә нинди киңәш бирер идегез?**

– Туган телебезне сакласыннар иде. Дин юлыннан барсыннар. Дини кеше тәртипле һәм бәхетле була ул.

**– Кемнәргә таянып яшисез?**

– Аллаһы Тәгаләгә таянам. Балаларым, туганнарым, дусларым – ышанычлы терәгем.

**– Кәүсәрия апа, хаҗда булгансыз икән. Изге җирләрдә Аллаһы Тәгаләдән ни сорадыгыз?**

– Әйе, 2015 елда Раббым хаҗ кылырга насыйп итте. Анда якын дин кардәшем Нәфисә Исхакова белән бардым. Ул – яхшы киңәшчем. Туганнарына, дусларына игелек кылып яшәүче. Самарда тора.

Аллаһыдан балаларыма бәхет, тәүфыйк, үземә хәерле картлык сорадым. Анда бер барсаң, гел барасы килеп тора. Хаҗ кылу вакыты килеп җитте исә, җаным өзелә минем. Изге җирләрдә шундый рәхәтлек тоясың, моны сүз белән аңлатып булмый. Раббым тагын шунда бару бәхетен бирсен иде, дип сорыйм.

**– Амин, Кәүсәрия апа, изге теләгегез тормышка ашып, исәнлектә, сөенечтә озын гомер кичерергә язсын сезгә.**



*Кәүсәрия ханым Шәйхетдинова сулдан дүртенче*

# ШАМИЛЬ ОБЪЕДИНИЛ ГОРЦЕВ, ВОЕВАВШИХ МЕЖДУ СОБОЙ, И СПЛОТИЛ ИХ ВОКРУГ ИСЛАМА

***Как и в любой империи, классическим средством для расширения Российской империи были завоевательные войны. Одной из них была Кавказская война, которая продолжалась полвека, захватив период правления четырех царей, и почти полностью опустошила российскую казну.***

**Фарид ШИРИЯЗДАНОВ**



*Имам Шамиль*

Для России эта война была предметом престижа, а для горцев – борьбой за национальную независимость и за сохранение исламских устоев.

Как и всякая война, она была страшной и жестокой. Одни там погибали и калечились, другие делали карьеру, третьи богатели, а дворянские дети – отмывали свою запачканную честь.

При этом силы сторон были неравными, поэтому ее цели и средства также были неадекватными.

Война эта была многолика. Включала она в себя и внутреннюю борьбу горцев со своими беками и ханами, мешающими объединению родственных народов.

В этой войне Шамиль объединил кавказцев и стал их гордостью, оставив яркий след и добрую память в серцах народов Кавказа. Родился он в аварском ауле Гимры в Дагестане. Шамиль был учеником и другом первого дагестанского имама Гази-Мухаммада. После гибели второго имама Гамзат-бека в 1834 году он был избран главой имамата.

Шамиль с детства рос слабым и худым, часто болел. Назвали его в честь деда – Али. Но по местному обычаю, чтобы запутать «злых духов», вызывающих болезни, дали ему второе имя – Шамиль.

Постепенно он поправился и вырос крепким юношей. Летом и зимой ходил босиком, с открытой грудью. Мог перепрыгнуть через пропасть шириной в 9 метров. Никто не мог догнать его на бегу и побороть в любом состязании. Он обладал такими чертами, как храбрость, решительность, умение достигать цели в любых условиях и необыкновенная верность исламу.

Однако, наряду с твердостью, он был чрезвычайно добр и отзывчив к простым людям, даже к пленным. Удивительным было и его общение с природой. Чтобы день был удачным, он с утра поклонялся горной реке, съедал одно яблоко из своего сада и запивал его речной водой. Он был молчаливым, мечтательным и целеустремленным. Часто уединялся в горах и там мог оставаться даже на всю ночь, проведя ее в глубоких размышлениях.

Его единственным другом был Гази Мухаммед, который долгие часы проводил за молитвой, готовя себя к духовной службе. А Шамиль стремился к физическому совершенству. Он был сильным борцом, бегал и плавал лучше всех и со временем стал искуснейшим наездником. Всех поражали его умение стрелять из лука на всем скаку и владение шашкой.

Когда он усвоил законы шариата и суфизм (сложное учение, рассматривающее религиозную историю от Адама, Моисея, Иисуса и до Мухаммеда), его признали лучшим учеником шейха Джамалутдина.

Со временем Шамиль со своим другом Гази Мухаммедом приняли особое мусульманское учение – мюридизм. Гази Мухаммед пешком ходил по аулам призывая к священной войне против захватчиков и горцы признали его как имама Чечни и Дагестана.

Против них были выставлены огромные силы под командованием трех генералов: Розена, Вельяминова и Вольховского. В первом же крупном бою участвовал и Шамиль. Вырываясь из окружения Гази Мухаммед геройски погиб, у Шамиля штыком было проткнуто плечо. Выздоровев, он стал продолжателем дела Гази Мухаммеда – имамом и сразу занялся укреплением в горах мусульманского права – шариата.

Существовавшее тогда вероисповедание было разнородным и вбира-



*Кавказская война*

ло в себя следующие верования: поклонение духам предков, одухотворение и поклонение неодушевленным предметам (фетешизм), сабеизм, шаманизм, и в то же время они признавали единого Бога.

Однако существующие тогда обычаи и все поверья способствовали сохранению пьянства, грабежей, невежества и кровожадности. Шамиль взялся искоренять все эти пороки. Он велел карать смертью за обман, измену, разбой, грабеж, за несовершение пятикратной молитвы и за неуплату закята в пользу нуждающихся. А курильщикам протыкали носы и привязывали трубку.

Будучи еще мальчиком, он презирал пьянство. Отцу, любившему выпить, пригрозил, что если тот не перестанет пить, то он зарежет сам себя. И тот бросил пить.

Год за годом имам Шамиль заменял неписаные правила, обычаи горцев законами, основанными на шариате. Среди важнейших его деяний была отмена крепостного права, рабства, противоречащего мусульманской идее о равенстве всех людей.

Его кодекс свода законов, их справедливость вызывали доверие и уважение горцев. Он был мудрым правителем, законодателем и прекрасным полководцем. Покорял и жестоко карал ханов и беков, покорных русскому царю, присоединяя все больше народностей – собратьев по вере, под знамена ислама.

Поняв, что идет стравливание народов, направленное на их взаимоуничтожение, а затем происходит их завоевание поодиночке, имам Шамиль твердо решил объединить народы Кавказа путем внедрения мюридизма и усиления нравственности, основанной на шариате.

О его фантастическом авторитете можно судить даже по одному примеру: во время пятничной молитвы его мюриды и весь народ его резиденции – селения Ведено вставали живым коридором от его дома до мечети и провожали его на молитву.

Во время проповеди каждое его слово воспринималось как абсолютная истина. У Шамиля было 30 наибов – правителей провинциями. Они также выполняли и роль военных предводителей, и у каждого из них было свое знамя.



Генерал Ермолов на Кавказе

В 1839 году произошло жестокое сражение. Потеряв много бойцов после трехмесячной осады, его участники героически вырвались с боем и чудом спаслись. В России уже торжествовали победу. А он, залечив раны, через 8 месяцев снова объявился во главе мюридов.

Однажды жители Чечни, усом-



нившиеся в успехе продолжения войны, через мать Шамиля обратились к нему с просьбой разрешить покориться русскому царю (передав ей 20 тысяч туманов).

Узнав о потворстве своей матери отступникам, Шамиль три дня провел в раздумьях и молитвах. Что же делать?! Простить – немыслимо, а наказать – тяжело! И тут он услышал голос сверху: «Кто виноват – дай ему сто ударов плетью!»

Выполняя этот приказ, он смог ударить свою мать плетью только 5 раз и упал без чувств. Когда встал, сказал: «Остальные 95 ударов, которые велел мне Аллах, я принимаю на себя. Бейте меня. Если кто пропустит хоть 1 удар, того я тотчас зарежу!»

В процессе борьбы против огромных войск Шамиль придумал верную тактику: не биться лоб в лоб, а заманить врагов в горы и, образовав завалы, обстреливать их с горных вершин.

Однако Шамиль понимал, против какой огромной силы ему придется воевать.

Ведь Кавказскую войну тогда возглавлял генерал Ермолов, который был твердо убежден, что у народов Кавказа есть только одна возможность – покориться власти императора или быть поголовно уничтоженными.

«Железом и кровью создаются царства, подобно тому, как человек рождается в муках!» – любил повторять он.

В его руках была огромная власть. Был он командиром отдельного корпуса, главнокомандующим Грузией. Ему подчинялись Каспийская флотилия, Черноморское казачье войско, Астраханская и Кавказская губернии. Ожесточенность этой войны можно объяснить и тем, что именно Северо-Запад Кавказа с его плодородными землями был целью завоевания (эти земли сейчас включены в состав Ростовской области, Краснодарского и Ставропольского краев).

Мы привыкли называть кавказцев горцами. Но ведь народы Северного Кавказа жили на равнине, но были загнаны в горы в процессе их борьбы за право на жизнь. Поэтому о жизни на Кавказе и об их суровых обычаях трудно судить человеку, который не проживал там.

В 1855 году имам Шамиль смог вертуть из России сына Джамалутдина, которого еще мальчиком он был вынужден отдать в заложники русскому царю. Воспитанник Пажского корпуса Джамалутдин тогда



*Пленинение Шамиля*

уже стал поручиком уланского полка. Шамиль с горечью слушал умные, но критические слова сына по поводу его войск, о вооружении горцев и их военном устройстве.

Рассказывая о царе и огромном его войске, Джамалутдин просил отца о примирении с Россией. Конечно, это было огромной трагедией для Шамиля. Но что делать?! Ведь тот с малых лет воспитывался в России.

Однако со временем Шамиль и сам понял, что противостоять такой огромной силе он дальше не сможет.

Он видел, как селения кавказцев в предгорьях и низинах уничтожались полностью. Находясь в окружении, ради спасения своего народа от полного истребления Шамиль согласился на переговоры.

После многолетней войны российская казна была опустошена до предела, а народам Кавказа грозило полное уничтожение. Учитывая это и с целью сохранения генофонда своего народа имам Шамиль принял условия почетного пленения и сдался в плен русским войскам 27 августа 1859 года, хотя и не верил, что его оставят в живых.

Но царь Александр II встретил его достойно, с почестями, и устроил в честь его торжественный прием. На содержание его многочисленной семьи определили пенсион в 20 тысяч рублей, а его личная пенсия составила 15 тысяч рублей серебром в год.

Местом его почетной ссылки сначала был определен город Калуга, а затем семью поселили в Киеве. Значительную часть своей пенсии Шамиль жертвовал ссыльным землякам и нуждающимся жителям города Калуги.

Кавказскую войну историки окружили ореолом славы, а поэты и писатели – романтическим ореолом. Но на самом деле она была страшной и предельно жестокой. Как горько шутили солдаты, даже в котлах с супом находили пули горцев.

Во все времена Кавказ являлся стратегической зоной особой важности. Если говорить об этой войне, то тогда три могучих империи – Россия, Турция и Персия претендовали на владычество над Кавказом.

А вопрос подвластности Кавказа самими горцами воспринимался по-своему. Например, когда один русский генерал объяснял черкесам, что турецкий султан уступил Кавказ русскому царю в дар, слушавший его старик-горец, показав на улетевшую с дерева птичку, сказал ему: «Я тебе дарю вот эту птичку, возьми ее, если сможешь!»

В 1870 году Александр II отпустил Шамиля с семьей в Мекку. Чтобы добиться этого, Шамиль написал клятвенное письмо, что в дальнейшем не причинит России вреда.

В Мекке он встретился с турецким султаном и, несмотря на его уважительное приветствие, Шамиль не подал ему даже руки. Ведь султан отказал ему в помощи в самые трудные моменты.

Несмотря на 18 серьезных ранений, полученных в различных сражениях, имам Шамиль прожил 72 года.

Пока он был жив, люди в Мекке толпами ходили за ним, почитая его за святого. Когда он умер, его с почестями похоронили на земле, считающейся священной для мусульман, – на кладбище сподвижников пророка Мухаммеда Джаннат ал-Баки.

Один из пяти сыновей Шамиля был пашой в Османской империи и служил там главнокомандующим войсками. А все остальные стали офицерами русской армии. Так уж было предначертано судьбой.

Как и про любого прославленного человека, про Шамиля тоже говорят разное: и хорошее, и плохое. Но при всем этом он заслужив себе славу, не меркнущую в веках.

Кавказцы – уникальный народ, сохранивший пассионарность древних булгар и стойко хранящий ее и сегодня. Ведь и «серебрянные барсилы», правящие роды Булгарского царства, были выходцами с Кавказа.

Сказки, древние легенды татарского народа всегда были окутаны загадками и тайнами, в которых Кавказ («Каф таулары» занимает особое место).

Будучи свободолюбивыми и природными воинами, кавказцы верны долгу и своему слову. Прославленный писатель-историк Мурат Аджи в своих книгах пишет о своих дедах и прадедах, как им и только им доверяли охрану царских особ России во многих их поколениях.

История народов Кавказа уникальна, но ее трудно до конца понять тем, кто не побывал там и не вникал в суть событий, происходивших там, хотя об этом много написано в произведениях Л.Н. Толстого, М.Ю. Лермонтова, Мурада Аджи и других писателей и поэтов.



*Шамиль*



*Җәмилә Шәрифуллина*

# «ТАТАР ТЕЛЕН БЕЛҮЕМ ӨЧЕН ГАИЛӘМӘ РӘХМӘТЛЕМЕН»

***Акыллы, максатчан, тәрбияле, тәүфыйклы, аралашучан, ачык, ягымлы яшьләребез белән сөйләшеп утыруы бигрәк рәхәт тә инде! Шушы матур сыйфатларга ия булган 25 яшьлек Җәмилә Шәрифуллина белән аралашканнан соң да күңелемдә уңай тәэсирләр калды.***

**Миләүшә ГАЗИМОВА**

Аның татар кызы булуы белән горурлануы, милләтен ихлас сөюе, күркәм холкы, үз һөнәрен яратуы хисләремне тагын да көчәйтеп җибәрде. Һәм инде Самар өлкәсенең авыл хуҗалыгы министрлыгы каршында чыгып килүче “Агро-информ” журналында хәбәрче булып эшләүче каләмдәшем белән әңгәмә кору аеруча кызыксыну уятты.



Җәмилә шәһәребезнең “Яктылык” мәктәбен тәмамлаган. Аның әтисе – Самар өлкәсенең “Туган тел” исемле татар җәмгыятенең активисты Ринат Шәрифуллин күпләргә таныш, дип уйлыйм. Ринат әфәнде озак еллар дәвамында барлык татар чараларында кул көрәштерү, гер күтәрү кебек спорт ярышларын оештыручы буларак катнашты. Нәкъ ул балачактан кызын татар милли хәрәкәтенә җәлеп иткән, аңарда милләтебезгә, ана теленә мәхәбәт тәрбияләгән дә инде. Милли җанлы гаиләнең ни өчен “Яктылык” мәктәбен сайлап алулары да аңлашыла, әлбәттә.

Җәмилә Самарның С.П. Королев исемендәге милли-тикшерү университетында филология һәм журналистика факультетын тәмамлаган һәм өч ел һөнәре буенча эшли.

**– Җәмилә, “Яктылык”та нинди дәресләрне аеруча ярата идең?**

– Миңа телләр үзләштерү ошый. Татар, урыс, инглиз телләре дәресләрен яраттым. Бигрәк тә инглиз теле укытучысы Зилә Шәрәфетдинова үз фәненә мәхәббәт тәрбияли белде. Ул дәресләрне бик тә кызыклы, аңлаешлы итеп алып бара иде.

**– Мәктәптә сиңа нинди белем һәм тәрбия бирделәр, дип саныйсың?**

– “Яктылык”та үз татарың мохитендә укыйсыйң. Сыйныфташларым бертуганнардай, класс җитәкчебез икенче әниебез кебек иде.

Безне олыларны – олы, кечеләрне кече итә белергә өйрәттеләр, татар теленә, гореф-гадәтләребезгә, динебезгә, мәдәниятебезгә, тарихыбызга мәхәббәт тәрбияләделәр. Татар язучыларын, шагыйрьләрен белдек, ана телебездә шигырьләр сөйләргә, җырларга, милли мирасыбызны саклап, аны үстереп яшәргә өйрәндек. Гомумән, “Яктылык”та бик яхшы тәрбия һәм тирән белем бирделәр.

**– Үрнәк алырлык остазың кем булды?**





– Сыйныф җитәкчебез Нурсәхи кызы Фәния апа Гыйлаҗева. Аның белән хәзер дә аралашып-очрашып торабыз, озак күрми торсам, үзен бик тә сагынам. Ул безне һәрвакыт хуплады, ярдәмен күрсәтте, авыр вакытларда акыллы киңәшен бирә белде. Мәктәпне тәмамлауга сигез ел узса да, әле дә безнең өчен кайгырып, борчылып яши, хәлләребезне белешә. Тормыш корган сыйныфташларым Фәния апабызны никахларыннан калдырмыйлар, аны иң якын кешеләрнең берсе буларак кабул итәбез без, олуг вакыйгаларыбыз белән уртаклашырга чакырабыз. Ул һәрберебезнең күңелен күрә иде. Аңа карата тирән хөрмәт кичерәбез, рәхмәтләребезне укыйбыз.

**– Мәктәп баласы булганда холкың нинди иде? Еллар үткәч, ул үзгәрдеме?**

– Укыган чакта тыйнак, тыныч холыклы, әмма актив идем. Хәбәрче булып эшли башлагач, кыюландым, андый оялчан түгел хәзер. Эшем шуны таләп итә. Кеше арасында йөрибез, аралашырга, әңгәмә алырга кирәк. Оялып тору урынсыз, ул чакта эш бармаячак.

**– Нинди чараларда катнаша идең?**

– Төрле фәннәр буенча олимпиадаларда һәрвакыт катнаштым. Миңа нинди урынга чыгуым мөһим булмады, катнашуым әһәмиятле иде. “Кояш” дип аталган ансамбльдә җырладым. Нәүрүз, Сөмбелә бәйрәмнәрендә, Сабан туйларында чыгыш ясый идек. Мин – иҗади шәхес. Миннән һәрчак плакатлар ясарга да сорыйлар иде.

**– Җәмилә, иҗади шәхес дигәннән, син брошкалар ясау белән дә шөгыльләнәсең икән. Моңа ничек өйрәндең?**



*Җәмилә сыйныф җитәкчесе Фәния Гыйлаҗева белән*

– “Туган тел” җәмгыятендә җитәкчебез Фәрхәт абый Мәхмүтов безне һәрвакыт төрле татар чараларында катнашырга җәлеп итә, активлык күрсәтергә чакыра иде. Гомумән, ул безне күп нәрсәгә өйрәтте, милли хисләребезне ныгыта торды, аңа бик тә рәхмәтлебез.

Шулай 2015 елда Фәрхәт абый безгә Казанга Татар яшьләре көннәренә барырга тәкъдим итте. Анда дизайнер Ләйсән Хәзиева брошка ясау буенча мастер-класс үткәрде. Бу миңа шулкадәр ошады ки, әлеге кул эшен җентекләп өйрәнә башладым. Осталыгым артты, хәзер инде брошкаларны сатам да. Инстаграмда үземнең битем бар, анда мин ясаган брошкаларны күрергә, махсус заказ бирергә дә була.

Милли бизәкләребезне кулланып, татар брошкаларын да ясыйм. Безнең бизәкләрнең нигезендә табигатьтәге чәчәк-үсемлекләрдән торган композицияләр ята. Шуларның берсе - лалә чәчәге. Ул үзгәреш-яңарышны аңлата. Кул эшләрем арасында лалә чәчәге,



ярымай формасындагы брошкаларым да бар. Үзем бизәнү әйберләрен тагарга бик яратам. Алкалар да ясый башладым.

**– Җәмилә, нигә нәкъ журналист һөнәрен сайлап алырга булдың?**

– Мин балачактан, кулыма микрофонга охшаш әйбер тотып, әтиәниемнән, дусларымнан әңгәмә ала идем. Телевизордан хәбәрчеләрне тыңлап, алар кебек булырга теләдем. Уенчык фотоаппарат белән кешеләрне, табигатьне, хайваннарны төшереп йөрергә яраттым. Мәктәптә укыганда да төрле чараларда фотога, видеога төшерә идем. Балачак хыялымны тормышка ашырырга теләп, журналист һөнәрен сайлап алдым.

Әле университетта беренче курста укыганда әбием мине Ришат Төхвәтуллинның концертына чакырды. Үзе миңа: “Җәмилә, видеокамераңны алырга онытма, концертны төшерерсең”, - дип бурыч та йөкләде. Шулай Ришат Төхвәтуллинның чыгышын, залда утырган халыкны төшердем. Булгач, тулы видеоролик булсын инде, дип, Ришат



Төхвәтуллиннан әңгәмә алырга да тәвәккәл иттем. Ул сорауларыма урыс һәм татар телендә җавап бирде.

Видеороликны интернетка элдем. Барысы да аңласын өчен урыс телендәге җавапларын бирдем. Күплләрдән: "Ришат Төхвәтуллинның урысча сөйләшүен беренче ишетүем!" – дип гаҗәпләнү сүзләре дә ишетелде. Видеороликны 7 мең кеше карады! Бу минем өчен профессиональ өлкәдә берникадәр тәҗрибә туплау булды.

**– Эшең нәрсәсе белән күңелеңә якын?**

– Яңа шәхесләр белән танышам, аралашам. Үзем өчен кызыклы, файдалы мәгълүмат алам. Исең китәр – төрледән-төрле кеше, һәрберсенең үз хезмәте, үз шөгыле, үз мавыгуы! Төрле һөнәр ияләре эшенең җентекләренә төшенәсең.

Баштан авыл хуҗалыгы тармагы кызыксыз, дип уйлаган идем. Бу бер дә алай түгел икән! Өлкәбезнең төрле районнарына йөрибез. Фермерларыбыз кәҗә, сыердан алып, дөя һәм боланга кадәр үрчетәләр!

Татар фермерлары өчен аеруча шатланам. Шулай миңа Яңа Ярмәк авылында Салават Җәләевта, Мәчәләйдә Әлфия Субеевада булырга туры килде. Алар үз хуҗалыкларын үстерер өчен өч миллионлык грант откannар. Үз милләтемнең тырыш, уңган кешеләре турында горурланып язам.

**– Журналист нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

– Һәр кеше белән уртак тел таба белергә тиеш. Авыр хәлдә калмас өчен әңгәмә алыр алдыннан булачак язмаңның герое турында берникадәр мәгълүматны үзләштерү, сорауларыңны әзерләү мөһим. Сөйләшкәндә үткен зиһенлелек тә кирәк, чөнки әңгәмә барышында яңа сораулар бирергә туры килергә мөмкин. Кешедән алган мәгълүматка тиз арада төшенеп, аны оператив рәвештә эшкәртергә, язарга да кирәк.

**– Буш вакытларыңны ничек уздырасың?**

– Буш вакытларымда "Туган тел" җәмгыяте яшьләре белән Халыклар дуслыгы йортында очрашып, төрле татар чараларын, уеннарын үткәрәбез, аралашабыз.

**– Синең өчен гаилә яисә карьера мөһимрәкме?**

– "Мөселманның көймәсе елганың уртасыннан барырга тиеш", диләр. Динебез Ислам буенча да уртадан бару хәерле. Икесе дә мөһим. Әмма татар халкында гомер-гомергә хатын-кыз гаилә учагын саклаучы булган. Гаиләбез – безнең терәгебез, тормышта иң мөһиме, дип саныйм.



*Җәмилә әтисе Ринат Шәрифуллин белән*

**– Әти-әниең синдә нинди сыйфатлар тәрбияләделәр?**

– Олыларны хөрмәт итәргә, кечеләрне үпкәләтмәскә, сабыр булырга. Ә татар телен өйрәткәннәре өчен мин аларга һәм бабама, әбиемә аеруча рәхмәтле. Гаиләбездә һәрвакыт ана теле яңгырады. Бездә "мама", "папа" сүзләре ишетелмәде, "әтием", "әнием" генә булды. Урысча берәр сүз әйтсәм, мин сине аңламыйм да, ишетмим дә, дип җавап кайтаралар иде. Күп иптәшләрем татар телен белмим, дип кызганалар. Мин ана телемдә сөйләшкәнемә шатланам, татар кызы булуым белән горурланам. Моның өчен гаиләмә бик рәхмәтлемен.

**– Әти-әниең белән мөнәсәбәтләрең нинди?**

– Алар һәм әбием – минем иң якын кешеләрем. Раббым үзләренә исәнлек, озын гомер бирсен. Серләрем белән уртаклашам, алар миңа һәрчак ярдәмгә киләләр, акыллы киңәшләре исә бәяләп бетермәслек.

**– Кайбер ата-аналарның: "Балабызга татар теле тормышта кирәк булмаячак", дигән сүзләре турында ни уйлыйсың?**

– Профессор Татьяна Черниговскаяның: "Күп телләр белү кеше миенең үсешенә уңай йогынты ясый", дигән акыллы сүзләре бар. Бала никадәр күп тел белсә, шулкадәр аның зиһене яхшы. Бигрәк тә Аллаһы Тәгалә безне төрле кавем, төрле халыклар итеп яралткан. Димәк, без үз телебезне, милләтебезне саклап калырга бурычлы!

**– Кешеләр синдә нинди яхшы сыйфатларыңны билгелиләр?**

– Мәрхәмәтле булуыма басым ясыйлар. Мин кешеләрне байларга һәм ярлыларга, начарларга һәм яхшыларга бүлмим, социаль статусларына карамыйм. Кеше булсын. Намуслы



булсын. Миңа эчке сыйфатлары якын.

Аннары мин кешене башкаларның фикеренә карап бәяләмим. Аның белән аралашып, аны белеп, үз фикеремне тудырам.

Үпкә, ачу тота белмим. Кешеләрне гафу итә белергә, позитив булырга кирәк.

**– Ә кимчелекләрең? Алар өстендә эшлисеңме?**

– Кайчак ялкаулык баса. Берәр эшне озакка сузуым бар. Кимчелекләремне төзәтергә тырышам, әлбәттә. Эшләремне планлаштырырга өйрәнәм.

**– Кешеләрдә нинди сыйфатларны өстен күрәсең?**

– Намуслы, гадел, әдәпле, үз-үзләрен кулда тота белүче кешеләрне яратам. Дөреслекне күзгә бәреп әйтүчеләр ошый. Әлбәттә, дөреслекне кешене үпкәләтмичә, әдәпле җиткерергә кирәк.

**– Синең өчен бәхет нәрсәдә?**

– Якыннарымның исә-сау булуы – минем өчен зур бәхет.

**– Камил гаиләне ничек күз алдына китерәсең?**

– Минем гаиләмдә, Аллаһы теләсә, ир гаилә башлыгы булачак. Ә мин – аның ярдәмчесе, терәге, гаилә учагын саклаучы. Балаларыбызның күп булуын телим.

**– Авыр вакытларда дөрес карар кабул итәргә кем булыша?**

– Әбиемнең акыллы киңәшләре тормышымда ярдәм итә.

**– Заманча яшьләрне ничек бәялисең?**

– Яшьләребез - алга киткән егетләр, кызлар. Барысыннан да хәбәрдар. Тик менә бик күп вакытларын компьютер алдында үткәрәләр. Интернеттан файдалы мәгълүмат тупласалар ярый әле. Ә бит еш кына күңел ачу өчен генә утыралар. Күбрәк китап укысыннар иде.

**– Тормыш девизың бармы?**

– Һәрхәлдә кеше булып калырга. Күңел төшенкелегенә бирелмәскә. Көчле рухлы булырга, бирешмәскә.

**– Киләчәккә нинди планнар белән янып яшисең?**

– Аллаһы теләсә, тормышка чыгарга, профессиональ яктан үсәргә, эшемдә уңышларга ирешергә телим.

**– Җәмилә, сиңа чын күңелдән уңышлар, бәхетле булуыңны, теләкләреңнең тормышка ашуын телим.**










# РАЗГОВОР С БАБУШКОЙ

***Моя малая родина в Похвистневском районе Самарской области. Там мои родители, бабушка. Та самая бабушка, которая всю жизнь прожила на этой земле. Чай и суп у нее только из родниковой воды, а родник на огороде. Такого чая и такой еды в большом городе не попробуешь. В этом роднике всегда стояли и остывали банки со свежим катыком. Вода в роднике такая прозрачная, что мы смотрелись в нее, как в зеркало, и такая студеная, что зубы ломит, когда пьешь. Но в жаркий летний день – просто счастье пить из этого ключа и находиться с ним рядом, поскольку он у речушки в тени деревьев.***
***Вам я хочу рассказать о моей бабушке Жэухар эбике.***

**Луиза ИМАНГУЛОВА**

У этой женщины безграничная любовь к людям...

Ее дом в селе Сукаевка напротив остановки. И я отчетливо помню, как она приглашала людей в дом погреться, если человек долго не мог уехать. Если отказывался зайти, она выносила теплую одежду. Если у человека не было денег, чтобы уехать, она не раздумывая помогала и с этим. В январе ей исполнится 90. Она живет в том же доме, встает в 4 утра, с радостью встречает гостей и каждый день молится за всех живых и ушедших.

Манжукова Жэухар Шакировна, труженик тыла, дитя войны. Родилась 20 января 1931 года в селе Сукаевка Самарской области.

Отец – Манжуков Шакир Шойдуллович родился в 1907 году, участник Великой Отечественной войны, мулла. Мама – Сафарова Срур Миргазовна 1911 года рождения, родом из села Мочалеевка, Самарской области.

**– Эби, какими ты запомнила своих родителей?**

– Отец был старательный, трудолюбивый, не жалел себя. Очень строгий, но людям помогал. Любил нас. Обнимать не обнимал, но я чувствовала, что любит. И больше всех, наверное, меня. Может, потому что, старшая была. У него и у меня одинаковые голубые глаза. Мама добрая. Даже в голодные годы, кто ни зайдет, всех накормит. Нас было четверо: я, Гайса, Марьям и Гэмбэр. Гэмбэр умерла от кори в возрасте двух лет. Еще помню бабушку, которая научила всем домашним делам. Всю работу я делала, пока родители работали.

**– Ты собрала только лучшие качества от своих родителей. А детство помнишь?**

– Марьям шустрее меня была, помню, дружно с ней жили. А с Гайсой ругались (смеется), он дразнил меня вороной или сорокой.

На гору поднимались с ребятами, когда заканчивались посевные работы и играли. «Кыр егырышу» (догонялки в парах), «Биляуся» (стенка на стенку).

**– А что помнишь, когда началась война?**

– Мужчин всех забрали на войну. Нам остались все работы на полях. Мальчики держали плуг, девочки



шли впереди с лошадьми. Поля пахали, бороновали, потом сеяли, снопы вязали, потом на гумно везли с полей, молотили зерно. Матерям помогали в полях, пололи зерно и подсолнечник. Эту траву приносили с поля домой для коровы, на тележке везли. Все мужчины были на войне, а мы работали. Приходили с поля домой, кто-то идет в огород, кто-то готовит суп из травы балтырган или листьев свеклы. Нам повезло, что была корова. Люди падаль ели. Лошади умирали весной от голода, люди делили их

мясо и забирали по домам. Я ребенком просила: «Вот бы с неба кусочек хлеба упал!» Так хлеба хотелось. Но не было. Мы ели гнилую картошку, мама делала из нее лепешки, ели почки с деревьев. Делали лепешки из тыквы и свеклы, муки не было. Один кубик сахара на троих делили. Белье стирали золой. Воду горячую добавляли в золу, размешивали, зола садилась на дно и вода становилась мягче, потом стирали. Голову мыли кислым молоком.



У нас жили четыре немецкие женщины, их пригнали из Саратова на целину и оставили рубить лес. Они одну зиму жили с нами. Супружеская пара евреев жила. Гита Борисовна, медсестра, и ее муж Амнеил из Москвы. Беженцы. Женщина Маруся с двумя детьми. Тогда беженцев расселяли по семьям. Гита, когда уезжала, целовала маму и благодарила. Говорила, что обязательно посылки будет отправлять за ее доброту.

**– Что рассказывал тебе твой отец, когда вернулся с войны. Это тяжело. Но можешь ли все это вспомнить, чтобы я все записала?**

– Отец всегда плакал, когда рассказывал мне о войне. Он контужен был, оба глаза ослепли, заливали кровь и глаза восстановились. Рядом разорвался снаряд, его землей засыпало, он вышел из-под нее, сел и сказал: «Эй, Аллам...» В это время медсестра на лошади проезжала, собирала раненых, татаркой была. Услышала родную речь и забрала его в больницу. Когда он выздоровел, снова письмо пришло, чтобы ехал на войну. Он говорил, когда первый раз шел, не так было страшно и тяжело. Потом ранили в ногу, он еще долго хромал, нога все не заживала. В Баку в госпитале лежал, всегда молился, читал намаз. Благодаря этому врач очень его полюбил и отправил ближе к дому служить. А когда отправляли его на барже, он чудом уцелел. На берегу было много людей, все побежали на баржу. А отцу и еще одному человеку не хватило места, и они остались на берегу. После того как баржа отплыла, ее обстреляли немецкие самолеты, и она пошла ко дну. Так он остался живым. От голода и холода очень много умирало людей. Солдаты верхнюю одежду снимают, а она ходуном ходит от вшей. Рассказывал, как друга его ранили, друг просил, чтобы он его застрелил, но он так и не смог. Наутро друг умер. Одна женщина бросила своего ребенка в воду. Кричит, плачет, волосы на себе рвет. Пусть лучше сейчас он погибнет, чем его немцы убьют. Река вся в трупах, можно было как по мосту ходить, по трупам... Вот такая страшная она – война, не приведи больше Аллах...

**– Помнишь ли ты день, когда объявили, что все, пришла победа?!**

– Я училась в школе, и тут нам объявили, что война закончилась! Мы начали бегать и кричать: «Ура, ура!» По улицам бежим, сумки кидаем и обнимаемся.

**– А послевоенное время, когда стало немного легче жить?**

– Сразу все, конечно, не наладилось. Сначала нам стали давать ржи по 200 грамм, потом по 400. Мололи и хлеб пекли. 200 грамм зерна за один трудодень. Четыре класса окончила. Учил нас Газизов Котдус. Детей было много, делили на классы. Писали простым карандашом, позже появились перо и чернила. У меня почерк был хороший, меня в пример ставили. Из уроков: математика, чтение, география, природоведение, история и грамматика. Летом работали, зимой учились. Подсолнечник сажали вручную, все потом болело. Свеклу пололи сахарную, а осенью по 12 машин в день вручную грузили. Помогали друг другу грузить. Колхоз наш называл-





ся «Красный партизан». Еще работала дояркой, от 7 до 15 коров доила. На стройке работала, разнорабочей на станции Безымянка. Носила раствор, цемент и кирпичи на тележке.

**– А как отдыхали?**

– Вещер уйный идек (вечер играли). По очереди, то в одном доме, то в другом собирались. Из забав «такмак» (хоровод), сольные пляски под гармонь, игра «курше» (соседи). Пели, плясали, смеялись вдоволь. Друг другу помогали во всем.

**– А во сколько лет ты вышла замуж за деда и как вы познакомились?**

– Замуж вышла в 23 года. Познакомились в колхозе, на поле. Он сказал: «Все равно выйдешь за меня» (улыбается). Он был скромный, этим и понравился. Приходит на крыльцо, один раз спрашивает: «Пустишь вечер посидеть?» Если скажу нет, сразу уходит. А некоторые привяжутся, как болезнь, такие не нравились. Один все писал письма, я ни на одно не ответила, другой «перилэремне кузгата» (до того не нравится, что терпеть не могу...).

**– Эби, а любовь – это что?**

– Яным тарта кешегэ (душа тянется к человеку). Одной жить не нужно. Друг нужен. Вдвоем и поругаться, и посмеяться можно.

**– Расскажи о своей замужней жизни.**

– В двух комнатах жили 9 человек. Свекор со свекровью, сестры мужа и мы вдвоем. Семья большая была. В три утра вставала. Доила корову, поила теленка, топила печку, в ней готовила еду. Все остальные спали. Потом шла на работу. До 55 лет в колхозе работала. Построили с мужем новый большой дом, места хватало всем. Каждое лето у нас гостили племянники и племянницы мужа, всем хватало места и еды.

Советская власть запрещала мечети. В нашем доме мечеть была. Люди с деревни приходили молиться по праздникам и пятницам. Комнату занавеской делили на две части, отделяли мужчин и женщин. Намазлыкларны (коврики для молитв) всегда стирала сама руками.

**– А кто тебя научил молитвам?**

– С детства приученные были. Отец был мулла. И уразу (пост) детьми держали. Моя бабушка говорила, что в конец света, все куда-то бежать будут, брат через брата будет перешагивать. А Аллаха только хорошие люди смогут увидеть через много-много занавесок.

**– Ты часто говоришь, что люди помогали друг другу.**

– Да, сейчас каждый за себя. А раньше, вот соседке надо сарай построить – омэ жыялар (всех зовут). Мужики придут – сруб срубят. Завтра мне надо баранов стричь, придет 5 женщин, быстро помогут. Вот так ходили, друг другу помогали. Без денег выручали друг друга.

**– Эбием, прожила ты славную жизнь, заслужила спокойную и счастливую старость. Желаю тебе здоровья еще на долгие годы.**

– Рэхмэт, балам. Вам, молодым, я желаю счастья, пусть сбываются мечты и планы.

## ОБ АВТОРЕ

**Имангулова**
**Луиза Равилевна.**

Училась в школе имени П.В. Кравцова в с. Старое Похвистнево Самарской области.

В 2010 году окончила Самарскую академию культуры и искусств.

Четвертьфиналистка проекта шоу «Голос». Обладатель Гран-при и лауреат международных конкурсов. Сооснователь и певица этнопроекта «Якруна» в Москве. Проект выпустил дебютный альбом «Зеленая улица» и несколько синглов, среди которых есть песни и на татарском языке.





# МӘХӘББӘТКӘ РӨХСӘТ СОРАМЫЙЛАР

***Авыл кешеләре гомер-гомергә, бер гаиләдәй аралашып, үзара дус, тату яши бит.***
***Җәйнең матур бер көнендә бөтен авылга: “Зәкиҗан ычкынган икән!” дигән хәбәр таралды. Юк, юк, сез әллә ни уйлый күрмәгез тагын, ычкынган, дигәч тә, ул үлмәгән, аның бары тик чираттагы сәрхүшлеге генә башланган.***

**Нурсинә ХӘКИМОВА.**
**Денис авылы, Шенталы районы.**

Ат арбасына аягүрә басып, баш очында чыбыркысын селти-селти:

Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар,
Мәхәббәткә рәхмәт әйтмиләр,
Ул бүләк һәм бурыч та түгел,
Мәхәббәтне гаеп итмиләр, – дип жырлап, дөбердәтеп, Зәкиҗанның урам уртасыннан үтеп китүе булды, капка төбендәге эскәмиядә авырткан сөякләрен кояшта җылытып утыручы Сабира карчык белгән догаларын укый-укый:

– Я, Раббым, берүк шушы сәрхүш, имансыз нәмәрсә – Зәкиҗанның юньсезлегеннән Үзең саклый күр инде дип, -теләкләр тели-тели, капкасын бикләп үк, өенә кереп китте.

Аның артыннан хәтфәдәй чирәмдә каз бәбкәләрен саклап утыручы тол хатын Фатиха да:

– Явыз дошманнардан үзең сакла, Аллаһым! – дип, өенә таба юнәлде. Урамда уйнап йөргән кечкенә эт баласы – Шарик та бер почмакка посты.

Кем ничек булдыра, шулай бәйләнчек Зәкиҗанның күзенә чалынмаска, аңардан котылып калырга тырышты. Чөнки аның шушы җырны җырлап урамнан үтүе әйтерсең лә:

– Хәзер авылга мин хуҗа, миңа каршы килгән кешеләр үзләренә үпкәләсен! – дип кисәтә иде.

Ә менә Җәмилә, Зәкиҗанның терәлеп торган күршесе булса да, аның гадәттәге авыруының ”баш күтәрүен” абайламый калды. Иртәгә Себердә вахта ысулы белән эшләп йөрүче ире Габдулла ял итәргә кайта. Өс-башымны, үземне бераз тәртипкә китерим әле, дип, кичке эшләрен бетергәч, рәхәтләнеп мунча кереп кайтучы яшь хатын каршында күзе-башы тузган Зәкиҗан пәйда булгач, мескен хатын куркудан телсез калды.

Аның каравы, күршесе бер дә югалып калмады, киек өстенә ташланган җанвар кебек, бер сикерүдә яңа гына мунчадан чыгып килүче, тәне-башы кайнар, үзеннән тәмле каен себеркесе, мәтрүшкә исе бөркелеп торучы Җәмиләне кочагына алып, иреннәреннән суырып үпте.

Ә үзе исә:

– Җәмиләкәй! Җиләгем минем, сине көтеп, сине сөеп гомерем үтә бит минем, – дип пышылдады.

Бичара хатын:

– Җибәр, Зәкиҗан абый! Габдуллага әйтәм, – дип тыпырчынды һәм ничек кенә булса да кызмача күршесе кочагыннан ычкынырга маташты.

Ахыры ни белән беткән булыр иде, гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шул чагында йорт ягында иртәгә кайтып җитәм, дип хәбәр бирүче Габдулла тавышы ишетелде:

– Җәмилә, матурым, кайда син?! Җәмиләү-ү-ү?

Куркудан ап-ак булган Җәмилә, һушы китеп, алмагачлар арасына егылды, ә Зәкиҗан “эһ” дигәнче ике арадагы койма өстеннән үз йортына сикерде. Габдулла якты ай нурында бакчада ап-ак эчке күлмәктән генә җирдә ятучы хатынын күтәреп алды да өенә керде.

– Матурым, ничә тапкыр табиб эссе мунчада юынма, дип орышты бит сине. Нигә бер дә колак салмыйсың соң? -дип шелтәләп тә алды ир хатынын.

– Әйе! Беркайчан да мондый эссе мунча кергәнем юк иде әле, – диде Җәмилә, ире ясап биргән баллы чәйне эчә-эчә.

Ә үзе исә рәнҗеп, күңеленнән генә күршесе Зәкиҗанга:

– Көтеп тор, синең мунчаң минекеннән дә кызурак булыр! – дип янады.

Яшьлек елларына килгәндә, Зәкиҗан, армия хезмәтен тутырып, авылга кайтканда Җәмилә язгы гөлдәй, чәчкә кебек, бик матур кыз булып өлгергән иде. Ул Габдулланы сайлады. Мәхәббәте кире кагылган Зәкиҗан, йөрәге әрнесә дә, күрше авыл кызы Гөлфиягә өйләнде.

Алар Габдулла белән Җәмилә күршесендәге бер буш йортны сатып алып, башка чыктылар. Ике яшь гаилә үзара ярышып тормыш көтә, балалар үстерә башлады. Тик менә Зәкиҗанның гына кайнар мәхәббәте сүнмәде, яшерен генә, пыскып януын дәвам итте. Үзенең юашлыгына ачуы килеп, эчкәләргә тотынды. Шушы чакта аның күзенә чалынмавың хәерле, юаш, басынкы холыклы ир атом бомбасына әйләнә иде.

Зәкиҗан аптырап калмады, икенче көнне, берни булмагандай, бер “акбаш”ны кыстырып кереп, ялга кайткан күршесе Габдулланы

сыйлады, ә үзе, май ашаган мәчедәй, Җәмиләне күзәтте. Шулай бер атналап вакыт үтте. Ике арадагы каерылган койма тактасы капка ролен үтәде.

Бер көнне карлыган куагы төбендә сабыр гына көтте Җәмилә. Төн шомлы караңгылыкка чумып утырганда, таң алдыннан, чайкала-чайкала, аның ирен исертеп, өенә таба юнәлгән Зәкиҗан каршысына ап-ак җәймә ябынган килеш килеп басты да, кулларын болгый-болгый, төрле куркыныч тавышлар белән ысылдап, чәчләрен туздырып, күптән түгел үлгән әнкәсе Маһинур әби кыяфәтенә кереп:

– Улым! Мин сине алырга, дип кайттым. Әйдә, хәзер үк китәбез, чөнки син биредә гөнаһ кылып кына яшисең! -дип өстенә килә башлады.

Менә шул вакытта исерек Зәкиҗан айнып китте дә инде. Үзе, куркудан хәле бетеп:

– Әнкәй!.. Юк, юк, кирәкми, кит, кит... Минем үләсем килми!... Яшәп туймадым әле мин!.. – дип кычкырды.

Кинәт көтелмәгән хәл булды, исереп алгач, батыр йөрәкле, бөтен дөньяны үзенә буйсындыручы, Җәмиләнең тормышын боза язган баһадирдай гәүдәле Зәкиҗан, йөрәген тотып, гөрселдәп җиргә ауды.

Хатын-кыз нечкә күңелле бит ул. Болай буласын көтмәгән Җәмилә Зәкиҗан янына, җиргә утырды да:

– Я, Раббым! Кеше үтердеммени мин?! Мәңгелек йортка күчкәч, ни дип җавап бирермен?! Зәкиҗанның ятим, гөнаһсыз сабыйлары, тол калган хатыны Гөлфия күзенә ничек күтәрелеп карармын?! – дип еларга кереште.

Ул шешенеп беткәнче елагач, тынычланды һәм көч-хәл белән Зәкиҗанның авыр гәүдәсен койма аша үз ягына сөйрәп чыгарды, ә үзе:



– Әтәч! Бүтән койма аша күрше тавыклары янына очып керә алмассың шул инде, – дип сөйләнде һәм өендә





йоклап ятучы исерек Габдулласы куенына чумды.

Иртәнге якта көтү озатырга чыккан Зәкиҗанның хатыны Гөлфия, ирен аңсыз яткан килеш табып алып, күршеләре ярдәме белән өйгә алып керде. Ул, табиб чакырып килеп, авыру иренә уколлар кадатты, кашыктан ашатты, йомшак күпчектә йоклатты. Нинди генә булса да, аның ире бит!

Ә Зәкиҗан белән Җәмилә арасында барган сугыш турында берни белмәгән Габдулла:

– Әле кичә генә җырлап-биеп, баш төзәтеп йөргән, ип-исән Зәкиҗан үлем көтеп ята, диләр. Үлем яшь кеше, дип тормый, сәгате җиткәч, алып китә икән ул! – дип сөйләнде.

Габдулла – кибеткә, Гөлфия чишмәгә суга киткәч, Җәмилә теге ике арадагы койманы аягы белән генә тибеп ачты да күршесе белән бәхилләшергә керде.

– Зәкиҗан абый, бәхил бул! Рәнҗеп китә күрмә инде! - диде хатын түр караватта башын ап-ак яулык белән кысып бәйләп яткан, төсе качкан күршесенә.

Нәкъ шул чагында:

– Җәмилә, дөресен әйт әле. Ул син идеңмени? – дип сорады Зәкиҗан әкрен генә.

Бичара хатын җавап бирмәде, елый-елый өйдән чыгып йөгерде...

Менә шуннан соң авылга тагын бер яңа хәбәр таралды: имештер, Җәмилә Зәкиҗанны дәвалап, терелткән икән.

Әйе, озак та үтмәде, Зәкиҗан тәмам савыгып, аякка басты. Узган хәлләрдән соң ул басылып, юашланып калгандай булды. Бераз акылга утырыпмы, иң беренче эш итеп, күршесе белән ике арага тимердән койма койды, үзе бакчасында карлыган җыючы Җәмиләгә, шомырт кебек, кара күзләрен мөлдерәтеп, мәгънәле караш ташлады да:

Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар,<br>
Мәхәббәткә рәхмәт әйтмиләр,<br>
Ул бүләк һәм бурыч та түгел,<br>
Мәхәббәтне гаеп итмиләр, – дигән җыр юлларын сузды һәм эре-эре адымнар белән үз өенә, гаиләсе янына таба атлады...

















# САМАРДА ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨНЕ УЗДЫ

***2020 елга өлкә һәм шәһәр татар милли оешмалары, гадәттәгечә, күп төрле чаралар уздырырга планлаштырган иделәр.***

**Алия АРСЛАНОВА**

Кызганычка, эпидемиологик вәзгыять кискен булу сәбәпле, аларның шактые үткәрелмичә калды. Шуңа үзара аралашуга һәм татар җыр-моңнарына сусаган милләттәшләребез декабрьнең беренче көннәрендә Самарның “Заря” мәдәният сараенда “Татар мәдәнияте көне” уздырылуы турындагы хәбәрне бик шатланып кабул иттеләр.

Бу көнне “Заря”ның кече залында бәйрәм рухы хөкем сөрде. Кунаклар Самар өлкәсенең халык кәсепләре һәм кул эшләре буенча декоратив-кулланма сәнгать остасы Гөлнара Насыйрованың кул эшләре, 40 елга якын фотокамерасы объективы аша шәһәр татарлары тормышын яктыртып килүче, танылган фотограф Әнәс Мингалиевнең фотосурәтләр күргәзмәләре белән хозурландылар. Ә җирле эшкуарлар Мәүлет һәм Римма Низамовлар җитештергән чәкчәк, бавырсак, талкыш каләвәләр, икенче буын умартачы Мөхтәр абый Гыйниатуллин алып килгән бал, умартачылык продукцияләре һәм бал кушып пешергән тәм-томнарны күчтәнәчкә дип сатып алырга ашыктылар.

... Бәйрәмнең төп өлешен бик матур итеп өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте Советы әгъзасы Альбина Мәхмүтова алып барды. Иң элек ул кунакларны өлкә һәм шәһәр татар милли оешмалары, аларның җитәкчеләре һәм эшчәнлеге белән таныштырды. Сүз уңаеннан, чарага өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүров та килеп, бүләккә “Самар татарлары” журналларын һәм календарьлар өләште.

Альбина ханым өлкәбездә татар телендә нәшер ителүче газеталар, милли сайтлар турында да сөйләде, татар мәдәнияте, гореф-гадәтләр һәм йолалар темасына кызыклы викторина да уздырды. Кунаклар Самар татарлары тормышы турында күп яңалык ишеттеләр, бергәләп табышмакларга җавап эзләделәр, мәкальләр әйттеләр.



Бәйрәм “Идел” татар халык эстрада ансамбленең концерты белән үрелеп барды.

Җырчылар Алинә Шәйхелисламова, Илдар Хәкимьянов, яшь талантлар Салават һәм Эльвина (ул саксофонда да оста итеп уйнады) Хәлимуллиннарны тамашачы яратып, сагынып каршы алды, һәр чыгышларын алкышларга күмеп барды. Алар артистларга кушылып җырладылар да, биешеп тә алдылар.

Ансамбльнең җитәкчесе, “Гали гармуннары” һәм “Җирнең бәллүр йөрәге” фестивальләре лауреаты Мидхәт Әминов берсеннән-берсе кечкенәрәк гармуннарда, курайда, кубызда виртоуз уйнавы белән таң калдырды. Ә Лилия Абдуллова-Хәлимуллина синтезаторда уйнап, артистларның чыгышларын һәм бу кичәне тагын да бизәде.

Кунаклар саны әллә ни күп булмаса да, бәйрәм әнә шулай бик күңелле, җылы атмосферада үтте.



# КЫШЛАУЧЫ КОШЛАР

***Кыш җитте, бөтен җирне кар каплады. Бу салкын чор безгә авырлык тудырса да, без кышны җиңел генә уздырып җибәрә алабыз. Өйләрдә җылы, ашарыбызга бар. Урамда да туңмыйбыз,чөнки җылы итеп киенеп йөрибез.***

**Эльмира СӘЙФУЛЛИНА**

Әменә кышлаучы кошлар өчен кыш – иң авыр чор. Кыш көне бездә чыпчык (воробей), песнәк (синица), күгәрчен (голубь), чәүкә (галка), ала карга (ворона), саескан (сорока) яши. Ә урманда тукран (дятел), мәче башлы ябалак (сова), карабүрек (снегирь), көртлек (тетерев), суер (глухарь), боҗыр (рябчик), чукыр (клёст), үрмәләч (поползень), күкшәне (сойка) очратып була.

Кышын кошларга салкыннар түгел, ә ачлык куркыныч тудыра. Азык табарга кирәк. Кышкы җилләрне җиңеп, нәни канатларын җилпеп, азык эзләүче кошларны күргәнегез бармы сезнең?

Кышын кошлар кеше янына елыша, ярдәм өмет итә. Әйдәгез, без кошларга карата мәрхәмәтле булыйк! Алар өчен «кошлар ашханәсе» оештырыйк – җимлекләр ясап элик!

**Гамил Авзал**

### ПЕСНӘК

Буранлы кышта
Нинди илләргә
Очасың, песнәк,
Салкын җилләрдә?
Туңа бит синең
Аякларың да,
Тала бит синең
Канатларың да.

Кунма син, песнәк,
Агач башына,
Мин бодай чәчтем
Тәрәз каршына.

**Инсур Мөсәнниф**

### ЧЫПЧЫК

Тәрәзәгә бер кош килгән,
Чиртә дә чиртә: «Чык-чык».
Дәү әнием әйтә миңа:
«Сине чакыра чыпчык».
Чыпчык? Чыпчык? Нигә алай? –
«Чыкчык» дисең бит үзең.
Өлкәннәр ялгыш кушкандыр,
Ишетеп бетерми сүзең.
Өлкәннәр «чыпчык» дисеннәр, –
Әллә китәме исем!
Бүгеннән сиңа куштым мин
«Чыкчык» – өр-яңа исем!

**Назип Мадьяров**

### ТУКРАН

Колагын агачка терәп,
Нәрсә тыңлый ул анда?
Әллә берәр хәвеф-хәтәр
Булды микән урманда?

Тыңлый өскәрәк менеп тә,
Түбәнрәк төшеп тә.
Кунарга шәт урын тапмый,
Ахрысы, берничек тә.

Әһә, бер турыга гына
Тукталды тукталуын.
Шулай да ул турының да
Тыңлап чыкты як-ягын.

Һәм, ниһаять, бик тырышып
Тукылдата башлады.
Күп тә үтми агачтагы
Кортны табып ашады.

**Әнәс Кари**

### КОШЛАР ТУЙДЫРАМ

Җимлек ясап бирде миңа
Абыем Сәлим.
Шунда хәзер кошлар өчен
Җимнәр сибәм мин.

Бире килә күк күгәрчен,
Песнәк һәм чыпчык.
Җыелалар бер-бер артлы,
Пыр-пыр очынып.

Ашап туйгач, китә алар
Төрле якка.
Тик күгәрчен генә кала
Иң азакка.

Ул да туйган, биегән күк,
Уйнап йөри.
Миңа рәхмәт әйткән сыман:
Пыр-пыр очынып, «гөлдергү», – ди.



## ТАБЫШМАКЛАР

Гөлдер, гөлдер, гөлдер бу,
Кызыл тәпи - кемдер бу. (Күгәрчен)

Җәй шакылдый бу чүкеч,
Кыш шакылдый бу чүкеч,
Ничек чыдый бу чүкеч. (Тукран)

Кечкенә генә берәү, артында озын терәү. (Саескан)

Ханның кызын алыр идем,
Кашым кызыл булмаса. (Көртлек)
Чуар киемле урам малае
Борчак җыя, кырда куна. (Чыпчык)

Кайсы кошның өе кар астында? (Көртлек)

Кайсы кош ауга төнлә чыга? (Ябалак)

Җәй буена ике тапкыр бала чыгаручы кош. (Песнәк)

Нинди кошны барабанчы диләр? (Тукран)

## САНАМЫШЛАР

Каенда – карга,
Имәндә – чыпчык,
Җирдә – елан,
Һавада – кош,
Бар, син оч!

Бер чыпчык, ике чыпчык, өч чыпчык, дүрт чыпчык, биш чыпчык, алты чыпчык, җиде чыпчык, сигез чыпчык, тугыз чыпчык, ун чыпчык – очып чык!

**Тәрәз каршына**
**Килгән бер чыпчык:**
**– Чык әле, – ди, чык!**

**Җепсез орчык,**
**Чәүкә, чыпчык,**
**Кара балчык,**
**Син кал, бу чык!**



Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та моннан чык.

# ПОКУПАЙТЕ ЖУРНАЛ «САМАР ТАТАРЛАРЫ»




## ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР




Телефон для связи 8-917-104-44-45 – **Сайфиев Данияр Ирекович**
Адреса электронной почты – **Samartatarlary@bk.ru, ilyas65@mail.ru**




**ПРИОБРЕСТИ НОМЕРА ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» МОЖНО ПО СЛЕДУЮЩИМ АДРЕСАМ:**
Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»), пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»), магазин «Булгар» (бывший «Итле-сетле») на территории Соборной мечети Самары.

**Стоимость текущего номера с доставкой – 250 рублей, стоимость номеров за 2019 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей. Доставка журналов по Самаре – тел. 8-937-64-044-77.**

# В НОВЫЙ ГОД – С НОВЫМ КАЛЕНДАРЁМ!

## ВЫШЕЛ В СВЕТ ТАТАРСКИЙ КАЛЕНДАРЬ ПАМЯТНЫХ ДАТ И СОБЫТИЙ НА 2021 ГОД




В красочном издании отмечены юбилейные даты наших известных соплеменников и важные для татар исторические вехи. Его создатели постарались также наполнить календарь максимально полезной информацией. В частности, на страницах календаря размещен полный перечень действующих татарских общественных организаций и их контакты, список мусульманских религиозных организаций, осуществляющих свою деятельность на территории Самарской области, популярные интернет-ресурсы, список действующих депутатов-татар и многое другое.

Напомним, что календарь издается с 2015 года и является ежегодным приложением к журналу «Самар татарлары».

Приобрести календарь можно будет по следующим адресам:

- Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»);
- Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»);
- магазин «Булгар» на территории Соборной мечети Самары.

Розничная стоимость календаря — 70 рублей.

По вопросам оптового приобретения обращайтесь по телефонам: 89171044445 или 89874457807.







ГОД ОСНОВАНИЯ 1974

# Кулинария
НА РЕВОЛЮЦИОННОЙ





- Праздничные торты и пирожные по индивидуальным заказам
- Готовые изделия из мяса, рыбы, птицы
- Салаты и гарниры
- Охлажденные и замороженные полуфабрикаты
- Большой ассортимент свежей выпечки
- Принимаем заказы на пироги
- Доставка горячих обедов в офис
- Обслуживание банкетов и фуршетов





**г. Самара, ул. Революционная, 142**
**Тел.: 260-10-60, 260-15-60**





